Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

# Риза казый фәтваләре

Казан – 2019

УДК 297
ББК 86.38
Р 45

*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррир:**
тарих фәннәре докторы,
ТР ФА академигы *Р.С. Хәкимов*

**Төзүче:**
филология фәннәре кандидаты
*А.М. Гайнетдинов*

Р 45 **Риза казый фәтваләре** / Төз. *А.М. Гайнетдинов*. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2019. – 108 б.

ISBN 978-5-94981-327-0

Китапта күренекле татар галиме Ризаэтдин Фәхретдиннең дини сорауларга биргән җапаплары китерелде. Алар 1908–1917 елларда чыккан «Шура» журналыннан сайлап алынды. Әлеге сораулар хәзерге көндә дә актуальлекләрен югалтмаганнар.

Хезмәт дини мирасыбыз һәм милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-327-0 УДК 297
ББК 86.38

© Гайнетдинов А.М., 2019
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2019

# КЕРЕШ

Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) – бөтен көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган бөек дин галиме, тарихчы, әдип, педагог, дини реформатор, казый, мөфти, археограф, эпиграфист, шәркыять белгече, җәмәгать эшлеклесе, җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле. Быел Р. Фәхретдиннең юбилее җитте, ягъни 2019 елда тууына 160 ел булды. Шулхәтле күп вакытлар узса да, аның исеме һаман телләрдән, каләмнәрдән төшми, халкыбыз аны һәрвакыт горурланып искә ала, хәзерге фәндә дә татарның иң олуг һәм могтәбәр галимнәренең берсе буларак санала.

Ризаэтдин Фәхретдин 1859 елның 17 гыйнварында (1858 елның 31 декабрендә) хәзерге Татарстан Республикасы Әлмәт районы Кичүчат авылында туган. Төпле белем алганнан соң, ул 1889–1891 елларда Илбәк авылында имам һәм мөдәррис вазыйфаларын башкарган. 1891–1906 елларда Р. Фәхретдин Мәхкәмәи шәргыядә (Диния Нәзарәтендә) казыйлык хезмәтен үтәгән. Аннан соң ул «Вакыт» газетасы идарәсендә мөхәррир ярдәмчесе, соңра «Шура» («Киңәш») журналына баш мөхәррир булып эшләгән. Әлеге журналның иң тәүге саны 1908 елның 10 гынварында дөнья күреп, иң ахыргысы 1917 елның 31 декабрендә чыккан. Шулай итеп, ун ел буе Р. Фәхретдин «Шура»да мөхәррир вазыйфасын намус белән башкарган. Аны журналның наширләре – бертуган Мөхәммәтшакир (1857 – 1912) һәм Мөхәммәтзакир (1859 – 1921) (Дәрдмәнд псевдонимы белән иҗат иткән шагыйрь буларак та билгеле) Рәмиевләр – эшкә чакырган булган. Р. Фәхретдин мөхәррирлегендә чыккан журнал битләрендә дин, тарих, әдәбият, тел белеме, халык авыз иҗаты, сәнгать,

фәлсәфә, география, педагогика мәсьәләләре тәфсилле рәвештә чагылыш тапкан. «Шура» битләрендә генә дә галимнең җиде йөзгә якын мәкалә һәм төрле характердагы язмалары дөнья күргән. Журналның һәр санында диярлек аның авторлыгы күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән ике-өч мәкаләсе басылган. Белгәнебезчә, «Шура» журналы Оренбург шәһәрендә айга ике тапкыр чыгып барган, шул рәвешле, бер елга барлыгы 24 сан дөнья күргән, тик иң ахыргы ике саны гына бергә, ягъни 1917 елның 23 һәм 24 нче саннары бергә кушылып басылган. Аннан соң, кызганычка каршы, журнал Халык Комиссарлары советының «Матбугат хакындагы декрет»ы нигезендә 1918 елның гыйнварында рәсми рәвештә ябылган.

Р. Фәхретдин «Шура» журналына унбиш ел казый булып торган һәм дин өлкәсендә бик зур гыйлем һәм тәҗрибә туплаган кеше буларак эшкә килгән. Иң беренче санында мөхәррир Р. Фәхретдин түбәндәге сүзләрне язган:

«Хак Тәгаләнең ярдәме белән бу «Шура» җыентыгын язарга һәм төзергә керештек. «Шура»ның мәсләге исә көче җиткән кадәр Русия мөселманнарының бәхетләре хакында хезмәт итүдән гыйбарәт булып, максаты да укучыларны риза итәр өчен ныклык һәм гайрәт күрсәтү.

«Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итү хакында киңәш мәҗлесе булачак. Теләгән кеше бу мәҗлестә сөйләр, теләгән адәм тыңлар»[1].

Әлбәттә, журналның структурасын һәм эчтәлеген формалаштырганда, ул укучыларның төрле сорауларына җавап бирә торган «Мөрасәлә вә мөхабирә» («Хат алышу һәм хәбәрләшү») исемле рубрика ясамыйча кала алмаган. Жур-

[1] Фәхретдин Р. Мәсләк вә максат / Р. Фәхретдин. – Шура. – 1908. – № 1. – Б. 1.

налның тышлык битләрендә: «Анда сорау-җаваплар һәм һәртөрле хатлар язылыр», – дип искәртелгән булган. Башта бу рубрикада сорау-җаваплар аз урнаштырылса һәм кайбер саннарында бөтенләй булмаса да, алга таба хатлар белән бик күп сораулар килә башлаган һәм Р. Фәхретдингә аларга җавап бирергә туры килгән.

Журналны укучылар шунда ук аңа бик күп дини сораулар яудырганнар, чөнки күпләр аның озак еллар казый булып эшләвен белгәннәр һәм аннан фәтва бирүне көткәннәр. Р. Фәхретдин бик теләп тарихи һәм иҗтимагый сорауларга җавап язган, әмма дини сорауларга җавап бирүдән башта сакланган, укучыларны андый сораулар белән Мәхкәмәи шәргыягә (Диния нәзарәтенә) мөрәҗәгать итәргә өндәгән. Әмма халык, Р. Фәхретдиннең дин өлкәсендә рәсми дини оешмаларда эшләүче казыйларга караганда гыйлеменең күпкә артык булуын белгән һәм сорауларын алардан түгел, ә Фәхретдиннән ишетәселәре килгән. Мөхәррир үзен бик тыйнак тоткан, үзенең гыйлеменең чикле булуын түбәндәге рәвештә искәрткән: «Белгәнебез кулда булган бармаклар санынча булса, белмәгәнебез күктә булган йолдызлар саныннан артык булыр»[2]. Башта ул карышса да, «Минем шәргый фәтваләр бирергә хакым юк», дип халыкка аңлатырга тырышса да, кешеләрнең гозерләрен кире кага алмаган һәм соңра «Бу – фәтваләр түгел, ә минем шәхси фикерләрем» дисә дә, халыкны борчыган дини сорауларга да җавап бирергә керешкән. Шуңа күрәдер Р. Фәхретдин: «Русия мөселманнары өчен арасында дини бер журнал булмау сәбәпле, мондый мәсьәләләр хакында фикер алышырга мәҗбүр булдык, ихтимал ки, моннан соң да бу мәҗбүрлек дәвам итәр», – дип язган[3].

---

[2] Шура. – 1909. – № 14. – Б. 442.
[3] Шура. – 1909. – № 22. – Б. 697.

Сораулар язылган хатлар илнең төрле почмакларыннан килгән. Аларны журналда урнаштырганда, гадәттә, сорауның кайсы торак пункттан килгәне язылган яисә, анысы билгесез булса, «намәгълүм» («мәгълүм түгел») дип язылган. Сорау ахырында сорау бирүченең исеме, псевдонимы яки инициаллары куелган. Галим Р. Фәхретдин халык биргән һәр сорауга төпле рәвештә һәм хикмәт белән җавап бирергә тырышкан. Җитдиләренә җитди һәм тулы итеп, мәгънәсезләренә бераз юмор кулланып һәм кыска рәвештә җавап биргән. Шуңа күрә аның кайбер фәтваләре кешене елатырга, кайберләре елмаерга мәҗбүр итәргә мөмкин.

Р. Фәхретдин – иң олуг һәм могтәбәр дин галимнәребезнең берсе. Ш. Мәрҗани аның турында: «Бу егет өметле. Мәсләгендә дәвам итсә, яхшы хезмәт итәр!» – дип әйтеп калдырган[4]. Г. Баруди Р. Фәхретдингә түбәндәгечә характеристика биргән: «Гыйльми куәте яхшы, гарәп телен белүе төзек, иң мөһим булган хәдис гыйлемен белүче, юлы һәм дөрес рәвеше белән яхшы исем хасил иткән. Ислам тарихында, аеруча галимнәр тормыш юллары турында яхшы мәгълүматы бар. Бу илләребездә (Казан, Болгар һәм Кыпчак вилаятендә) үткән галимнәр һәм мәшһүр затлар хакында гүзәл әсәрләре бар. Диндә һәм иманда ныклы, дини вазыйфаларында тугры, әхлагы сабыр, чыдамлыгы күркәм, аз сүзле, күп эшле, һәркемгә хәерлек теләүдә, әманәтле һәм туры сүзле зат»[5]. Шуның өчен без аннан үрнәк алырга, һәр сүзенә колак

---

[4] Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле / Ш. Шәрәф // Мәрҗани: Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. – Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). – Б. 181.

[5] Баруди Г. Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр / Басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. – Б. 229.

салырга, һәр хезмәте белән таныш булырга, һәр фикеренә таянырга тиешбез.

Ун ел буе чыккан «Шура» журналының «Мөрасәлә вә мөхабирә» рубрикасында якынча биш йөз сорауга җавап язылган. Без бу китабыбызда анда урын алган, бүгенге көндә дә актуаль һәм кызыклы булган 70 сорау хатына бирелгән җавапларны сайлап алып, аларны кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып, милләттәшләребезгә тәкъдим итәргә булдык. Нәкъ менә гади халык укысын, аңласын өчен аларны хәзерге телгә яраклаштырып бирдек, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Шулай ук текстларда очраган гарәп телендәге җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде. Китап исемен шартлы рәвештә «Риза казый фәтваләре» дип куйдык. Бу җыентык аркылы укучылар галим Р. Фәхретдин хакында тагын да күбрәк белерләр һәм үзләрен борчыган байтак дини сорауларга җавап табарлар, дигән теләктә калабыз.

**А.М. Гайнетдинов,**
филология фәннәре кандидаты

## [ТӘФСИРЛӘР ТУРЫНДА]

**Хоканд шәһәреннән:**

Уку өчен иң ышанычлы тәфсир [Коръән аңлатмасы] кем тәфсире? Дөрес фикер хасил итәр өчен нинди тарих китапларына иярү тиешле?

*Вәлиулла бине Мөхәммәдрәхим.*

**«Шура»**

Бу турыда гомуми сурәттә җавап бирү мөшкел. Бирeләчәк җавап сораучының хәлен тәмам белгәннән соң хосусый сурәттә булырга тиеш. Әгәр дә максат Коръән шәриф эчтәлеге белән ачык сурәттә беркадәр танышу булса, моның өчен төрки, гарәп тәфсирләре күп.

Моннан югары чыккан кешеләр өчен үз мәсләкләренә яраклы әсәрләр ихтыяр итү тиешле килер. Чөнки тәфсир китаплары гомумилык белән сыйнфый сурәттә булалар. Тәфсир төзүчеләр гарәп [теле] гыйлемнәре, кәлям [фәлсәфә һәм фәкать акыл белән шәригать текстларын аңлатуга нигезләнгән схоластик дин белеме системасы], ысуле фикыһ [ислам хокукы нигезләре], Сөннәт [пәйгамбәр юлы, өйрәтмәләре, гамәлләре һәм сүзләре], фикыһ кебек үзләре белгеч булган фәннәрен үзләренә мәсләк итәләр. Мәзһәб [ислам хокук системасына нигезләнгән дини юнәлеш] белән бәйләнгәннәр дә аять шәрифләрне үз мәзһәбләренә яраклаштыру белән шөгыльләнәләр. Менә шуңа күрә һәркем үз хәленә туры килгән тәфсир китаплары белән шөгыльләнер. Әмма, хакыйкать хәлдә, тәфсир махсус юлы белән хөрмәтле Рәсүлдән күчерелгән һәм гарәп теле мәгънәсе булган нәрсәдән гыйбарәт. Моннан арыларына башкалар өчен шәригать җәһәтеннән иярү тиешле түгел, уй һәм фикерләрдән гыйбарәт булыр. Ислам философы булган шәех Җамаледдин әл-Әфгани хәзрәттән: «Коръән шәриф өчен заман кадәр дөрес тәфсир юк һәм булмас, заман шундый бер китап ки, һәр шигырендә чиксез юллар, һәр юлында чиксез сүзләр, һәр

сүзендә чиксез мәгънәләр бар», – дип ишеттем. Фәкать югарыда искә алынган хәзрәтнең бу сүзе дә бары тик үзләре кебек нык галимнәргә күрә булганын уйлармын.

Ислам тарихларының могтәбәрләре Табари, Мәсгуди, Ибне әл-Әсир, Ибне Хальдун һәм болар шикелле галимнәрнең әсәрләреннән гыйбарәт. Исемнәре искә алынган затларның әсәрләре хәзер, бүген басылып, таралдылар. Фәкать элекке ислам тарихлары бары тик риваятьтән гыйбарәт булган өчен файдалану беркадәр мөшкел. Хөкемнәрен һәм фәлсәфәсен бәян итеп, тарих язу ысулы – яңа бер нәрсә. Бу җәһәттән, табигатендә зур бер сәләте булмаган кешеләр, мондый риваять юлы белән язылган әсәрләр сәбәпле, ялгыш фикерләр дә хасил итәләр.

Истанбулда басылган төркичә тарихлар, деспот хөкүмәтләр сәясәте мәҗбүр итүенә күрә, кимчелекле һәм байтак үзгәртүләргә очрап, басылганлыктан, дөрес бер фикер хасил итү – мөшкел бер нәрсә. «Нинди бер эшкә катышса, сәясәт аны бозар» дигән сүз дөрес булса кирәк.

*Шура. – 1908. – № 9. – Б. 293–294.*

## [ДИНИ МӘЗҺӘБЛӘР ТУРЫНДА]

**Эстәрлетамак шәһәреннән:**

1. Фикыһта мәшһүр булган дүрт мәзһәб [ислам хокук системасына нигезләнгән дини юнәлеш] кайсы гасырда пәйда булган? Ни өчен дүрт белән чикләнеп, тагын [да] артык булмаган? Боларны кемнәр төзеде? Үзләренең мәзһәб башлыклары икәнлекләрен үзләре дәгъва иттеләрме һәм мәзһәбләренә дә халыкларны чакырдылармы?

2. Мөҗтәһид[ләр] бетте, дип дәгъва итүчеләрнең шәригать дәлилләре бармы? Булса, ниләр? Бу сүз кайсы вакытта

таралган һәм ни өчен таралган? Бу мәсьәләләрнең җавабын «Шура»да язуыгызны үтенәбез.

*Түбән Бикәнеш авылыннан*
*имам Исхак Мөхәммәдша улы.*

**«Шура»:**

1. Әбү Хәнифә, Мәлик, Шафигый, Ибне Хәнбәл гасырлары мәгълүм булган җәһәт белән искә алынган мәзһәбләрнең нинди вакытта пәйда булганы үз-үзеннән мәгълүм була. Мәзһәб исә дүрт белән чикләнмәгән. Искә алынган мөҗтәһидләр дәрәҗәсендә Әүзагый, Ибне Әби Ләйли, Суфъян бине Гуяйнә, Ләйс бине Сәгъд, Суфъян Сәүри, Исхак бине Рәһәвәйһ, Дауд әз-Заһири, Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табари, Ибне Хәзимәән-Нисабури, Әбү Сәүр, Ибне Хәзем кебек затлар бар. Бу кешеләр дә мөстәкыйль мәзһәбләрдән булыр иде. Фәкать боларның кайберләренең мәзһәбләре бик элекке гасырларда бетеп, кайберләренеке исә байтак вакытлар дәвам иткән.

Мәзһәб һәм мәсләкләр күпвакыт шәкертләр һәм ияручеләр тарафыннан төзелә. Мөҗтәһидләрнең үзләренең мәзһәб баш[лык]лары булачагын дәгъва итүләре шулай торсын, хәтта моннан мәгълүматлары булачагы шөбһәле. Ибне Хәнбәл мәзһәбе үзенең вафатыннан йөзләр еллардан соң төзелгән. Хәтта кайберәүләр моның мәзһәб имамы булуын башлыча инкяр итәләр. «Безнең дәлилебезне белмәгәндә, сүзебезгә иярмәгез!» – дигән имам Шафигый һәм [шул ук сүз] Әбү Хәнифәдән риваять ителә. Инде чакыру кайсы җирдә калды?

2. Икенче соравыгызга караган бәхәсләрне «Әл-гасрел-җәдид» журналында басылган «Монасыйб диния» китабында тәфсилләп сөйләнгән иде. Искә алынган әсәрне укысагыз, шаять, таләп ителгән җавап табылыр.

*Шура. – 1908. – № 11. – Б. 358.*

## [ГАЛӘМНӘР ТУРЫНДА]

**Аксудан:**

Кайбер әсәрләрдә «Аллаһ Тәгалә унсигез мең галәм ялартты» дип язылган сүз бар. Госман Хәлил әфәнде дә моны риваять иткән (Фәне тарих. – Б. 2.). Бу сүзнең асылы бармы?

*Мөгаллим Ибне Җиһандар Фәйзрахман.*

**«Шура»:**

Бар итүчесе [Аллаһ] тарафыннан ачык хәбәр булмаганлыктан, мондый нәрсәләрне белү мөмкин булмаса кирәк. Коръән шәриф: «Раббыңның гаскәрләрен Аллаһтан башка һичкем белмәс», «Ул сез белмәгән нәрсәләрне бар итте», – ди. Язган сүзегез исраилият [яһүдләр китапларындагы сүзләр] булмасын! Мөхтәрәм философ Әбү әл-Галяә әл-Мәгарри: «Әй, кешеләр, Аллаһ ничә орбиталар бар иткән, йолдызлар, кояш һәм ай шулар буенча йөриләр», – дип, чиксез бар ителгән нәрсәләрне санап бетереп булмаячагын сөйли.

*Шура. – 1909. – № 2. – Б. 62.*

## [ГАУҖ БИНЕ ГАНАК ТУРЫНДА]

**Троицк шәһәреннән:**

Гауҗ бине Ганак бер фәрсәх [миль] зурлыгында булган тауны күтәреп, Муса пәйгамбәр кавеме өстенә барган һәм ташларга ниятләгән сәгатьтә тау, тишелеп, Гауҗ муенына камыт рәвешендә төшкән һәм бу сәбәпле вафат булганы китапларда күренә. Бу тау кайсы мәмләкәттә булган һәм хәзер бармы?

**«Шура»:**

Гауҗ хакында булган хикәяләрнең асылы булу шулай торсын, хәтта үзе дә хыялый бер шәхес булып, дөньяда булганы юк, диләр. Һәрбер адәмнең сүзенә ышану дөрес булмаган кебек, һәрбер китап сүзенә дә ышану булмас.

*Шура. – 1909. – № 2. – Б. 63.*

## [ПӘЙГАМБӘР КАБЕРЕН ЗИЯРӘТ КЫЛУ ТУРЫНДА]

**Галҗат авылыннан:**

Хөрмәтле Рәсүл каберен зиярәт кылу фарыз [гаять мәҗбүри], важиб [мәҗбүри], сөннәт [пәйгамбәр үтәгән яхшы гамәлләр] һәм яхшы дип табылган өлешләрнең кайсысына керә?

*Мөгаллим Әмир бине Габделкаһһар.*

**«Шура»:**

Соравыгыз – саф дини бер мәсьәлә. Дини бер мәсьәләләрне камил сурәттә язу җыентыкның [журналның] программасына һәм рөхсәтенә керсә дә, максат асылы әдәбиятка хезмәт итү булганлыктан, мондый мәсьәләләргә чумарга ниятебез юк. Җыентыкның кечкенәлеге һәрберсенә дә тәфсилләп керешүдән тыя. Шулкадәр дип белербез ки: Мәдинә шәһәрендә булган вакытта раузаи мотаһһараны [пәйгамбәр каберен] шәригатьчә зиярәт кылу олы кардәшлек һәм иң яхшы табылган эш икәне хакында гыйлем ияләре арасында низаг юк. Әмма ерак җирләрдән бу ният белән сәфәр чыгу хакында байтак сүзләр бар. Ике шәех [Бохари һәм Мөслим] тарафыннан риваять ителгән «Өч мәчеткә генә сәфәргә чыгарга ярый: Хәрам мәчете, Әкъса мәчете һәм минем мәчетем [Мәдинәдәге мәчет]» хәдис шәрифе шәрехендә Ибне Хәҗәр,

Касталани, Нәвави тарафыннан бирелгән аңлатуларның җыелмасыннан бер нәтиҗә чыгару мөмкин булыр. Бу әсәрләр басылган булганлыктан, хәзер һәр кеше өчен булдыру мөмкин. Замандашларыбыздан булып та, [һиҗри] 1317 елда вафат булган Багдад мөфтие Ногман әл-Алуси «Җәләъ әл-гайнәйн» исемле әсәрендә бу турыда гаять тәфсилләп, бәхәс кылган. Мөрәҗәгать итәр булсагыз, файдаланырсыз. (Фәтх әл-бәри. – Т. 3. – Б. 42; Касталани. – Т. 3. – Б. 24; Нәвави. – Т. 7. – Б. 316–415; Җәләъ әл-гайнәйн. – Б. 315.

*Шура. – 1909. – № 5. – Б. 154–155.*

## [ЛОТЕРЕЯ ТУРЫНДА]

**Кучкар приискасыннан:**

Мәктәпләр файдасы һәм балаларыбызны укытырга ярдәм булсын өчен, лотерея уйнау бик файдалы булыр иде. Мондый нәрсә ислам галәмендә булганы бармы? Һәм дә шәригать карашында дөресме, юкмы? Әгәр дә дөрес булса, моның мәшәкатьләрен өсләренә алырга вәгъдә бирүче адәмнәр бар. Шул сәбәпле, «Шура»да җавап язылуы сорала.

*Мөхәммәдгариф Садыйкый.*

**«Шура»:**

Лотерея «Маидә» сүрәсе (92 нче аять) белән тыелган, «мәйсәр»нең үзе булса кирәк. «Мәйсәр» сәбәпле хасил иткән нәрсәләрне гарәпләр үзләренә тотмыйлар, бәлки фәкыйрьләргә бүләк итәләр иде. Шуның белән бергә, Коръән шәриф бу гамәлдән тыйды. Моның бер хикмәте дә кешеләргә мал оту нияте белән түгел, бәлки ләззәт, мәхәббәт белән фәкыйрьләр өчен (ярдәм итү тиешлеге булса кирәк. Ул тәкъдирдә, мөселманнар мәктәпләргә оту нияте белән түгел, бәлки асыл гыйлемгә мәхәббәт тотуларыннан һәм сөюләре өчен ярдәм итү) тиешле икәне аңлашыла. Кайберәүләр:

««Мәйсәр» адәмнең тәрбиясен боза, ялкаулыкка һәм эшсезлеккә гадәтләндерә, шулай ки, аның бәрабәренә килгән файда зарарының уннан беренә дә алмашы булмас. Шул җәһәттән, хәтта, бер карашка, файдасы өметле булган «мәйсәрләр» дә катгый сурәттә тыелды», – диләр. Фәкать Мисырда булган «Әл-гурвәт әл-вәсикый» исемле ислам хәйрия җәмгыятьләренең һәрвакыт «Әй, уңыш» игъланы газеталарда күренә. «Әй, уңыш» исә бездә булган лотереяның үзе. Күпчелек әгъзасы зур галимнәреннән гыйбарәт булган бу җәмгыятьтә мондый хәлләр булуның сәбәбен һаман белә алмадык.

*Шура. – 1909. – № 6. – Б. 186.*

## [ӘЮП ҺӘМ ШОГАЕП ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТУРЫНДА]

**Чиләбе шәһәреннән:**

Кайбер китапларда хәзрәте Әюб галәйһиссәлам хаста булып, тәне череп һәм кортлап беткәне риваять ителә. Кайбер урыннарда хәзрәте Шогаеб галәйһиссәламнең сукыр булганы күренә. Шул ук вакытта, Хөсәен әл-Җәсәри хәзрәт: «Пәйгамбәрләр халыкны нәфрәтләндерәчәк гаепләрдән пакь иде», – дигән. Бу мәсьәләдә кайсы тараф хәбәрен өстен итү яраклы булыр?

*Мөгаллим Габделмәлик.*

**«Шура»:**

Бер кешенең казада булмавы, шайтан котыртуына очрамавы, шулай ук кавеме эчендә зәгыйфь бер хәлдә булмавы гаеп булмаган кебек, халыкны нәфрәтләндерәчәк нәрсәләрдән дә түгел. Бу ике пәйгамбәр хакында Коръән шәриф хәбәр биргән нәрсә – менә бу кадәр. Моннан артыгы кайбер хәдисләрдә булса да, искә алынган хәдисләрнең кайберләре Ваһеб бине Мөнәббиһтән риваять ителгәне, кайберләре Ибне Габбас хәзрәткә соңгы чик булып, мәрфуг [пәйгамбәргә то-

ташкан хәдис] булмавы, мәрфуг булганнарның тоташу чылбырында Җүвәйбәр бине Сәгыйдь исемле бер зат булуны сәбәп [итеп] күрсәтеп, хәдис белгечләре кабул итмәгәннәр. Бу сәбәпле, Хөсәен әл-Җәсәринең «Шогаебның сукыр булуы һәм Әюб кыйссасындагы нәфрәтләндерә торган хикәяләр нык түгел һәм алар ялган» эчтәлегендә булган сүзе, иншалла, лаеклы [рәвештә] кабул булыр.

*Шура. – 1909. – № 7. – Б. 216–217.*

## [КОРЪӘН ТУРЫНДА]

**Күкчәтаудан:**

Коръән кәрим хәзрәте Госман заманында язылган язудан икенче язуга нинди вакытта күчерелде? Нокта һәм хәрәкәт кайсы заманда куелды?

*Ф. Чәркәси.*

**«Шура»:**

Куфи язуының үзгәрүе әл-Моктәдир билләһ вәзире булган Әбү Гали Мөхәммәд бине Гали бине Моклә заманында һәм аның тырышлыгы белән булган (Әл-Фәхри. – Б. 244). Коръән шәриф язуы да, табигый, бу вакытта үзгәргән була. Иң элек нокта һәм хәрәкәт куючыларны билгеләү хакында тарихчылар һәм әдәбият галимнәре арасында каршылык күп. Кайберәүләр: «Хәрәкә, сәкеннәр, нокталар электән [үк] бар иде, фәкать Коръән язган вакытта, сәхабәләр [пәйгамбәрне күреп, аңа ияргән кешеләр], болардан аеру белән, саф хәреф белән генә яздылар», – диләр. Нокта маддәсенә караган «Укъянус» авторы да бер вакыйга күчерә, «Әт-Тәкъйид» маддәсенә мөрәҗәгать итеlә.

*Шура. – 1909. – № 12. – Б. 373–374.*

# [ӘКЪСА МӘЧЕТЕ ТУРЫНДА]

**Вятка губернасыннан:**

«Коран – первоначальный источник магометанского вероучения» исеме белән русча язылган бер китапта (190 нчы бит) 17 нче сүрәнең беренче аяте ахырына кадәр тәрҗемә ителгәннән соң, авторы тарафыннан: «Әкъса мәчете («Бәйт мөкаддәс») Мөхәммәд галәйһиссәламнән 500 ел элек җимерелгән иде. Инде Мөхәммәд галәйһиссәламнең анда баруы һәм Буракны бәйләп куеп, намаз укуы ничек мөмкин булсын?» – дип бер бәхәс кылынган һәм дә: «Мөселманнар бүген ничек булсалар, элекке заманда да тарих гыйлеменә бик фәкыйрьләр иде. Шуның өчен һәрбер сүзгә ышаналар», – дип ачы сурәттә хурлаган. Мондый русча китаплар, бик күп таралу сәбәпле, ихтимал ки, кайбер кешеләргә зарар бирер. Шуның өчен берәр җавап бирелеп кителсә, яман булмас иде.

*М.*

**Шура:**

Әкъса мәчетенең җимерелүе үзе бу сүрәдә югарыда искә алынган аятьтән соң ишарә юлы белән бәян ителгән. Шуның өчен «Хәрам мәчетеннән Әкъса мәчетенә барды» диюдән максат – Мәккәдән Кодескә барды, дип әйтү булса кирәк. Хөрмәтле аятьтә бина эченә кергәнлеге бәян ителмәгән. Шуның белән бергә, «мәчет» сүзе – кирәк бинасы булсын, кирәк булмасын, абсолют рәвештә «гыйбадәт урыны» дигән [сүз]. Бу тәкъдирчә, хөрмәтле Рәсүл Әкъса мәчетенең урынына, бәлки, нигезе эченә кергән була. Мөселманнарның тарих гыйлеменә фәкыйрь икәнлекләре бу мәсьәләнең кайсы ноктасыннан аңлашыла, гаҗәп? Без моны белмәдек.

*Шура. – 1909. – № 16. – Б. 505.*

## [ТЮЛЕНЬ МАЕ ТУРЫНДА]

**Новая Казанкадан:**

Безнең Новая Казанка сәүдәгәрләре диңгез тарафыннан тюлень (ат балыгы) мае китереп, поты 8 сумнан саталар. Арык һәм корчаңгы ат һәм дөяләр моннан берәр кадак ашаса, сәламәтләнеп, симереп китәләр, кайберләре, моны күтәрә алмыйча, үләләр. Менә бу майны ашаган хайваннарның итләре хәләл булу хакында муллаларыбыз каршылыкка керәләр. Гади халык исә, муллалар каршылыклары сәбәпле, аптырап йөри. Бу – бер. Икенчесе – бу заманда иҗтиһад [нинди дә булса дини мәсьәләдә, Коръән һәм хәдисләргә таянып, үзлегеңнән хөкем чыгару] беттеме? Бетсә, кайсы заманда бетте? Бетмәсә, моның өчен ни кадәр гыйлем шарт икәне мәгълүмме? Бу гыйлемнең мизаны нинди нәрсә? Өченчесе – үзен хәнәфи мәзһәбендә дип йөрүче кеше өчен башка бер хак мәзһәбкә иярү белән гамәл кылу дөресме?

*Габдулла бине Әхмәд.*

**«Шура»:**

Өченче һәм икенче сорауларыгыз өчен [Ризаэтдин Фәхретдиннең] «Монасыйб диния» исемле китапка мөрәҗәгать итсәгез, бәлки, файда алырсыз. Беренче сорауга булган шөбһә, ягъни тюлень мае эчкән ат һәм дөя, чалынганнан соң итләренең хәләл булуында шөбһә асыл ат ите ашауда булган шөбһә дәрәҗәсендә – юк. Муллалар, әгәр дә каршылыклы мәсьәләләр белән шөгыльләнергә теләсәләр, тюлень мае ашаучы хайваннар хакында түгел, бәлки асыл тюленьнең үзе хакында булган каршылыкларны тикшерсәләр, зарар булмас иде. Имам Мәлик һәм имам Шафигый су хайваннарын абсолют рәвештә хәләл дигәннәр. Фәкать бер риваятьтә имам Мәлик су дуңгызын чыгарма итә, имам Шафигый пакь булуын шарт итә. Бу язылган нәрсәләр, бары тик бер фикер-

дән гыйбарәт булып, шәригать фәтвасе түгел. Әгәр дә максат шәригать хөкемнәрен белү булса, ышанычлы галимнәрнең китапларына мөрәҗәгать итәрсез.

*Шура. – 1909. – № 17. – Б. 536.*

## [СӘДАКА ҖЫЮЧЫЛАР ТУРЫНДА]

**Екатеринбург:**

Гәүдәләре сәламәт һәм хезмәткә көче җиткән хәлдә, саф кәсеп йөзеннән сәдака җыеп йөрүчеләргә каршы сүз сөйләү шәригать һәм әдәп җәһәтләреннән тыелганмы? Мондый сүз сөйләүчеләргә протест белдерергә мәчеттә имамлык итүче кешенең хакы бармы?

*Һади Таһири.*

**Җавап:**

Өммәтнең тормышын тәэмин итү һәм икътисади хәлләрен үстерү кебек гаять бөек максатларга нигезләнгән исламда сәдака канун ителгән иде. Фәкать соңгы вакытларда бу кагыйдә начар идарә итү бәласенә очрады, исламның максатына табан-табанга капма-каршы булган ялкаулык үрчүенә һәм бөтен милләтне хәерчелек кәсебенә салыштырырга сәбәп ителде. Һәркөн йорттан йортка йөрү һәм һәрбер кергән хәерчегә бер шакмак шикәр яки бер сынык икмәк бирү белән өммәтнең иҗтимагый хәле төзәлү һәм тормышы тәртипкә керү ихтималы юк. Шуның өчен мөселманнар бер көн элек бу сәдака ысулын яраклы рухка куярга тиеш (хәзер Төркиянең депутатлар палатасында бу мәсьәлә хакында фикер алышына). Бүреләргә шәфкать итү сарыклар өчен җәбер булачак кебек, тәннәре сәламәт һәм хезмәткә көчләре җиткәннәргә сәдака бирү – асыл сәдакага мохтаҗ булучыларга җәбер-золым. Шуның өчен тиешсез кешеләргә бирүнең за-

рарлы икәнлеген бәян итүчегә каршы чыгарга ни имам, ни ахунның хакы булмаса кирәк.

*Шура. – 1910. – № 1. – Б. 23.*

## [АДӘМНЕҢ СӨЙЛӘШКӘН ТЕЛЕ ТУРЫНДА]

**Каслиев:**

Хәзрәте Адәм һәм аның балалары кайсы тел белән сөйләшкәннәр иде?

**Җавап:**

Тел галимнәре, хәзрәте Адәм һәм аның балаларының телләре дөнья йөзеннән югалган, дип уйлыйлар.

*Шура. – 1910. – № 2. – Б. 62.*

## [КИЕМНӘР, ФОТОГРАФИЯ, ФОНОГРАФ ТУРЫНДА]

**Чапурин:**

Мөселманнар өчен нинди киемнәр билгеләнгән? Фотограф белән рәсем чыгарту дөресме? Фонограф аркылы көйләр тыңлау мөбахмы [ярыймы]? Бу сорауларның җавабы безнең өчен зарур. «Мәгълүмат» журналына йөкләмичә, җавабы «Шура»да язылуы сорала.

*Исхак Таҗетдинов.*

**Җавап:**

Мөселманнар өчен кияргә һәм файдаланырга ярамаган киемнәр фикыһ һәм хәдис китапларында бәян ителгән. Шуннан башка киемнәр, билгеләнеп түгел, бәлки асыл мөбахлыкта [ярауда] дөрес. Якынча егерме ел булыр, гыйлем алган адәмнәребез указ алу өчен фотограф белән рәсем чыгартып

торалар. Гомуми бер яхшылыкны үтәү нияте белән хосусый адәмнәрнең хәрам эш эшләүләренә шәригатьнең мөмкинлек бирүе булмаса кирәк. Димәк, хәрам эш кылыр өчен, указ алу гозер түгел. Шуңа күрә: «Әгәр дә рәсем чыгарту дөрес булмаса, монычча гыйлем ияләре бу гөнаһка төшмәсләр иде», – дип уйланыла. Фонограф мәсьәләсе тыңлау мәсьәләсеннән [бер] тармак булган өчен, шуның хөкеменә ияргән. Фәкать әдәп һәм тәрбиягә каршы булганы өчен, Коръән шәриф һәм хәдисләрне фонограф белән файдаланудан һәм тыңлаудан сакланырга тиешле булса кирәк. Аллаһ дөресен белүчерәк.

*Шура. – 1910. – № 2. – Б. 62.*

## [АЙ ЯРЫЛУ ТУРЫНДА]

**Җамбити:**

Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә могҗиза буларак ай ярылуы дөресме? Дөрес булса, [ай кую] галәмәте кабул ителсә, сәбәп шул вакыйганы хәтерләү булмасмы?

*Мулла Насретдин Хуҗаши.*

**Җавап:**

Мөселманнар тарафыннан язылган элекке әсәрләрдә ай ярылу мәсьәләсе тәфсилләп искә алынган. Шуларга мөрәҗәгать итүчеләр, әлбәттә, файда алырлар. Гыйздеддин «Әлмуафикъ»та могҗиза буларак ай ярылу хакында күп юллар белән килгән мәгънә барлыгын дәгъва итә. Тәшкил иткән галәмнәр хакында булган соңгы гипотезалар таралганлыктан, барлыкка килгән кайбер соңгы ислам галимнәре Коръән кәримдә булган «Ай ярылды» җөмләсенә «Кояштан ярылды» дип мәгънә биреп, аннан соң булган аятьне яңарту булу ихтималын да йөртәләр. Һәрхәлдә, Төркия һәм төрекләрнең ай

галәмәтен кабул итүләрендә булган сәбәп ачык мәгълүм түгел, ихтимал ки, киләчәктә мәгълүм булыр.

*Шура. – 1910. – № 5. – Б. 152.*

## [ИБНЕ ТӘЙМИЯ ТУРЫНДА]

**Әркәй:**

Кайбер адәмнәр Тәкыеддин ибне Тәймияне хаклык иясе түгел, бәлки [Аллаһны] гәүдәләндерүче иде, диләр. Бу сүз дөресме? Ибне Тәймиянең тәрҗемәи хәле «Шура»да язылса, гүзәл булыр иде.

*Садретдин Хәмиди.*

**Җавап:**

Максатыгыз Ибне Тәймия хакында дөрес бер фикер хасил итү булса, читләр тарафыннан сөйләнгән сүзләргә ышану җирендә турыдан-туры үз әсәрләрен укыгыз. Шулвакыт белерсез ки, Ибне Тәймия мондый нәрсәләрдән пакь. Ибне Тәймия тәрҗемәи хәле бик озын язылырга тиеш. Аны «Шура» битләре күтәрә алмас. Гомеребез сүздә торса, мөстәкыйль сурәттә китап төзергә фикеребез юк түгел.

*Шура. – 1910. – № 6. – Б. 188–189.*

## [ГРАММОФОН, ТЕШ ЯМАТУ, ТЕШ КУЙДЫРУ ТУРЫНДА]

**Алмата:**

Граммофон белән Коръән шәриф укыту, шулай ук тешләрне ямату һәм тимер тешләр куйдыру шәригать каршында дөресме? Бу турыда бик күп сөйләнсә һәм бик күп язылса да, без «Шура»да да берәр җөмлә язылуын телибез.

*Кәлимулла.*

**Җавап:**

Хөрмәткә каршы урыннар һәм хөрмәткә каршы рәвешләрдән башка сурәттә Коръән шәриф укудан тыярга сәбәп юк. Гыйбадәт һәм игътибар алу нияте белән Коръән шәриф уку һәм тыңлау – фазыйләтле бер эш. Фәкать, уебызга күрә, граммофоннар гыйбадәт кылыр өчен басылган нәрсәләр түгел, гадәттә дә, аның тирә-ягына вәгазь алу һәм Аллаһка гыйбадәт кылуны күрсәтү өчен түгел, бәлки башка ниятләр өчен җыелалар. Кыскасы: Коръән шәриф һәм гыйбадәттән саналган нәрсәләрне граммофоннарда файдалануны дөрес күрү җөмләсеннән түгелбез. «Шура» тарафыннан язылачак сүз – бу. Әгәр дә мәсьәләнең Аллаһ Тәгалә һәм Рәсүлуллаһ каршында булган хөкемне бәйләү ниятендә булсагыз, моны исә ияләренә тәкъдим итәрсез.

Теш ямату һәм тимер тешләр куйдыру сәламәтлек саклау һәм медицина кагыйдәләренә ияргәнлектән, шәригать белән мөнәсәбәте юк. Теш ямату һәм теш куйдыру хакында низаглашу «Мөселманнар өчен сәламәтлек саклау кагыйдәсенә игътибар итү дөрес түгел һәм, хаста булганда, дәвалану тыелган» дип әйтү булганлыктан, бу турыда галимнәр тарафыннан сүз булмаса, башкалар тарафыннан булмас.

*Шура. – 1910. – № 10. – Б. 309.*

## [НӘҮРҮЗ ТУРЫНДА]

**Тукмак:**

Безнең бу тарафта Нәүрүз бәйрәмен [бәйрәм] итү мөселманнар арасында гомуми бер гадәт булган. Хәтта моны ишаннар да [бәйрәм] итәләр. Мәктәп-мәдрәсә шәкертләре, гомумән, дәрестән азат ителәләр. Шул ук вакытта, фәтва китапларында Нәүрүз бәйрәмен [бәйрәм] итүчеләр хакында яман сүзләр язылган. Бу турыда берәр нәрсә язылса, зарар булмас иде.

*Гайсә Төркестани.*

**Җавап:**

Дини бәйрәмнәрнең вакытларын, саннарын шәригать үзе билгеләгән, моны арттырырга һәм киметергә, урыннарыннан күчерергә һичкемнең хакы юк, монда хуҗа булу мөмкин түгел. Әмма моннан башка дөньяви бәйрәмнәрне [бәйрәм] итү-итмәү, урыннарында тоту яки күчерү турында шәригать тарафыннан әмер дә, тыю да юк. Монда халыкларның үзләренә ихтыяр. Әгәр дә хәрам нәрсәгә тоташтырмаса, аны [бәйрәм] итүдән зарар булмас. Шуның өчен Нәүрүзне мәҗүсиләрнең дини бәйрәмнәре булу сәбәпле, хөрмәтләп ясалмаса яки ислам диненә махсус бәйрәм исеменнән [бәйрәм] ителмәсә, бәлки шул төбәк халкының үзләренең хәлләренә яраклы ял көне булганлыктан, бары тик бер гадәт юлы белән ясалса, шәригать исеменнән тыярга юл күренми. Дин исеменнән Гашура көнен бәйрәм итүгә, гыйбадәт ышануы белән Хуҗа Әхмәт Ясәви һәм Хуҗа Баһаветдин каберләренә ерак җирләрдән сәфәр чыгуга караганда, Нәүрүз бәйрәме, Сабан туе ясауда җаваплылык азрак булса кирәк. Шәригать каршында иң зарарлы нәрсә – динне гадәт [дип] белү, гадәтне дин итеп тоту. Менә моннан саклану тиешле.

*Шура. – 1910. – № 12. – Б. 380.*

## [ХАВАНЫҢ КАБЕРЕ ТУРЫНДА]

**Казан:**

Җиддә шәһәрендә ифрат дәрәҗәдә озын булган бер кабергә, анабыз Хава (Аллаһ анннан риза булсын) кабере дип, зиярәт кылдырдылар. Телгә алынган зат исә бу дәрәҗәдә озын буйлы булганмы?

*Мосафир Габделкәрим Хөсәени.*

**«Шура»:**

Хаваның (Аллаһ анннан риза булсын) кабере һәм озынлыгы, шулай ук Җиддәдә аңа нисбәтле кабер хакында бер нәрсә укыганыбыз хәтеребездә юк. «Көтебе синттә» [алты хәдис җыентыгы] һәм дә сира [пәйгамбәр томыш юлы], тарих китапларында искә алынмаган бер кабер хакында, нинди дәлилгә таянып, Хава кабере дип хөкем ителер һәм моңа кемнәр ышаныр?

*Шура. – 1910. – № 14. – Б. 439–440.*

## [ХАҖ ТУРЫНДА]

**Зайсан:**

Бирәчәге күп була торып, халыктан акча сорашып, хаҗ кылган кешедән хаҗ фарызы [мәҗбүрилеге] төшәрме? Безнең бу җирдә бу турыда сүз күп.

*М. Габдов.*

**«Шура»:**

Фарыз төшү рөкен [нигез] һәм шартларны җиренә китерүдән гыйбарәт. Шуның өчен мәгълүм сәбәп белән гамәл кылучы хакында «Фарыз төшмәде» дияргә юл юк. Ләкин хаҗга бару өчен сорашып йөрү дөрес бер эшме? Менә мәсьәлә – монда.

*Шура. – 1910. – № 14. – Б. 440.*

## [ДИНИ МӘЗҺӘБЛӘРГӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА]

**Атбасар:**

Коръән шәрифтә бәян ителгән ышанырга тиешле нәрсәләргә иман китереп тә, ышану һәм гамәл мәсьәләсендә Рәсүлуллаһ хәзрәттән соң мәшһүр булган мәзһәбләрдән [ис-

лам хокук системасына нигезләнгән дини юнәлешләрдән] берәрсенә иярмәгән кешеләр, шәригать хөкеменә күрә, кяфер булырлармы яисә зур гөнаһ ияләреннән саналырлармы?

*Госман Габдерәшидов.*

**«Шура»:**

Мәзһәбләрнең берсенә ияру асыл иманнан яки камиллегеннән бер өлеш, дип гыйлем ияләре арасында дәгъва кылучы барлыгы безгә мәгълүм түгел. Шуның өчен Мөхәммәд галәйһиссәламне раслаучылар һәм танучылар – мөэминнәр. Теләсәләр – мәзһәбләрнең берсенә иярсеннәр, теләсәләр – иярмәсеннәр. Монда шөбһәләнергә урын юк.

*Шура. – 1910. – № 19. – Б. 611.*

## [ТУЙ ТУРЫНДА]

**Пируфсык:**

Башка җирләрдә булган кебек, безнең бу җиребездә дә мөселманнар, туй чыгымнарын үлчәүсез иткәннәре сәбәпле, һәркөн эштән чыгып торалар. Кыланусыз һәм дә бик кыланусыз сурәттә туй ясау мөселманнар өчен дөрес эшләрдәнме? Моңа берәр юл күрсәтү мөмкинме? Әгәр дә берәр төрле юл күрсәтелсә, бүген булмаса, киләчәк бер көндә, бәлки, кабул ителер иде. Бу мәсьәләдә «Шура»да берәр нәрсә язылса, яхшы гына түгел, бәлки бик гүзәл булыр иде.

*Әхмәдҗан Габдуллин.*

**«Шура»:**

Электән килгән гадәтләрне һичбер милләт җиңеллек белән бетерә алмас. Шуның өчен туйларда булган кыланулар, исраф итүләр һәм ясалмалыкларның элекке һәм яңалары

тиз заманда бетү ихтималы аз. Тик, бер тарафтан, гаиләләребез арасында тәрбия гомумиләшеп, олы хисләр мәйдан алса һәм, икенче тарафтан да, Гоголь мәсләгендә һәм аның кебек тасвирлауга оста һәм иң вак кадәр нәрсәләрне тәнкыйтьләргә көче җиткән язучылар пәйда булып, килешсез кыланышларны акыл ияләренең күзләренә күрсәтеп, гарьләндерсәләр, ихтимал, бер нәтиҗә күренер. Милләтне ташлатырга сәбәп булачак эшләрдә фәкыйрьләр байларга, түбән катламнар югары катламга, яшьләр картларга үлчәп кенә иярү гадәтен чыгарсалар да, яхшы бер эш булыр иде. Һәрхәлдә, бу мәсьәлә хакында яшьләр үзләре мөстәкыйль һәм җитди фикерле булып, үз киләчәкләрен һәм үз мәнфәгатьләрен башкаларның кәефләре өчен фида итмәскә тиеш. Бер мәҗлестә егерме каз белән бер кач санда үрдәк, күркә башына җитүдән исә егет белән кыз өчен бөтен әсбабы белән бер самавыр яисә бер дюжина урындык иясе булулары хәерлерәк.

*Шура. – 1910. – № 23. – Б. 725.*

## [ЧАЛМА, СӘДАКА ТУРЫНДА]

**Минзәлә:**

1. «Чалма белән укылган бер рәкәгать намаз җитмеш рәкәгать намазга һәм чалма белән укылган бер җомга [намазы] фәлән кадәр җомга [намазларына] савап җәһәтеннән бәрабәр килер» эчтәлегендә сүзләр күренә. Боларның асыллары бармы?

2. Милләт һәм дингә хезмәт иткәннәре өчен бай муллаларга важиб [мәҗбүри булган] сәдака бирелсә, бирүче өстеннән фарыз төшәрме?

*Б. авылыннан имам Таһир.*

**«Шура»:**

1. Чалма кию саваплы эш һәм гыйбадәт икәне хакында «Көтебе ситтә»дә бер хәдис булсын – күрә алмадык. Хөрмәтле Рәсүл чалма кигән булса, гадәткә нигезләнгән бер нәрсә булган, дип уйлыйлар.

2. Биреләсе сәдака Коръән шәрифтә ачык сурәттә бәян ителгән, ләкин болар арасында милләт һәм дингә хезмәт итүче бай муллалар дөрес булырлык рәвештә бер бирү бәян ителмәгән.

*Шура. – 1911. – № 1. – Б. 26.*

## [ТӘМӘКЕ, ЧӘЙ ТУРЫНДА]

**Минзәлә:**

Миндә булган бер җыентыкта «Мәшһүр тәмәкенең хәрам булуын бәян итү» дип тәмәке хакында гарәп теле белән язылган бер мәкалә язылган. Моның эчтәлеге исә гүя тәмәке хөрмәтле Рәсүл заманында булган, олы бер ачлык булгач, халыклар тәмәкедән тәүбә иткәннәр һәм дә Рәсүлуллаһ хәзрәтнең «Киләчәк заманада бер төркем тәмәке тартыр, алар миңа өммәтлекне дәгъва итсәләр дә, алар минем өммәтем түгел» диюеннән гыйбарәт. Ахырында, «Тәфсир мәкънәгый әл-кәбир»дән алынды, дигән. Бу нинди тәфсир һәм бу вакыйга дөресме?

**«Шура»:**

Чәй белән тәмәке гасры сәгадәттә [пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре яшәгән заманда] юк иделәр, аларны куллану гадәте соңгы вакытларда чыккан. Һәрбер җыентыкта язылган сүзләргә ышану дөрес түгел. Шәригать ысулы мәгълүм, хәләл белән хәрам ачык бәян ителгән. Хәрамны хәләл дип ышану белән хәләлне хәрам дип ышану – икесе бер хөкемдә.

*Шура. – 1911. – № 2. – Б. 56.*

## [УТ ПУМАЛАСЫ ТУРЫНДА]

**Тингинский:**

Кайбер вакыт[та] ут пумаласы кебек нәрсәләр күренә. Гади халык ышануына күрә, бу эш Аздакый исемле бер хайван булып, хатынсыз ирләргә хатын, ирсез хатыннарга ир булып йөрүдә икән. Моның асылы бармы?

*Ибраһим Юманколов, Кавказиядә мөгаллим.*

**«Шура»:**

Моннан максат нәрсә икәнен аңлап бетермәдек. Аяз кичләрдә яшен шикелле күренә торган нәрсә күздә тотыладырмы яки һавада очып йөрүдә булган утлармы? Әүвәлгесе фән әһелләренең сүзләренә күрә, бик ерак җирләрдә булган яшеннәрнең чагылышы (шәүләсе) булып, соңгылары исә – ватылган планеталарның вак кисәкләре.

*Шура. – 1911. – № 2. – Б. 56.*

## [ИСЕМНӘР ТУРЫНДА]

**Уфа:**

Сәхабәләр һәм мәшһүр табигыйннар [сәхабәләрне күргән һәм алардан белем алган кешеләр] исемнәре арасында «дин» сүзенә изафә кылынган исемнәр күренми. Мөселманнар кайсы вакытлардан башлап «дин» сүзенә изафә кылып, Мисбахетдин, Сираҗетдин, Хәйретдин, Фәхретдин, Таҗетдин, Камалетдин, Садретдин кебек исемнәр бирә башлаганнар? Һичбер китапка яки журнал-газетага йөкләмичә генә, «Шура»да дөрес җавап бирүегезне үтенәбез.

*Әбү Хафс.*

**«Шура»:**

Франкларның мәшһүр затлары гади фамилия һәм нисбәтләр белән сөйләнгән кебек, сәхабә һәм табигыйн исемнәре дә кыланусыз кулланыла иде. Шекспир, Декарт, Мюллер, Флайшер, Саси, Пушкин, Толстой, Муромцев һәм башкалар үз мохитларында бөек адәмнәр булган кебек, Мәсрук, Сәгыйдь бине әл-Мөсәййиб, Галькамә, Катадә, Шәгъби, Тахави, Кәрхи һәм башкалар да – ислам галәмендә олуг остазлар. Соңра катышу тәэсире белән мөселманнар арасына Иран күпертүләре һәм аларда булган мактану гадәте кереп, таралды. Оренбург Духовное собраниесенә имтиханга баручы шәкертләрнең берсеннән күрмәкче икенчесе «остазым – мөдәррисләр терәге һәм өйрәнүчеләр горурлыгы» кебек гыйбарәләр язганнары шикелле, Иран арттырулары таралудан соң, мөселманнар да үзләренең ышанган кешеләренә Мөхьетдин, Шәрәфетдин, Зыяэтдин, Шәмсетдин кебек кушаматлар бирә башладылар һәм дөньяны да олуг кушаматлар белән тутырдылар. «Дин» сүзенә изафә кылынган исемнәр, хакыйкать хәлдә, соңыннан бирелгән кушаматлар иде. Риваятьләргә күрә, иң элек «дин» сүзе кушылып, кушамат бирелгән адәм Мөхәммәд бине әл-Хөсәени исемле бер зат булып, [һиҗри] 376 елда вәзирлек дәрәҗәсенә күтәрелү мөнәсәбәте белән, үзенә Заһиреддин дип кушамат бирелде. Шуннан күрмәкче, башкалар моның шикелле төрле-төрле кушаматлар бирергә керештеләр. Әмма Русия мөселманнары кушаматларны, атамаларны һәм рәсми мәртәбәләрне асыл исемнәрдән аера алмаганлыктан, шуларның һәрберсен исем дип уйладылар һәм, берсеннән берсе күрмәкче, балаларына кушканнар. Зыяэтдин исемле булып, ашап йөрүгә караганда, Тимер, Таш кебек исем алып, эшләп йөрү яхшырак.

*Шура. – 1911. – № 21. – Б. 663.*

## [«ДӘВЕР» ТУРЫНДА]

**Оренбург:**

«Асар» җыентыгында (Т. 1. – Б. 288) Дәүләтша бине Гаделша хәзрәтнең тәрҗемәи хәлендә югарыда күрсәтелгән затның үз фидиясе [мәрхүмнең үтәлмәгән фарыз гыйбадәтләре өчен бирелгән сәдакасы] хакында булган васыятен күреп, кайбер урыннарына төшенә алмадым. Беренче васыятендә җитмеш сум фидиясен «дәвер» [акча бәрабәренә мәрхүмнең гөнаһларын кемнеңдер үз өстенә алуы] белән бирергә әйткән. Фидияне «дәвер» белән бирү шәригатебездә катгый дәлил белән исбат ителгән шәригатьчә булган бер әмерме? Белгәнемчә, «дәвер» бер хәйлә булып, моның нинди юл куллануын һәркем белсә кирәк. Менә шул хәйләне куллану дөрес булырмы?

Икенче. Мәрхүм Дәүләтша хәзрәт фидия сәбәпле: «Безнең гөнаһыбыз алар өстенә куелмас, бәлки алар бары тик сәбәп булырлар», – дигән. Фидия малы «дәвер»сез дөрес кенә бирелгәндә, бу сүз дөрес булыр кебек булса да, «дәвер» белән бирелгәндә, ничек дөрес булыр икән? Минем бу рәвешле әйтүем күптән юкка чыккан бер кешенең сүзләрен ялгыш-хатага чыгару булмый, бәлки хакыйкатькә җитү. Янә шул җирдә үк «Гаилә, угыл һәм кызлар хакында булган гаепләрем өчен «дәвер» иттерәсез» дигән сүзгә бер дә төшенә алмадым. Менә шөбһәләнүләрем шул җирләрдә булып, мөмкин булганча, ачык бер җавап бирелүен өмет итүдә идем.

*Китапханә мөдире Шакирҗан Сәгъди.*

**«Шура»:**

Шәригать хөкемнәрендә, Дәүләтша хәзрәт түгел, бәлки шәех Төрекмәни, хәтта Нәкышбәнд, Әхмәт Ясәви һәм Бәдәви кебекләрнең гамәлләре дә дәлил түгел. Искә алынган васыятьнамә «Асар»да сөйләнсә, халык гамәл кылсын өчен

түгел, бәлки бер мәгълүмат булганлыктан язылган. Фидия мәсьәләсе һәркемгә мәгълүм булганга күрә, ике өлешкә аерыла. Берсе – шәригатьтә дөрес булган асыл фидия, икенче өлеше аны «дәвер» юлы белән бирүдән гыйбарәт. Ураза хакында фидия бирү Коръән шәрифтә искә алынганлыктан, моның белән гамәл [кылу] дөреслегендә гыйлем ияләре арасында низаг юк. Низаг исә намаз фидиясе хакында. Кайберәүләр бу турыда шәригать иясеннән [пәйгамбәрдән] күчерелмәгәне өчен, моны, уй белән, дин төзүдән санап, тыйганнар. Кайберәүләр гомуми сәдака хакында булган фәрманнар астына (ясалмалык белән булса да) кертеп, файдасы фәкыйрьләргә кайтканлыктан: «Шаять, дөрес булыр, ягъни асыл бурыч кирәк бетсен, кирәк бетмәсен, намаз өчен фидия бирүчеләр кыяматтә җәзаланмаслар», – дигәннәр. Әмма фидияне «дәвер» юлы белән бирү хакында ислам хафизларында [Коръәнне яки хәдисләрне яттан белүчеләрдә] һәм борынгылар әсәрләрендә бернәрсә күрмәдек, мондый хәл сәләф [сәхабәләр, табигыйннар һәм борынгы изге галимнәр] заманында булмаган. Булырга да мөмкин түгел, чөнки мондый эшне гамәлгә кую, ваҗиб сәдакалар, аеруча катгый дәлилләр белән фарыз булган зәкятләрдән шундый хәйләләр белән котылу юлларын ачарга сәбәп була. Бу көнебездән бераз еллар элек вафат булган бер мөдәррис хакында: «Дәүләтле бер адәм булган хәлдә, төрле хәйләләр төзеп, зәкят һәм башка ваҗиб сәдакаларның һәртөрлесен кабул итә иде, меңнәр сум белән зәкят бирү һәм гошерне үтәү мәҗбүри булганда, бер шәкерте белән «дәвер» итеп, бер-ике сум белән бөтен фарызыннан котыла иде. Бу юл белән зур байлык хасил итте. Вафат булганда, йөз мең сум мирасы калды», – диделәр. Моның өчен бөек затларның берсе: «Хәйлә һичвакыт шәригать булмас һәм шәригать тә һичвакыт хәйлә белән җыелмас», – ди. Бу сүзләребез шәригать фәтвасе түгел, бәлки хосусый фикердән генә гыйбарәт.

*Шура. – 1911. – № 21. – Б. 664.*

## [ХӘДИСКӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА]

**Бохара:**

«Ибне Тәймия» исемле китапны укыдык, аннан-моннан исемен ишетеп йөргән Ибне Тәймия хәзрәте белән инде таныш булдык. Ләкин бу кешенең сүзләре һәм фикерләре дөрес булса да, кабул итү үзебезнең Әбү Хәнифә мәзһәбенә әдәпсезлек кылу булмасмы? Сезгә мәгълүмдер ки, имам Шафигый хәзрәт Әбү Хәнифәгә әдәп саклау өчен иртәнге намазында «көнут» [догасын] укымаганы билгеле. Без бу турыда шөбһәдә. Шөбһәбезне бетерсәгез иде.

*Х. Б.*

**«Шура»:**

Сөннәткә [пәйгамбәр юлына] яраклы бер сүз булса, сөйләүче кем булса да булсын, шуңа иярү тиешле. Әбү Хәнифәгә мәхәббәтегез булса, шулай эшләргә мәҗбүр сез, чөнки искә алынган зат һәрвакыт «Минем сүзләрем хәдисләргә каршы булса, хәдисләр белән гамәл кылыгыз!» эчтәлегендә нәсыйхәт иткән булган. Хәдискә иярү – хакыйкать хәлдә, Әбү Хәнифәгә иярү булып, Әбү Хәнифәдән күчерелгән сүзгә иярү аңа каршылык итү булыр. Бу сүз ачык сурәттә Әбү Хәнифәдән күчерелгән мәзһәб хакында. Әмма аннан ачык сүз күренмәгән нәрсәләр хакында хәдис һәм Сөннәткә иярү тиешле икәнлегендә дә икеләнергә урын юк. Имам Шафигый каршында, иртәнге намазда «көнут» [догасын] уку – сөннәт (Китәб әл-әм. – Т. 1. – Б. 76; Мохтасар әл-Мәзәни. – Т. 1. – Б. 77). Шафигый исә үз каршында сөннәт булган бер гамәлне вафат [булган] адәм янында да, сәламәт адәм янында да калдырмас. Мондый мөгамәләдә булу әдәп түгел, бәлки ялагайлану булыр, мондый эшләрне имам Шафигый, Әбү Хәнифә кебекләр эшләмәсләр. Искә алынган хәбәр [Әбү Хәнифәнең] казанышларын язучылар тарафыннан уйлап чыгарылган булса кирәк. Дөрес булган тәкъдирдә, шул вакытта имам Шафигыйга «көнут»ның сөннәтлеге мәсьәлә-

сендә бер шөбһә барлыкка килеп тә, шуңа нигезләнеп, калдырган булыр. Һәрхәлдә, бу мәсьәләне без тикшерәчәкбез, нәтиҗәсен исә форсаты килгәндә язсак кирәк, иншалла. Ибне Тәймия китабында булган кайсы сүзләр Әбү Хәнифәдән риваять ителгән мәзһәбләргә каршы? Монда булган кайсы сүзләр Әбү Хәнифәгә [карата] әдәпсезлеккә сәбәп булган? Боларны, хуш күреп, бәян итсәгез, шул хакта без тикшерер идек.

*Шура. – 1911. – № 22. – Б. 694.*

## [«ВАҺҺАБИ» СҮЗЕ ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Ибне Тәймия белән Ибне әл-Кайийм әл-Җәүзиянең ваһһаби мәзһәбендә дип ишетә идек. Шул ук вакытта, «Ибне Тәймия» исемле китапта Ибне Тәймиянең мәзһәбе сөйләнгән җирдә моңа ишарә ителмәгән. Ваһһаби мәзһәбе хакында мәгълүмат бирелсә иде.

*Х. Бигиев.*

**«Шура»:**

Әгәр дә һәр гасырның могтәбәр галимнәре тарафыннан язылган «диннәр һәм агымнар»га караган китапларга таянырга яраса, ислам милләте эчендә «ваһһаби» исемле дини бер мәзһәб юк. Әгәр дә моннан максат Нәҗед тарафларында ваһһаби дип билгеле халыклар булса, болар мөстәкыйль бер мәзһәб ияләре түгел, бәлки Әхмәд бине Хәнбәл мәзһәбенә нисбәт ителәләр. Боларның шөһрәтләренә, мәсләкләреннән бигрәк, Мисыр гаскәре белән сугышулары, дөресрәге дә, сәяси хәлләре сәбәп булган. Ике сугышучы милләт, хәтта чит дәүләтләрнең вәкилләре, газета мөхбирләре булып торган вакытта да, бик күп арттырулар, бәлки ялган һәм яла ягулар уйлап чыгардылар һәм бүген түгел, бәлки моннан бер гасыр элек һәм читләр күзләреннән аулак җирдә сугышуда булган

бу ике фирканың бер-берсе хакында сылтаган нәрсәләренең чиге юк иде. Һәр ике тараф үзләренең гаскәрләре «Без ни өчен мөселман кардәшләребез белән сугышабыз?» дип карышмасыннар, гайрәтләре сүнмәсен өчен, бер-берсе өсләренә ялалар ягып, көферлектә гаепләгәннәр һәм моңа мәҗбүр булганнар. Кыскасы: ваһһабилар белән мисырлылар арасында булган низаг дини түгел, бәлки сәяси һәм мәдәни. Яшь төркем өчен хезмәттән күп нәрсә юк. Әгәр дә болар камиллек хасил иткәннән соң, ислам тарихын фәнни рәвештә тикшерсәләр һәм дини фиркалар булу белән шөһрәт тапкан мәзһәбләрнең программалары хакында хөкем йөртсәләр, «күз булмаса да – күрдем, колак булмаса да – ишеттем» шикелле яңа хакыйкатьләр мәйданга чыгачак. Ислам тарихы белән фикыһ һәм әхлактан башкаларга караган хәдисләр – дөнья яратылганнан [алып] бу көнебезгә кадәр балта күрмәгән урманнар шикелле очсыз-кырыйсыз гыйлем хәзинәләре.

«Ваһһаби» сүзе безнең заманда бер өлеш руханиларыбыз өчен «юлга кертү» коралы булды. Халыкларны шушы сүз белән тәрбиялиләр. Ләкин ваһһабилыкны тикшерү боларның башларына кермәгән. Башларына кергән сурәттә дә, битараф бер мәсләк сайлаячаклары шөбһәле. Боларның мәгълүматларының чыганагы һәм бөтен гакыйдәләренең [ышануларының] хәзинәсе – Дәхлян һәм шуның мәсләгендә булган кешеләрнең әсәрләре. Шуның белән бергә, битарафлык нигъмәте боларга насыйп булмады. Дәхлян, ихтимал ки, үзе бөек һәм галим адәмдер, әмма хакыйкый һәм хөкем чыгаручы тарихчы түгел. Ибне Тәймия белән Ибне әл-Кайййимне ваһһаби дип әйтү, Җүнәйдне Ибне Гарәбигә иярүче иде, дигән шикелле, мәгънәсез бер дәгъва булганлыктан, «Ибне Тәймия» китабында искә алынмаган.

Халыкларны юнәлтүчеләр [ишаннар] «ваһһаби» исемен шул дәрәҗәдә начар күрсәтәләр һәм шул дәрәҗәдә халыкларны нәфрәтләндерәләр ки, мөгамәләләренә караганда, хәтта, фараз белән, ахирәттә бөтен халык котылу тапса, бу нигъмәттән бары тик ваһһабилар гына мәхрүм булачаклар,

кебек бер фикер килә. Болар каршында, үзләре кебек фикер йөртмәүчеләр һәм болар мөгамәләсе кебек мөгамәләдә булмаучыларның һәрберсе – ваһһаби һәм һәрбер ваһһаби – утта. Ашыкмасыннар!.. Мондый хөкемнәргә әле вакыт җитмәде. «Тузан өере узып киткәч кенә, астында атмы, ишәкме икәнен күрерсең».

*Шура. – 1912. – № 1. – Б. 29–30.*

## [РАШТУА ТУРЫНДА]

**Алмата:**

Русларның Рождество бәйрәмнәре башлыча «сабыйлык бәйрәме» [дип] атала. Бүген хәзрәте Гайсә хөрмәтенә һәм дә сабый балаларның күңелләрен табар өчен, «ёлка» кичәсе ясыйлар, ягъни чыршы агачын матурайтып, һәртөрле уенчыклар, конфет, яндырылган шәмнәр белән бизәклиләр ки, моңа балалар һәвәсләнеп кызыгып карыйлар. Русларның ишануынча, ёлканың үзе хәзрәте Гайсәнең сабый вакытындагы яткан бишеген, чыршы ботаклары арасында янучы шәмнәр исә монахларны, хәзрәте Гайсә бишеге янына алып баручы Вифлеем йолдызын искә төшерәләр икән. Ёлка кичәсе христиан балаларының бик яраткан һәм дини хисләрен кузгаткан кичәләре була. Бу ёлка кичәсен мисал буларак күрсәтәм. Русларда мондый дини хис кебек нечкә һәм мөкаддәс хисләрне балаларга урнаштыра торган милли уеннар күп. Бу соңгы заманда кайбер мөселманнар да искә алынган уеннарга балаларын катнаштыра башладылар. Башка милләтләрнең дини хисләрен урнаштыруда булган мондый уеннарга мөселман балаларын катнаштыру дөрес булырмы? Бу хакта җавап язсагыз иде.

*Билал Хисами.*

**Җавап:**

Ёлка һәм яфрак бәйрәмнәре, христиан мәзһәбенә күрә, дини бәйрәмме яисә соңыннан кертелгән яңа эшләрдәнме? Моны тикшерү, хәтта белгәнебез кадәрлесен сөйләү безнең вазыйфабыз түгел, аны исә христиан мәзһәбендә булган адәмнәр үзләре тикшерерләр һәм сөйләшерләр. Искә алынган бәйрәмнәр – теләсә үзләренчә тиеш, теләсә яңа эш булсын, бүген дини бәйрәмнәреннән. Нинди чит дингә хас бәйрәм булса да булсын, анда катнашу, тәрбия ноктасыннан, мөселманнар өчен яраклы эшләрдән түгел. Мәҗбүрлек булмаганда андый эшләрдән саклану тиешле. Ләкин халык фикерләренә мөрәҗәгать иткәннән соң, аны коры тыюда файда күренмәс, хәтта күпвакыт коры тыюлар халыкларның хирыслыгын арттыруга сәбәп була. Шуның өчен мондый эшләрдән тыюны тәрбия ысулына яраклаштыру тиешле. Әгәр дә моның урынына балаларга махсус бер бәйрәм кичәсе ясалса, күңелләр шуның белән канәгатьләнер, башкаларга китмәс. Моның өчен иң яраклы нәрсә – Мәүлид бәйрәме ясау. Мөселманнар Мәүлид бәйрәме исеме белән балаларга махсус шатлык кичәләре ясасалар, балалар аңлар кадәр хөрмәтле Рәсүл тормыш юлын да укыштырсалар, балаларга махсус әдәби хикәяләр һәм мәзәк хәлләр сөйләсәләр, күңелләре, хәтерләре ачылыр, бер-берсе белән белешеп, дуслашырлар, үзләренә туры килгән әдәп һәм гадәтләрне өйрәнерләр, шундый кичәне һәр ел көтеп алырлар. Мәүлид бәйрәмен элекке вакытлардан ясап киләләр, балалар кичәсе исә шуның бер төре генә булыр. «Мәүлид бәйрәме» исеме яраклы күренмәсә, шиксез, «Балалар һәм шәкертләр кичәсе» исеме белән дә рәхәт кичәләр төзергә мөмкин. Ислам шәригатенә күрә, дини бәйрәмнәр уйлап чыгару дөрес булмаса да, дөньяви һәм әдәби бәйрәмнәр ясаудан тыю юк. Кырга, хозурга чыгу шикелле, болар – мөбах [гөнаһ та, савап та булмый торган] эшләр. Мәүлид бәйрәме үзе дә дини түгел, бәлки бары тик әдәп һәм гореф-гадәт бәйрәме. Ният сәбәпле, мөбах эшләр

өчен савап һәм гөнаһ билгеләнергә мөмкин булса да, бу эш гореф-гадәткә һәм әдәплеккә каршы түгел.

*Шура. – 1912. – № 3. – Б. 87–88.*

## [ДӨЛДӨЛ ТУРЫНДА]

**Җамбити:**

Хәзрәте Галинең Дөлдөл исемле бер аты булып, бу ат бер айлык җирне бер көндә йөри торган булган. Шулай ук Зөлфәкар исемле бер кылычы булып, бер селтәгән вакытта, йөз аршын кадәр озыная һәм хәзрәте Гали үзе дә баһадир булып, берүзе мең адәмне кыра икән. Хәзрәте Гали тәрҗемәи хәлен язган вакытта, «Шура»да боларга һич ишарә итмәдегез. Без моңа гаҗәпләндек.

*Минҗан Исхакый.*

**«Шура»:**

Хәзрәте Галинең Зөлфәкар исемле кылычы бар иде. Әмма Дөлдөл исемле аты булуыннан хәбәребез юк. Хәзрәте Рәсүлнең Дөлдөл һәм, икенче риваятькә күрә, Дөлд исемле бер качыры булганлыгы мәгълүм (Макукс тарафыннан бүләк ителгән качыр – бу булса кирәк). Хорафат һәм арттырулар язмаганыбыз өчен гаҗәпләнер булсагыз, мактанырбыз.

*Шура. – 1912. – № 6. – Б. 187.*

## [ШӘДАД ҖӘННӘТЕ ТУРЫНДА]

**Ташкент:**

Хазин тәфсире сөйләгән Шәдад җәннәтенең урыны кайсы җирдә? Моның хакында география китапларында мәгълүмат бармы? Карталарда күрсәтелгәнме? Җавап язуыгызны үтенәбез.

*Габдулла Карамалый.*

**«Шура»:**

Шәдад җәннәте хакында Хазин тарафыннан тәфсир китабына язылган нәрсә – асылсыз әкият. Шуның өчен география кебек хисләргә нигезләнгән җитди фәннәр ул турыда бәхәсләшмәс. «Дәкаикыль-әхбар» китабында искә алынган хикәя язылса да, ул китапның темасы да шуннан гыйбарәт булганлыктан, авторы гозерле. Әмма Хазин әбиләрдән ишетелгән нәрсәләр белән Аллаһ китабының тәфсирен пычратуында һич һәм катгый рәвештә гозерле түгел. Тиз көннән «Шура»да тәфсир һәм тәфсир китаплары хакында беркадәр мәкаләләр укырсыз. Шунда моның шикелле күп нәрсәләр мәгълүм булса кирәк. Бу мәкаләләр «Коръән тәрҗемәсе» хакында булган мәкаләләргә иптәш булачак.

*Шура. – 1912. – № 14. – Б. 439.*

## [БОЛГАРГА КИЛГӘН СӘХАБӘЛӘР, БЕР ХӘДИС ТУРЫНДА]

**Сембер:**

1. Безнең Болгар мәмләкәтен ислам диненә чакырыр өчен Рәсүлуллаһ заманында Әбү Гобәйдә, Тальхә һәм Җәгдә исемле өч сәхабә килделәр. Боларның кәрәмәтләре [күрсәткән могҗизалары] сәбәпле, хан кызы Туйбикә хасталыгыннан терелде. Искә алынган өч сәхабә Болгарда озак вакыт

калдылар, ниһаять, ике сәхабә генә Мәдинәгә кайтып киттеләр һәм берсе, Туйбикәне никах кылып, Болгарда калды, дигән бер хәбәр халкыбыз арасында таралган, элекке заманнардан бирле авыздан авызга күчерелеп дәвам итәлә. Бу хәбәрнең асылы бармы?

2. «Аллаһ бар иткән иң беренче нәрсә – минем нурым» мәгънәсендә булган хәдис «Көтебе ситтә»нең [алты хәдис җыентыгының] берсендә искә алынамы?

*Мөхәммәдсабир Ибраһим.*

**«Шура»:**

1. Болгарга сәхабәләр килүенең асылы булмаса кирәк, сәхабәләр заманында Болгар белән Хиҗаз арасында караван йөргәне хакында ишарә юк һәм, гомумән, Болгар исеме бер җирдә дә очрамый, бәлки уртада румилар белән иранлылар торып, болар мөселманнарга дошман булганлыктан, Мәдинәдән Болгарга сәфәр чыгу мөшкел эш иде. Бу – бер. Икенче – бик вак нәрсәләргә озын ышандыргыч дәлилләр китереп язучы Табари һәм һәрнәрсәне кыскартып, сөйләп үтүче Билазири, Ибне әл-Әсир, Ибне Халдун һәм Әбү әл-Фидалар, мондый олуг вакыйга булганда, һич ишарә итмичә үтәрләр идеме? Әлбәттә, бу турыда мәгълүмат бирерләр иде. Һич булмаса, мәгълүм сәхабәләр сөйләнгән җирләрдә «Әл-истигаб», «Үсдүл-габа», «Әл-исабә»ләрдә берәр сүз күренер иде. Ислам тарихында Болгар исеме бары тик габбасилар заманында очрый. Бу мәсьәлә хакында Мәрҗани хәзрәт «Мөстәфаделәхбар»да сөйләгән. Шунда мөрәҗәгать итсәгез, зарар булмас.

2. Имам Газали: ««Аллаһ бар иткән иң беренче нәрсә – акыл» дигәннән, Акыл исемле бер фәрештә булырга тиеш», – дисә дә (Фәйсал эт-тәфрика. – Б. 41), Газали хәдис галимнәреннән булмаган өчен, аның бу сүзе хәдисне дөресләү түгел. Хәдис гыйлемендә белгеч затлар шул мәгънәдә булган хәдисләрне асылсыз дигәннәр.

*Шура. – 1912. – № 16. – Б. 507.*

## [БИДГАТЬЛӘР ТУРЫНДА]

**Казан:**

«Шура»ның 13 нче санында (409 нчы бит) дини бидгатьләрнең [дини мәсьәләләрдә Коръән һәм пәйгамбәр өйрәтүләренә туры килмәгән фикерләр, гамәлләр, йолалар һәм сүзләрнең] һәрберсе адашу икәнлеге бәян ителде. Шул ук вакытта, мөселманнар арасында дини бидгатьләр бик күп. Мәсәлән, китаплар язу, мәчетләргә манаралар кую, дини мәктәпләр төзү һәм башкалар. Динне куәтләргә беренче сәбәп булган бу нәрсәләр дә адашу булачакмы? Алай булса, халыклар адашуга төшүдән куркып, бу эшләрне эшләмәсәләр, ислам дине ничек дәвам ителер?

*Габделмәҗид.*

**«Шура»:**

Хөрмәтле Рәсүл үзенең хөтбәсен Әбү Шамә исемле адәмгә язып бирергә кушканы Бохари һәм башка Сөннәт китапларында искә алынган. Хәтта Бохари бу турыда бер бүлек куйган. Шуның өчен моны бидгать дияргә мөмкин түгел. Моның белән бергә, гомумән, китаплар язу, мәчетләргә манаралар кую, дини мәктәп-мәдрәсәләр төзү (ният һәм теләкләрдән буш ителеп тулганда) дини эшләр түгел, бәлки дөньяви нәрсәләр. Мөселманнар манара һәм мәктәпләрне, китап язу ысулларын Рум һәм Иран халыкларыннан күреп, уйлап чыгардылар. Дөньяви эшләрдә исә иркенлек. Халыклар нинди нәрсәне тормышлары, әхлак һәм диннәре өчен муафыйк күрсәләр, шуны алырлар. Дини бидгатьнең һичбер яхшысы юк, бәлки һәммәсе адашу һәм гөнаһ булып, дөньяви бидгатьләрнең һәртөрлесе булырга мөмкин. Ихтимал ки, кайберләре, ният һәм теләк сәбәпле, бик зур савапларга да сәбәп булыр.

*Шура. – 1912. – № 17. – Б. 538–539.*

## [ЗИРАТЛАР ТУРЫНДА]

**Уфа:**

Кайбер адәмнәрнең, гомуми каберлекләрдән хосусый сурәттә үзләренә аерып алып, ия булулары хакында «Шура»да бер мәсьәлә язылды (№ 13). Сорау ачык булган хәлдә, моның җавабы безнең кайберләребезгә бик аңлашылып бетмәде. Шуның өчен бу мәсьәлә һәм бу җавап хакында түбәндәге маддәләрне аңлатуыгызны үтенәбез:

1. Шәһәрдә булган каберлекләрнең мөселманнарга вакыф [мөселманнар файдасына иганәчелек рәвешендә тапшырылган милек] булуы белән Управа милке булу арасында нинди аерма бар? Моннан нинди хөкемнәр тармаклана?

2. Кешеләрнең нинди җирдә вафат булачаклары мәгълүм булмаганда, үзләренә күмәр өчен дип бер буш урынны үзенә хаслап, аерып, ихаталап куюда нинди мәгънә бар?

3. Управа милке дә булсын, буш урыннарны милек итеп фәкыйрьләргә зарар итү, сезнең хосусый фикерегезгә күрә, дөрес һәм акылга сыя торган бер эшме?

4. Мәетләр белән тулып та, үзенең мәгълүм бер вакыты үткәннән соң, һәртөрле бозыклык урыны булачак гомуми бакча булып калуында мөселман каберлекләре өчен нинди файда бар, каберлекләрнең бакча булып калуына караганда урам һәм мәйдан булып калуы арасында нинди аерма? Мөселман каберлекләрен мәйданнар итеп калдырмаска һәм базар-фәләннәр ясатмаска ни өчен телисез, шулардан азат булыр өчен бердәнбер чара бакча булып калу дип, каберлекне бакчалык рәвешенә китереп калдырырга тырышасыз?

*Габделкәрим Кармасани.*

**«Шура»:**

1. Мөселманнарга вакыф булган нәрсә мәңгелек белән үз милекләре хөкемендә булып, башка һичкем аңа катыша алмас. Управа милке булган нәрсәләрдә исә мөселманнар махсус шартларга игътибар итеп кенә файдалана алырлар һәм ул нәрсә алар кулында аренда хөкемендә генә.

2. Сәләф галимнәре арасында үзләре өчен кабер казып, әзерләп куючылар күп булды. Үлемне онытмаска сәбәп булган өчен, башкалар да моңа каршы чыкмыйлар иде. Ихата тотып кую – кабер казып, әзерләү шикелле бер нәрсә. Ихата тотып куючы башка җирдә вафат булса, мондагы ихатасына башка бер адәм җирләнер. Монда ни зарар бар?

3. Каберлекләр хосусый адәмнәр тарафыннан ихаталану сәбәпле милек булмый. Бу – пароход яки тимер юл арбалары иркен вакытта ике кешелек урынны бер кеше биләп баруы шикелле бер нәрсә. Кеше булмаганда, бер адәмнең ике, өч кешелек урынга хуҗа булып баруыннан тыю юк. Әгәр дә кеше күбәйсә, табигый, бу вакытта үз урыныннан чыкмаска хакы булмый. Каберлек тә иркен вакытта кайбер адәмнәр үзләренә хаслап, урыннар билгеләсәләр дә, урын бетә башласа, шул ихата эчләре буш вакытта Управа икенче урыннан каберлек бирми, бу вакытта мәетләр шул ихата эчләрендәге буш урыннарга күмелергә тиешле була. Шуның өчен бу эшләрдә фәкыйрьләргә һич зарар күренми.

4. Һәр бакчаның бозыклык урыны булуы мәҗбүри түгел. Гомуми булачак бакчалар хакында хосусый низамнар бар. Кабер һәм гыйбадәтханәләрдә булган бакчаларны бозыклык урыннары итәргә бүгенге законның рөхсәте юк. Шуның өчен Управа тарафыннан бирелгән каберлекләрне мөселманнар бакча итәргә һәм гомер буенча бакча булып торачак рәвешләр белән оештырырга һәм карарга тиеш. Каберлек бакча булса, гомер буе каберлек булып торачак.

*Шура. – 1912. – № 19. – Б. 599–600.*

## [МӨХӘММӘДИЯ» КИТАБЫ, КАБЕРДӘН ТЕРЕЛЕП ЧЫГУ, БЕР ХӘДИС ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

1. Төркиянең Балкан дәүләтләре тарафыннан җиңелгәнен ишеткәннән соң, кайбер муллалар: «Ахырзаманда Истанбул шәһәре алыначак, «Мөхәммәдия» китабында шулай әйткән, бу сугыш шул ахырзаман сугышы булыр инде», – диләр. «Мөхәммәдия» авторы шундый сүзләрне, бәлки, берәр хәдискә таянып сөйләгәндер?

2. Шул «Мөхәммәдия» китабында: «Рәсүлуллаһның атасы, анасы һәм дә Әбү Талиб каберләреннән терелеп, Рәсүлуллаһка иман китерделәр», – ди. Бу сүзне Хөсәен әл-Җәсәри хәзрәт тә дөрес күрә. Бу хакта «Сахих» китапларында берәр сүз бармы?

3. «Мохтасар Бохари»да (Т. 2. – Б. 161) «Дөньяда ят кеше яки юлчы кебек бул (Мөслим риваятендә) һәм үзеңне кабер иясе итеп сана» дигән бер хәдис бар. Бу хәдис мөселманнарны хәерчелеккә чакыру булмыймы?

Бу сорауларның һичберсе иҗтимагый һәм икътисади. Әдәби һәм фәнни мәсьәләләрдән булмаса да, безнең өчен олы әһәмиятләре бар. «Шура»да җавап язылуын үтенәбез.

*Әхмәдвәли Әхтәмов.*

**«Шура»:**

1. «Мөхәммәдия» китабы – дәрвишләр өчен язылган бер дәрвиш китабы. Эчендә дөрес сүзләр хисапсыз булса, игътибарга алырга лаек түгел сүзләре дә хисапсыз. Һәрхәлдә, мондый олы эшләр турында «Мөхәммәдия» сүзенә таянып, хөкем итүче кеше арттыру һәм үлчәүсез сөйләү хәтәрлегеннән сәламәт булмас. Мәмләкәтнең читләргә китүе өчен ахырзаман җитүе шарт түгел. Халыкларның бөтен байлыкларын гыйлем юлына сарыф итүләре, түбәләре күкләргә җитәрлек итеп, мәктәпләр салулары, тырышлыклары сәбәпле, табигать

күренешләрен буйсындырулары булган вакытта, бар тапканнарын Габделкадыйр әл-Гиляни белән Нәкышбәнд төрбәсе өстендәге әрәмтамакларга ташучылар, Гаус, Котыб, Әбдал, Мәһди хәбәрләре сөйләп, Аллаһ Тәгаләне аларга җиңелгән хөкемендә тотучылар, гомерләрен хыяллар һәм мәгънәсез нәрсәләр белән әрәм итүчеләрнең Кәгъбәләре белән пәйгамбәрләренең төрбәсе читләргә китүе дә гаҗәп булмас.

2. Аллаһ Тәгалә бер кешенең иман белән үтүен теләгән булса, моның өчен үлгәннән соң кабат терелтеп, иман китертергә хәҗәт юк, моннан башка да мөмкин. Мондый бәхәсләр өммәтләр өчен кирәкле түгел. Хосусый кешеләрнең иман һәм көферлеккә мөнәсәбәтле эшләрен Аллаһ Тәгаләнең Үзенә тапшыру тиешле. Искә алынган мәсьәләләрдә «Көтебе ситтә»дә бер нәрсә күрүебез хәтеребездә юк.

3. «Дөньяда бул...» хәдисе – күңел юкарсын, нәфес азып, горурланып китмәсен өчен әйтелгән гыйбрәтле бер нәсыйхәт. Аның исә хәерчелек кылырга дәлиле юк. Бәлки андый эшләрдән тыелу тиешле икәненә дәлиле бераз бар. Үзләрен гадел һәм нык тотарга тырышучылар һәм нәфесләрен туры юлдан йөртергә ниятләүчеләр өчен мондый сүзләрнең файдалары бик күп. Бүгенге мөселманнарның наданлыклары, җебегәнлекләре һәм һәртөрле затларга риза булулары дөньяда торуны сөюләреннән, мәңге үлмәс кебек дөнья куучан булуларыннан, «Үзеңне кабер иясе итеп сана»га буйсынмауларыннан.

*Шура. – 1913. – № 1. – Б. 26.*

## [«КАРА ТАШ» ТУРЫНДА]

**Газиабад:**

«Җир һәм хәят тарихы» исемле китапта күктән ташлар төшүе турында яхшы гына мәгълүмат бирелгән. Шул мөнәсәбәт белән «кара таш» хакында (1 нче бүлек. – Б. 77): «Берничә йөз еллар элек Гарәбстанда күктән төшкән «кара

таш» хөрмәтле Кәгъбәнең таш стенасының эченә куелган һәм миллионнарча адәмнәр тарафыннан хөрмәтләнә һәм олылана, зиярәт кылына. Бу һәм мондый һавадан төшкән кадәрле нәрсәләрнең гыйльми җәһәте хәзерге көндә тикшерелүдә булып, безгә һәркөн яңа-яңа гаҗәеп мәгълүматлар биреп тора», – дип яза. Димәк, «кара таш» күктән төшкән бер таш икән – бу шулай. Шулай булгач, искә алынган «кара таш» ни өчен без – мөселманнар каршында изге санала, моның сәбәбе ни икән? Яисә башка бер яшерен сере бармы? Шул хакта «Шура»да җавап бирелүне өмет итеп калдык. (Бу, әлбәттә, дини булмас һәм дингә бәйләнеше дә юк, фәкать, тарих гашыйкы булуыбыздан, асылын беләсебез килә).

*Г. Госмани.*

**«Шура»:**

«Кара таш» – тавафны [гыйбадәт рәвешендә таш тирәли әйләнүне] башларга билге һәм тавафларның саннары мәгълүм булсын өчен Йәмән рөкене белән куелган бер таш. Кәгъбәне башлап төзүче Ибраһим пәйгамбәр булса да, аннан соң күп мәртәбә төзекләндерелде. Хәтта нигезенә кадәр сүтелеп, күбесенчә, яңа ташлар кушылып, төзелде. Бүген Кәгъбәдә, шөбһәсез, Ибраһим пәйгамбәр ядкәре булган нәрсә бу «кара таш» булып, башкаларын билгеләп, Ибраһим пәйгамбәр әсәре дияргә мөмкин түгел. «Кара таш» хөрмәтле булса, аның хөрмәте күктән төшүе яки Әбү Кобәйс тавыннан чыгуы өчен түгел, бәлки Аллаһ Тәгаләнең илһамы белән Ибраһим пәйгамбәр тарафыннан ихтыяр кылынып, шул урынга куелганы өчен (гыйбадәт әмере). Пәйгамбәрләрнең хөрмәтле булулары матдәләре башка булу сәбәпле түгел (чөнки матдәдә башкалык юк), бәлки Аллаһ Тәгаләнең пәйгамбәрлек хезмәтенә сайлавы өчен. «Кара таш»тагы хөрмәт тә моның шикелле. Үзенең бабасының әсәре һәм хөрмәтле олуг бер пәйгамбәрнең ядкәре булганлыктан, хәзрәте Рәсүлуллаһ моны үпкән иде. Инде Рәсүлуллаһның бу

гамәленә муафыйк [булу] йөзеннән, өммәт тә үбә. Бу үбүдән изге булу мәгънәсен аңларга ярамый.

*Шура. – 1913. – № 3. – Б. 90.*

## [ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ТУРЫНДА]

**Иманкол:**

Шәкертләребез мәдрәсәләрдә вакытта дөньяга чыкканнан соң, фидакяр булмакчы, мәктәп-мәдрәсәләр хакында гаҗәеп рәвештә хезмәт итмәкче, халыкны агартмакчы булалар. Әмма указ алып бер мәхәлләгә урнашканнан соң, бөтен идеяләреннән ваз кичеп, әүвәлге хәбәрсез муллаларның берсе булып калалар. Бездә фикердә ныклык юклыкның һәм, дөресе дә, дөрес идеал юклыкның сәбәбе нинди нәрсәләр?

*Закир Мәгази.*

**«Шура»:**

Бу мәсьәлә белән хәзерге көндә бөтен ислам дөньясы мәшгуль. Мисырда олы журналларның берсе: «Ишаннарның авторитетлары бик куәтле икәнен күргәннән соң, болар арадашлыгы белән мөселманнар арасына гыйлем, фикер таратырга мөмкин икән, дип, арабыздан иң яхшы һәм хезмәтле бер адәмне ишан итеп, шуның аркылы мәсләгебезне таратырга карар бирдек. Искә алынган адәм күп ялынуларыбыздан соң, морадыбызны кабул итте һәм эшкә кереште. Тырышлыгыбыз сәбәпле, заказыбыз тиз тәмамланды. Адәмебез ишан булды, ләкин акча һәм рәислек ләззәтен белгәннән соң, тәмам шуңа бирелеп китте һәм башка ишаннардан да яман сурәттә дөньяга әсир булды, вөҗданын сатты. Без дә үзе белән бәйләнешебезне кистек. Кулыбызны селтәп, хәленнән Аллаһка сыендык», – дип язган иде.

*Шура. – 1913. – № 3. – Б. 91.*

## [ИЗГЕ КАБЕРЛӘР ТУРЫНДА]

**Газиабад:**

1. Бу мәмләкәтләрдә могтәбәр [итеп] тотылган каберләр һәм төрбәләр күп. Шуларны бу җирле халкылар пәйгамбәребез (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) заманында килгән сәхабәләр каберләре дип йөртәләр һәм шулар өчен дип күп-күп вакыфлар кылганнар. Каберләрнең өсләре, гадәттә, бер сәҗдә урыны хәленә кергән һәм бу төрбәләрне ифрат дәрәҗәдә изге саныйлар. Алар җөмләсеннән мәшһүрләре:

Сәхабәләрдән: 1) Петнәк каласында Әбү әл-Хәҗән; 2) Сәгъд Ваккас; 3) Бишарыкта Ибне Мәсгудь (Аллаһ аннан риза булсын); 4) Нухас авылында Габдрахман бине Гауф; 5) Шаһигаббас авылында Габдулла (Наримҗан) бине Сәгъд Ваккас; 6) искә алынган затның артында Дагыстанда Солтан Вәйс әл-Карани; 7) Дурман авылында Гукькяшә; 8) янә шунда хәзрәте Гали хезмәткәре – Баба Канбар; 9) Юмыт авылының көнбатышында сәхабә исеме; 10) Һиляли каласында хәзрәте Билал.

Пәйгамбәрләрдән: 1) Кызыл ком эчендә хәзрәте Дауд; 2) Хуҗа иле каласында Шәмгун нәби. Бу сәхабә һәм пәйгамбәрләрнең төрбәләре ничек бу йортта калган? Боларның төрбәләре кайда икәне, әлбәттә, сезгә мәгълүмдер. Хакыйкать хәлдә, бу хөрмәтле адәмнәрнең төрбәләре бу урыннарда булса, вакыфларны тагын да күбрәк кылырга, каберлекләр дәрвишләрен һәм хуҗаларны артыграк хөрмәт итәргә тиешле булмасмы? Шушы турыда «Шура»да язсагыз, яхшы булыр иде.

*Гафур Госмани.*

**«Шура»:**

Бу җирдә искә алынган адәмнәрдән Әбү Мәхҗән (Әбү әл-Хәҗән түгел) хакында гына «Кабере Хәрәземдә» дигән зәгыйфь бер сүз бар. Башкалары хакында хәтта зәгыйфь ри-

ваять тә юк. Хөрмәтле Рәсүл хәзрәттән башка пәйгамбәрләрнең каберләре мәгълүм түгел. Үвәйс әл-Карани хакында «Шура»ның 4 нче санындагы 248 нче битендә сүз бар иде. Шуңа мөрәҗәгать ителсә, аның кабере хакында да мәгълүмат хасил итеп булыр. Каберләр өчен вакыфлар кылу, каберләргә нәзерләр әйтү, каберләр янында дәрвиш булып тору, каберләрдән ярдәм сорау афәтләре ислам дөньясына мөселманнарны адаштыру, Рәсүлуллаһ юлыннан саташтыру нияте белән ислам дошманнары тарафыннан кертелде. Моның шикелле эшләрнең күбесе иранлыларның яшерен сәяси җәмгыятьләре тарафыннан эшләнде. Әгәр дә урын күп булса, бу турыда бераз тәфсилләп аңлатылыр иде. Каберләргә хас булган вакыфларны тәмам кулга төшереп, бер өлешен гыйлем юлына тоту, бер өлешен зәгыйфь һәм эшкә яраксыз мөселманнар өчен тәрбияханәләр [приютлар] ачу бүгенге мөселманнар өчен фарыз. Моны исә башлап Хуҗа Баһаветдин кабереннән эшләргә кирәк. Зират һәм каберләрдән ярдәм сорауның шәригать хөкемнәре «Вакыт» идарәсе тарафыннан нәшер ителгән «Ибне Тәймия» исемле китапта бераз сөйләнгән. Мөрәҗәгать итүчеләр, иншалла, зарар күрмәсләр.

*Шура. – 1913. – № 9. – Б. 283–284.*

## [КОРЪӘН СҮЗЛӘРЕ ТУРЫНДА]

**Катай:**

1. Коръән кәрим «Бүген мин сезнең динегезне камил иттем» [Коръән, 5:3] дип хәбәр бирде һәм Рәсүлуллаһ хәзрәт тә: «Миннән Аллаһ китабыннан башканы күчермәгез. Әгәр дә күчерәчәк булсагыз, аны Аллаһ китабына (Коръәнгә) тәкъдим иткәннән соң гына күчерегез!» – дигән иде. Шулай була торып, хәдис белгечләре хәдис сөйләүчеләр хакында беркадәр шартлар куеп, хәдисләрне күчерә биргәннәр. Моңа сәбәп нинди нәрсә?

2. Коръән кәрим «Әгәр җир өстендәге кешеләрнең күбрәгенә иярсәң, алар сине Аллаһ юлыннан адаштырырлар, чөнки алар тик үлчәүсез фикергә ияргә һәм алар – фәкать ялганлаучылар» («Әнгам» [сүрәсе], 116 нчы аять) һәм дә «Әгъ-рафтагы ирләр залим ирләрне галәмәтләре белән танырлар һәм әйтерләр: «Дөньяда җыйган малыгыз сезгә файда бирмәде» («Әгъраф» [сүрәсе, 48 нче аять]) дигән хәлдә, бездә күпчелек, олуг галимнәр тарафына ышану булуының сәбәбе ни?

3. Коръән кәрим яһүд һәм насаралар хакында «китап әһеле» дип хөрмәт сүзе кулланган хәлдә, безнең ислам галимнәре Коръән әһелләрен могтәзилә, шигый, масон, хәтта кяфер һәм динсез кебек сүзләр әйтүләренең сәбәбе ни?

*Имам Әюб Гайнуллин.*

**«Шура»:**

1. Рәсүлуллаһның шундый бер фәрманы булуы хакында берәр нәрсә күргәнебез һәм укыганыбыз хәтеребезгә төшми. «Миннән гыйлем ишетүчеләр ишетми калганнарга ирештерсеннәр» эчтәлегендә хәдисләр «Көтебе ситтә»дә күп. Юкса сез хәдис риваять кылу мәсьәләсе белән хәдисне китапларга язу мәсьәләсен бер [дип] санап йөрисезме? Алар – икесе ике мәсьәлә.

2. Хакыйкать ияләре дөньяда һәр заманда, һәр җирдә аз була. Халыклар, күбесенчә, фикер һәм мәзһәбтә ата-анага, шәехләр һәм остазларга, сүзгә оста һәм мөгамәләләре белән күңелләрне сихерләүчеләргә ияреләр. Шуның өчен бер нәрсәнең хак булуын аның тарафындагы халыкның күп булуы белән генә исбат итәргә, дәлилләрне тикшерми торып, бары тик яхшы уйлау белән күплек тарафына ияреpгә ярамый. Хаклыкның күплек тарафында булуы дөрес булган кебек, азлык тарафында булуы да дөрес.

3. Моның сәбәбе – тәрбия кимчелеге. Коръән кәрим мөшрикләр һәм ялган табыну затлары хакында: «Аллаһтан башка мөшрикләр табына торган потларны сүкмәгез, надан-

лыклары белән сезгә ачу итеп Аллаһны сүгә башларлар» («Әнгам» [сүрәсе], 108 нче аять), – дип юл күрсәткән булса, кыйбла әһелләре хакында әдәпле булу тиешле икәне үзүзеннән аңлашыла.

*Шура. – 1913. – № 11. – Б. 346–347.*

## [НАМАЗ ТУРЫНДА]

**Оренбург:**

Аллаһ Тәгалә бәндәләргә тәүлектә бишвакыт намаз фарыз иткән иде. Рәсүлуллаһ хәзрәт бу фарызларга сөннәтләрне [пәйгамбәр укыган өстәмә намазларны] кушты. Хәзрәте Гомәр болар өстенә дә тәравих намазын уйлап чыгарды. Бу гыйбадәтләрне кылып җитешү кәсеп һәм эш кешеләре өчен читен булуында шөбһә юк. Шул сәбәпле, бу эшләр Хак Тәгаләнең «Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми» дигән сүзенә каршы килмиме?

*Габдерәхим Нурулла.*

**«Шура»:**

Фарыз намазлар кем өчен дә авыр булырлык дәрәҗәдә күп түгел. Авыл җирендә һичбер намаз калдырмый торган ялчылар булганлыгы ишетелгәне бар. Әгәр дә ялкаулык белән генә түгел, бәлки хакыйкать хәлдә авыр булырлык булса, сөннәтләрне (тәравих та шуның эчендә) калдырырга мөмкин. «Валлаһи, фарызларны калдырмам, әмма сөннәт һәм нәфелләрне [мәҗбүри булмаган өстәмә намазларны] укымам!» дигән гарәп хакында Рәсүлуллаһ: «Әгәр дә сүзендә тора алса, ягъни фарызларны калдырмаса, котылды», – дигән иде (Сахихе Бохари. – Т. 8. – Б. 60). Гозер бәян итми торып, «Нәфел укымам» дигән кеше хакында Рәсүлуллаһ шушындый мөгамәлә иткән булса, җиңеллек белән карау сәбәпле түгел, бәлки авырлык һәм җитешә алмаганлык гозере белән

сөннәтне куюдан зарар булмаска тиеш. Тәравих намазы – Рәсүлуллаһтан нык рәвештә килгән бер намаз. Хәзрәте Гомәрнең бу турыдагы хезмәте халыкны җыюдан гына гыйбарәт иде. Башка сорауларыгызга җавап язарга мөмкинлек булмады, гозерле күрегез.

*Шура. – 1913. – № 22. – Б. 698.*

## [ҖЕНАЗА ТУРЫНДА]

**Ташкент:**

Үз йомышым белән йөргәндә, дусларымнан берсенең өендә бер хатын күрдем. Бер баласы кулында, өч баласы янында аналарының тезенә башларын салган хәлдә, шушы биш җан бишәүләшеп ыңгырашалар. Хатын мине күрү белән: «Шушы дүрт баланы ятим калдырып, ирем вафат булды. Бишенчегә йөгем бар, инде кайларга барыйм, кемнәрдән ярдәм сорыйм? Бер кешем дә юк!..» – дип үксеп-үксеп елый башлады һәм: «Иремнең дүрт йөз сум акчасы калган иде, фидиясенә, гүр сәдакасына, өчесен, җидесен үткәрер өчен шул акчаны тотып бетерә яздык. Тагын кырыгын үткәрәсе бар, диләр. Инде анысына акчам җитми. Аның өстенә дә, авырулы бер хатын булган хәлемдә, бу балаларны ничек итеп тәрбияли алыйм?» – дип зар-моңын сөйләде. Мин бу җан ияләрен ифрат кызгандым һәм үз-үземне тыя алмыйча: «Шул акчаны ничек алай өчесенә дә, җидесенә, гүр сәдакасына да, фидиясенә сарыф иттең? Сезнең хакыгызда алар бар да – тиешсез эшләр, син балаларыңның ризыкларын һәм балаларыңның хакларын урынсыз әрәм иткәнсең», – дип шелтәләдем. Шушы сүзләр хәзрәтләргә ишетелгән дә, миңа ачуланганнар, хәтта «Андый изге эшләргә аркылы төшкәне өчен, аңа байкот ясарга кирәк» дип йөрүчеләр дә бар. Байкот ясарлармы, юкмы – хәзер мәгълүм түгел. Ләкин мин шул сүзне изгелеккә каршылык итәр өчен түгел, бәлки ятим бала-

лар һәм аналарын кызгануым сәбәпле, сөйләгән идем. Инде бу вакыйганы язуымнан максатым – шул. Әгәр дә хата әйткән булсам, мин бу эшемнән тәүбә итәчәкмен. Әгәр дә хата булмаса, сүземнең дөрес икәнлеге мәгълүм булып калсын иде. Мондагы үлек чыгымнары, аеруча дөньялары тар адәмнәр өчен бик мөшкел хәлдә. Мөселманнар бик сыкраналар. Бурычларга кереп, бөлгенлекләргә төшәләр, ятимнәрнең хаклары әрәм була. Ләкин хәзрәтләрнең «Үлсәң, җеназаңа бармабыз, байкот ясарбыз» дигән сүзләреннән куркып, хәтта актык нәрсәләрен сатып булса да, хәзрәтләрне ризалатырга тырышалар. Бу мәсьәлә бары тик дини генә түгел, моның башка яклары да күп. Шуның өчен, әлбәттә, берәр сүз язарсыз, дип өмет итәбез.

*Шафигъ Гомәров.*

**«Шура»:**

Бу мәсьәләләр – бик мәгълүм нәрсәләр. Хәтта мәктәпләрдә укытыр өчен төзелгән төркичә китапларның да озынракларында бар. Муллаларның җеназа [намазы] укымаулары белән куркытуларына карап, ятимнәр малларын әрәм итәргә юл юк. Муллалар укымаса, башка мөселманнарның укулары җитә. Хәтта акча өчен укыла торган җеназа намазына караганда һич тә укылмый күмелүе үлекнең үзе өчен дә, башкалар өчен дә яхшырак. Шәригать карашында, җеназа [намазы] өчен хәзрәт шарт түгел. Хәтта Рәсүлуллаһ заманында кайбер мәетләрнең, Рәсүлуллаһка хәбәр бирелмичә, җирләнүләре «Сахих»ләрдә [«Сахих әл-Бохари» һәм «Сахих әл-Мөслим»дә] бар. Боларның берсе хакында Рәсүлуллаһның «Гәрчә хәбәр иткән булсагызчы!» эчтәлегендә бер сүз әйткәне дә риваять кылына. Инде Рәсүлуллаһ сәламәт вакытында, аның барачагында шөбһә булмый торып, аннан башка җеназа намазы укып күмү яраган булса, хәзрәттән башка укылган җеназа намазы ничек ярамасын?..

*Шура. – 1913. – № 24. – Б. 764.*

## [ТАЛАК ТУРЫНДА]

**Пешпәк:**

Бу җирдә бер имам өч талак кылынган хатыннарны алырга теләүчеләр өчен аерусыз алырга яңа юл тапты. Өч мәртәбә талак кылынган хатынны алырга теләүче ирнең (нинди булса да бер сәбәп табып) көферлеге белән хөкем итә дә: «Кяфер булуың сәбәпле, хатының синнән аерылган һәм талак булырга урын калмаган. Шуның өчен талакларың хөкемсез кала», – дип, иман китертә һәм хатынны никахлап кайтара. Шушы эш шәригатькә туры киләме?

*Мәхәлләдән бер адәм.*

**«Шура»:**

Бу эштә бер аңламаулык, хаталык булса кирәк. Мөселман кеше мондый эшкә батырчылык итәр, дип күңелебезгә килми һәм дә мондый мөгамәләләр белән мөселманлык бер кешедә җыелыр, дип тә белмибез. Мулла мондый эшне эшли икән, шул кешеләр үзләре моңа риза булмаска, дин белән бу кадәр уйнамаска тиеш. Хәйлә шәригать түгел дип, күп мәртәбә яздык. Бу эш хәйлә дә түгел, бәлки туптуры Шәригать хуҗасын [Аллаһны] алдау, кимсетү һәм мыскыллау.

*Шура. – 1914. – № 1. – Б. 24.*

## [МӘҮЛИД ТУРЫНДА]

**Корыч:**

Мәүлиден-нәбине (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) хәзерге заманда Русия мөселманнары да кылалар. Мәүлид мөнәсәбәте белән, мәдрәсәләрдә яллар да була. Быел галимнәр арасында бу турыда бәхәсләр күренгәләде. Кайберәүләр мөэминнәр анасы Гайшәдән (Аллаһ аннан риза бул-

сын) китерелгән: «Безнең динебездән булмаган эш уйлап чыгарылса, ул эш кире кагылыр» дигән хәдис белән дәлил китереп: «Мәүлид гамәлләре кире кагылыр», – диделәр. Нәвавинең «Хәдис әрбәгыйн» («Кырык хәдис»)нең бишенче хәдисе аңлатмасында «Фәтх әл-мөбин» авторы, Әбү Шамә дигән заттан күчереп, моны яхшы бидгатькә керткән. Безгә кирәк нәрсә фәкать шул гына: Мәүлид хакында сәхабә әсәре бармы? Сәхабә әсәре булмаса, нинди бидгатькә керә? Искә алынган Әбү Шамәнең кем икәнлеге мәгълүмме? Мәгълүм булса, шуның хәлләрен, аз гына булса да, язсагыз иде. «Шура»га теркәп, безнең шөбһәбезне бетерүегезне үтенәбез.

*Мөгаллим Нурелгаян Атлангилде.*

**«Шура»:**

Мәүлиде нәби хакында Шураның 3 нче санының (1910 ел) 69 нчы битендә мондый җөмләләр бар: «Һиҗрәттән соң өч гасыр үтте һәм шушы вакыт эчендә мөселманнар Мәүлид бәйрәмнәре ясау түгел, хәтта аның исеме дә булмады. Хафиз Ибне Хәҗәр: «Мәүлид гамәленең асылы – бидгать, өч гасырдагы изге сәләфләрнең берсеннән дә китерелмәде. Ләкин шулай булса да, ул үз эченә яхшысын да, яманын да алган. Аны уздыруда яхшылыкны булдырырга тырышса һәм капма-каршысыннан сакланса – ул вакытта яхшы бидгать була, юк икән – булмый», – дигән. Хакыйкатьтә, сәхабәләр һәм табигыйннар заманында Мәүлид бәйрәме ясау булса, Мәүлид көне Корбан һәм Фитыр [Рамазан] гаетләренең көннәре кебек билгеләнеп калган булыр [иде], сира язучылар да Мәүлид көне хакында бу дәрәҗәдә каршылык кылмаган булырлар иде. Риваятьләргә караганда, иң элек Мәүлид бәйрәме ясаучы ислам хөкемдары Ирбил падишаһы Күкбүре булды ([һиҗри] 630 елда вафат). Әндәлүс хафизларыннан Ибне Дәхия ([һиҗри] 623 елда вафат) Шәрык мәмләкәтләренә сәфәр чыккан вакытында бу хөкемдарга очрады һәм моның Мәүлид

гамәле турындагы игътибарын күреп, «Әт-тәнвир фи мәүлид әс-сираҗ әл-мүнир» исемле бер китап язды. Күкбүре исә бу китап өчен, бүләк итеп, Ибне Дәхиягә мең алтын бирде.

«Шура»ның 3 нче саныннан күчергән сүзебез – бу. «Шура»ның үткән санында тәрҗемәи хәле язылган Кадәкыйның остазы Салих әл-Йәмәни үзенең бер әсәрендә мондый эчтәлектә сүз сөйли: «Мәккә Мөкәррәмәдә булган бидгатьләрнең иң олысыннан – мәүлид бәйрәме ясау. Рәсүлуллаһка сәхабәләрнең ихласлыгы һәм мәхәббәтләре һәркемнең ихласлыгы һәм мәхәббәтеннән артык иде, үз араларында Рәсүлуллаһ хәзрәтнең булуы өчен белүе мөмкин булмаган дәрәҗәдә шатланалар иде, ләкин шәригать чикләрен саклау турында кайгыртучанлыклары камил булу сәбәпле, мондый бәйрәмнәр ясамадылар. Асылда, мондый бәйрәмнәр Тәүрат һәм Инҗил әһелләре тарафыннан уйлап чыгарылды. Бу Мәккә халкы рәҗәб һәм шәгъбән айларында да бәйрәмнәр ясыйлар. Монда тора башлавыбызга өченче ел булды, һаман яңа бәйрәмнәр чыгып тора».

Әгәр дә бер кеше һәртөрле очраклардан азат ителеп тотылган хәлдә, Мәүлид бәйрәме ясауны гыйбадәт һәм дини бер гамәл дип ышанса, бу эш – шөбһәсез, бидгать. Безнең гаҗиз фикеребезгә күрә, бидгатьнең яхшысы юк. Мөхтәрәм шәригать төзүче [пәйгамбәр] бәян итүенә туры килгәнчә, «Һәрбер бидгать – адашу». Рәсүлуллаһ сүзенә каршы һичбер адәмнең сүзен кабул итмибез. Рәсүлуллаһ сүзеннән һәм аның хөкеменнән башка сүзләрне һәм хөкемнәрне танымыйбыз. Әгәр дә Мәүлид гамәлен дини гыйбадәт һәм шәригать төзүче [пәйгамбәр] тарафыннан әмер ителгән гамәл дип ышанмаса, ул вакытта, бер мөбах [гөнаһ та, савап та булмый торган] эш кенә булып кала. Мөбах эшне кылудан, әлбәттә, тыю юк. Сүзнең кыскасы бу: адашу булган бидгатькә керү ихтималы булганлыктан, Мәүлид бәйрәмен дини эш дип кылырга ярамый. Әмма дөньяви, гадәти һәм мөбах эшләр җөмләсеннән кылып эшләүдән, шәригать хөкемнәренә күрә, тыю күренми. Шуның өчен бу мәсьәлә хакында низаг кылышулар яраклы эш

түгел. Бәйрәм ясаучыга да, ясамаучыга да кагылырга урын булмаса кирәк. Һәркем үз гакыйдәсенә күрә гамәл кыла бирсен. Мөбах булган нәрсәләрнең, ният һәм чара булу кебек очраклар сәбәпле, гыйбадәт яки хәрам эшләр җөмләсенә керүе мөмкин. Бәхәснең бу өлеше безнең мәсьәләбезгә [карата] башка. Безнең үз аңлавыбызга күрә, яхшылык мәгънәсе белән (хәдис шәрифтә хурланган) булган «бидгать» сүзе бары тик дини эшләргә генә хас булып, дөньяви эшләр бидгать булу белән дә, Сөннәт булу белән дә сыйфатланмыйлар. Әгәр дә дөньяви бер эш хакында «бидгать» яки «Сөннәт» сүзе кулланылганлыгы күренсә, аларны яхшы мәгънәгә түгел, бәлки тел мәгънәсенә генә йөкләү тиешле. Бер җиргә җыелып, тәравих намазы укучыларны күргән вакытында хәзрәте Гомәрнең: «Бу – яхшы бидгать», – диюе шуңа йөкләнгән. Чөнки асыл тәравих намазы бидгать түгел, бәлки бер җиргә җыелу кадәрлесе генә бидгать. Тәравих намазында бер җиргә җыелу исә дини эшләрдән түгел, бәлки дөньяви эшләрдән булганлыгы өчен, «Һәр бидгать – адашу» хөкеме аны эченә алмый. (Бу мәсьәләне башка бер җирдә моннан озынрак сурәттә яздык). Ләкин безнең аңлавыбыз һичкем өчен дәлил түгел, һәркем үз кирәген үзе тикшереп белсен. Әгәр дә бу эш насыйп булмаса, белүчеләрдән сорасын. «Әгәр дә белмәсәгез, галимнәрдән сорагыз» [Коръән].

Әбү Шамәнең исеме Габдрахман һәм кушаматы Шиһабеддин иде, атасы Исмәгыйль исемле. [Һиҗри] 596 елда Димәшкъта дөньяга килде, [һиҗри] 665 елда[6] вафат булды. Галимнәрнең мәшһүрләреннән һәм хәдис белгечләренең могтәбәрләреннән иде. Сул ягында миң булу сәбәпле, Әбү Шамә дип билгеле булды. Адәмнәрне бик нечкә иләкләр белән иләүче Зәһәби моның хакында: «Үзе күп гыйлемнәрдә өстен булса да, тыйнак, түбәнчелекле, кылануны калдыручан һәм хәдисләр риваять итүдә ышанычлы кеше булды», –

[6] «Тәзккират әл-хүффаз»да моның вафаты хакында «625 елның 19 рамазанында вафат булды» дип язылган булса да, бу сүзнең типография хатасы булуында шөбһәбез юк. Дөресе исә «665 елда».

дигән[7]. Шаять, сораган нәрсәләрегез хакында бу сүзләребездән җавап чыккандыр. Әгәр дә аңлашылмый калган җирләр булса, кабат язарсыз.

*Шура. – 1914. – № 2. – Б. 56–57.*

## [ХӨТБӘ СӨЙЛӘҮ РӘВЕШЕ ТУРЫНДА]

**Эстәрлетамак:**

Хөтбә сөйләүчеләр җомга хөтбәсе укыган вакытларында ике хөтбә арасында бераз утырып торалар. Бу утыру берәр дога укыр өченме яки әүвәлге хөтбәдәге сүзләрне аңламый калып та, шуны белергә теләүчеләр хөтбә сөйләүчедән сорап аңласыннар өченме? Хөтбә укыганда таяк тотуның сәбәбе нинди нәрсә? Юкса: «Сүземне тыңламасагыз, менә сезгә шушы таяк!» – дип халыкны куркытыр өченме? Шушы сорауларга, кыскача гына булса да, җавап язылсын иде.

*Хаҗиәхмәт Әмиров. «Исмәкай».*

**«Шура»:**

Рәсүлуллаһ ике хөтбә уртасында утырып, бераз хәл җыя иде, дигән сүз бар. Утыруы хәл җыяр өченме яки башка нәрсә өчен була идеме – һәрхәлдә, утыруы шиксез. Рәсүлуллаһның шул гадәте мөселманнар арасында мирас булып калган. Юкса сүз сорасыннар өчен булмас. Чөнки сәхабәләр хөтбә вакытында да сүз сорыйлар, Рәсүлуллаһ шул эштән тыймый, үзе дә, йомышы булса, хөтбә арасында башкара иде.

Таяк тоту кеше куркытыр өчен түгел, бәлки Рәсүлуллаһ хөтбә сөйләгән вакытта, гарәп гадәтенә күрә, кайбер вакытларда таяк һәм кайбер вакытларда җәя тота иде. Гарәп ораторлары, сүзләре тәэсирле булсын өчен, хөтбә вакытында хәтта кием-салымнарын да аерым формаларга куялар. Ишарә итеп

---

[7] Тәзкират әл-хүффаз. – Т. 4. – Б. 262.

сөйләр өчен, кулларына михсара дип билгеле аршын озынлыгында кыска бер таяк яисә җәя тоталар иде. Европа ораторларында да шушындый бер гадәт булган һәм бүген дә бар, диләр. Мәшһүр ораторларның хөтбә сөйләгән вакытындагы гадәтләре сөйләнгән бер мәкалә укыган идек. Боларның гадәтләре бик төрле булып, кайберләре кыска таяк һәм кайберләре култык асларына бер букча яки китап кыстыралар, кайберләре бүрек һәм эшләпәләрен тотулары сөйләнгән иде. Габделмәлик бине Мәрванның: «Әгәр дә кулымнан камыш таягым төшеп китсә, сөйләргә дип әзерләгән хөтбәмнең ярымы гына да күңелемдә калмый», – дип сөйләгәнлеге риваять кылына. Бер мәҗлесендә Могавия мәшһүр хөтбә сөйләүчеләрдән Собхан Вәилгә хөтбә сөйләргә кушкан иде. Собхан: «Янымда таягым булмаса, сөйли алмыйм», – дип гафу үтенгән. Бер таяк китереп бирделәр, тотып караганнан соң: «Үз таягым булмаса, сөйли алмыйм», – диде. Өенә барып, үз таягын алып килделәр, кулына бирделәр, «Инде мөмкин», – дип, аяк өстенә басты да хөтбә сөйләде. Кайбер китапларда «Рәсүлуллаһ кайбер хөтбәләрендә кылыч тота иде» дигән сүз бар. Гыйлемнәре ышанычлы адәмнәр: «Бу сүз дөрес түгел, Рәсүлуллаһ һичвакыт кылыч тотып, хөтбә сөйләмәде», – диләр. «Безнең Болгар мәмләкәте таяк белән күрсәтелгән кәрәмәт сәбәпле мөселман булды, шуны хәтердә тоту өчен, хөтбәләрдә таяк тотыла» дигән сүз дә асылсыз. Һәрхәлдә, таяк – гарәпләрнең олылары һәм аеруча хөтбә сөйләүчеләрнең кулланган нәрсәләре. Җахиз үзенең бер әсәрендә «Китаб әл-гаса» дип аерым бер китап куеп, таяк хакындагы хикәяләрне һәм аның хасиятләрен яза. Укырга бик күңелле нәрсәләр бар. Һәрхәлдә, хөтбә вакытында таяк тотуның асылы – борынгы гарәп ораторлары гадәтеннән алынган бер эш.

*Шура. – 1914. – № 2. – Б. 57–58.*

## [ТАҢ, АЛТЫН ЧЫГАРУ ТУРЫНДА]

**Ахун (Верхурал өязеннән):**

1. Китапларда «дөрес таң» һәм дә «ялган таң» исемле ике төрле таң барлыгы сөйләнә. Гүя боларның әүвәлгесе югарыга сузылган һәм соңгысы да офыкта аркылы таралган була икән. «Мөселманнар таң беленде инде, дип сәхәр ашамый калсыннар өчен, Каф тавы артында шайтаннар ут ягып яталар да, шуның яктысы күккә сузылып төшә, шул яктылык ялган таң була», – дип безгә өйрәткәннәр иде. Шул сүз дөресме?

2. Газеталар кайбер мәмләкәтләрнең бурычлары бик күплеген язалар. Һәрбер хөкүмәт үзенең эчке эшендә мөстәкыйль булганнан соң, акчаны күбрәк эшләтергә кирәк иде. Мәсәлән, Русиянең үзендә никадәр күп алтын чыгып та, бурычка керүендә хикмәт нәрсәдә? Бу эш икмәк пешереп сатучының кешеләрдән бурычка икмәк җыюына охшамыймы?

*Мөхәммәт бине Госман Юнысов.*

**«Шура»:**

1. Кайбер урыннарда һәм кайбер вакытларда таң алдыннан шундый үзенчә бераз яктылык сизелә. Ләкин ул шайтаннар яккан ут яктылыгы түгел, бәлки җирнең безгә каршы тарафта булган кояш яктылыгынан чагылган яктылык.

2. Мәмләкәтләрнең чыгымнары шулкадәр күптер ки, үзләреннән чыгып торган алтын һәм башка хәзинәләр шуны капларга җитә алмый. Русиядә алтын күп булса да, ул күктән явып тормый, аны чыгару өчен дә күп чыгымнар кирәк. Әгәр дә Каф тавы артында урман яндырып, кызынып ятучы шайтаннар килеп тә, алтыннарны бушка чыгарып торсалар, әлбәттә, алтын күп чыгар һәм дә чыгымнарсыз хасил булыр

иде. Ләкин шайтаннарны хезмәткә җигәрлек көч юк. Русиядә алтын күп, ләкин ул алтын арыслан авызында! Шуннан алуы читен.

*Шура. – 1914. – № 3. – Б. 87.*

## [ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ҖӘМӘГАТЬ БЕЛӘН НАМАЗ УКУЛАРЫ ТУРЫНДА]

**Чистай (дини бер сорау):**

Җәмәгать булып намаз укуның фазыйләтле эш икәнлеге хакында хәдисләр бик күп булды. Шушы хәдисләр тик ирләргә генә хас булмый, бәлки хатыннар җәмәгатьләрен эченә алган төсле күренсә дә, фикыһ галимнәренең байтагы араларыннан берсен имам итеп, хатыннарның җәмәгать булып намаз укуларын мәкруһ [хупланмаган эш итеп] күргәннәр. Шулай булса да, олуг галимнәр арасында моңа каршы булучылар да бар. Мәсәлән: 1. Ибне әл-Һөмам «Фәтх әл-кадир»дә, Рәсүлуллаһ әмеренә күрә, хәзрәте Гайшәнең хатыннарга имам булып намаз укуын сөйләгәннән соң, хатыннарның җәмәгать булып намаз укуларының шәригатьтә дөрес булуы гамәлдән чыкмавын аңлата. 2. Гали әл-Кари «Мохтасар» шәрехендә Гайшә һәм Өмме Сәләмәнең хатыннар җәмәгатьләренә имам торып, намаз укуларын риваять иткәннән соң, «Шәрхе Мәҗмәгъ»тән «Хатыннар җәмәгатенең мөстәхәб [яхшы эш] булуы гына гамәлдән чыкты» дигән сүзне күчерә һәм дә «Мондагы мәкруһлык, чыгуга нигезләнгән булып, дөреслек исә пәрдәләнүгә нигезләнгән», – ди. 3. Габделваһһаб Шәгърани «Әл-мизән әл-күбра»сында хатыннарның җәмәгать булып [намаз] укуларын имам Шафигый һәм Әхмәд каршында мәкруһсыз, дөрес дип риваять кыла. Бу мәсьәләнең әһәмияте мәгълүм. Хәзер безнең бәхәс-

ләшүебезгә сәбәп булган нәрсә – кызлар мәдрәсәсендә гыйлем алучы кызларның ялгыз-ялгыз намаз укулары булды. Үз араларыннан берәрсен имам [итеп] куеп, җәмәгать булып [намаз] укысалар, яхшы булмас идеме, дип хәтеребезгә төште. Кыскасы гына, бу мәсьәләдә «мәкруһлык» белән җәмәгать намазы хакында булган фазыйләт кара-каршы тора. Шуларның кайсын өстен күрү тиешле? Җәмәгать намазы хакындагы шатлыклы хәбәрләрне ирләргә генә хас итәргә дәлил бармы? Хөрмәтле галимнәребезгә тәкъдим итү нияте белән «Шура»га язуыгызны үтенәбез. «Шура» үз фикерен дә өстәсә, зарар булмас иде.

*Чистайда мулла Шиһабетдин Шәрәфетдин улы.*

**«Шура»:**

Хатыннарның ирләргә имам булып укуларыннан тыя торган шәригать дәлилләре булса да, үз араларында җәмәгать булып укуларыннан тыя торган шәригать дәлилләре булуы безгә мәгълүм түгел. Шулай ук җәмәгать намазы фазыйләте хакында килгән дәлилләрне ирләр җәмәгатенә генә хас итүчеләрнең сәбәпләре безгә мәгълүм булмады. «Һидәя» авторының «Хатыннарның җәмәгать булып укулары исламның әүвәлге вакытында иде» дигән сүзе – һич шөбһәсез, каләм хатасы. Хәзрәте Гайшә Рәсүлуллаһ гомеренең ахырында бары тугыз ел кадәр генә бергә торды. Аның гамәлен ничек итеп исламның әүвәлге хәленә йөкләргә мөмкин? Ибне Габделбәр «Әл-истигаб»та (Т. 2. – Б. 806) Өмме Вәрака хакында: «Пәйгамбәр (аңа сәлам булсын) аңа үз гаилә әгъзаларына намазда имам булырга әмер итте. Аның мөәзине дә булды. Колы аны буып үтергәнче, ул үз гаиләсендә намазда имам булды...», – ди. «Хәттәә»

[«буып үтергәнче»] сүзеннән Өмме Вәрака шәһит булган көненә кадәр бу хәлендә дәвам иткәнлеге аңлашыла. Өмме Вәраканың хәзрәте Гомәр заманында шәһид булуы мәгълүм. Хәнәфи мәзһәбендә билгеле риваятьне күчерергә махсус булган «Әл-мәбсут»та (Т. 1. – Б. 187) очраклы сәбәпләрне бәян иткәннән соң, «Хатыннарга аерым укулары хәерлерәк» дип искә ала. Бу «үләә» [«хәерлерәк»] сүзе, аеруча аның сәбәпләре табылмаган вакытта Сөннәткә каршы түгел. Ибне әл-Һөмамның риза булган сүзе дә бу рәвешле булырга охшый. Сүзнең кыскасы: өйләрдә булу шарты белән, хатыннарның җәмәгать булып намаз укулары – ирләр җәмәгате шикелле фазыйләтле бер эш. Безнең өстәвебез – бу. Бу өстәмә әлеге мәсьәлә хакында башкаларның сүз сөйләүләренә киртә түгел.

*Шура. – 1914. – № 3. – Б. 88.*

## [ӘҮЛИЯЛӘР ТУРЫНДА]

**Керәч:**

Бездә сырхауларның күбесе хастәханәгә докторга китмиләр дә, ике йөздән артык ел элек калган кабердә газиз үлеккә барып, аннан авыруына шифа сорыйлар. Шул кабердәге үлек тә үзенең тере вакытында гадәттән тыш бер эш күрсәткәнлектән, әүлия (кәрамәт [могҗиза] иясе) булган зат була. Моңа күрә, гадәттән тыш бер эш күрсәтеп тә, әүлия булган бер зат хәзерге заманда ни өчен булмый? Булса да, безгә беленмиме? Элек ничек беленде? «Шура»да җавап язылса иде.

*Мөгаллим Сәед Мөхәммәд.*

**«Шура»:**

Адәм балалары арасында һәрвакытта Аллаһ Тәгаләгә әүлияләр (дуслар) булырга мөмкин. Ләкин шушы әүлияләрне билгеләп белү Рәсүлуллаһ хәбәреннән башка мөмкин түгел. Чөнки кешеләрдә, әүлиялекне белер өчен, шуннан башка юл юк. Дөньяда булган гадәттән тыш нәрсәләр һәм, фәлсәфә терминына күрә, «табигать хаталары» – хакыйкать хәлдә, тышкы сәбәпләргә багланып та, шул сәбәпләрнең адәм балаларыннан яшерен торуыннан гыйбарәт нәрсәләр. Шуңа күрә бер нәрсәнең бер вакытта гадәттән тыш нәрсә булып, икенче бер вакытта гадәти нәрсә булуы мөмкин. Мәсәлән, телефон – сәбәпләре мәгълүм булмаган бер вакытта гадәттән тыш нәрсә, әмма сәбәпләре мәгълүм булганнан соң икенче вакытында гадәти нәрсә [булып] санала. Ирләр белән катышмый торып, нәсел үрчетү һәм үлгән тәннәргә кире җан кертү, аннан туган сукырларның күрә алу сәбәпләрен табар өчен тырышучылар бар. Болар шушы максатлары юлында төнкөннәрен белмичә тырышалар һәм даими тәҗрибәләр белән шөгыльләнәләр. Әгәр дә шушы эшкә ирешкән булсалар, болар, безгә күрә, гадәттән тыш нәрсәләр булсалар да, үзләренә күрә, табигый бер эш булачагы мәгълүм. Шуның өчен гадәттән тыш нәрсәнең әүлиялеккә дәлиле юк. Әгәр дә берәр гадәттән тыш нәрсәнең кәрамәт булуы Коръән һәм хәдисләрдән аңлашылса яки Рәсүлуллаһ тарафыннан хәерле үлем белән хөрмәтләнгән булачаклары хәбәр бирелгән кешеләр [сәхабәләр] кулыннан чыкса, шуларга кәрамәт булу белән хөкем кылу дөрес булса да, алардан башка сурәттәге гадәттән тыш нәрсәләргә кәрамәт булу белән хөкем кылу арттыру һәм исраф булачагында шөбһә юк. Гомәр бине әл-Хаттаб хәзрәттән чыккан бер гадәттән тыш нәрсәне (әгәр дә кабул ителгән юл белән күчерелгән булса) кәрамәт дип хөкем кылырга яраса да, Гомәр бине Габделгазиз, шулай ук Әбү

Язид әл-Бистами, Җүнәйд һәм Шәбли кебек адәмнәрдән риваять ителгән гадәттән тыш нәрсәләр (әгәр дә кабул ителгән юл белән күчерелгән булсалар) хакында кәрәмәт булу белән хөкем кылу – дуамаллык һәм юкны юраган дәгъвадән башка нәрсә түгел. Кыскасы: бер гадәттән тыш нәрсәнең кәрәмәт булуын белү, я пәйгамбәр тарафыннан ачык хәбәр бирелү яки кайбер хәдисләре шуны ныгыту белән генә мөмкин булыр. Кәрәмәт хакындагы хәбәрләрнең урта гасырларда бик күп булып та, бүген бетүенең сәбәбе бик ачык. Урта гасырларда матбугат юк иде. Махсус кешеләр арасында ифрат дәрәҗәдә олуг галимнәр булуына карамастан, гади халык гомуми рәвештә ифрат дәрәҗәдә надан иде. «Җәрех вә тәгъдил» [хәдис сөйләүчене гаепләү яки мактау, ягъни дөрес сөйлиме-юкмы икәнен тикшерү фәне] галимнәре шәехләр һәм мөридләрнең хәдисләренә (алар каршында, мөселманга яхшы уйлау мәҗбүри, шуның өчен нинди сүз ишетсәләр дә, кабул итәләр, дип) ышанмыйлар яки бик нык тикшереп, шөбһә урыны калмаганнан соң гына, кабул итәләр, әмма гадәти хәбәрләренә әһәмият бирмиләр иде.

Бу сәбәпле, объект ияләре һәм дөньяви файда китерә торган ау коручылар өчен мәйдан иркен калды (гади халык гомуми рәвештә надан, «җәрех вә тәгъдил» галимнәренә илтифат итмиләр, матбугат юк). Болар үз максатларына җитәр өчен, һәртөрле кәрәмәт хәбәрләре таратып тордылар һәм гади халык арасына тәмам урынлаштылар. Соңрак язучылардан бер төркем бу халык арасында таралган хәбәрләрне «мәшһүр» һәм «мөстәфыйд» [киң таралган] хәбәрләр җөмләсенә кертеп, китапларына яздылар. Хадими кебек ахырзаман галимнәре шушы нигезсез нәрсәләргә: «Үлгән пәйгамбәрләр һәм изгеләр аркылы Аллаһ Тәгаләгә ялвару һәм ярдәм сорау рөхсәт ителә, чөнки аларның могҗизалары һәм кәрәмәтләре үлемнәреннән соң тукталмый» кебек икенче бер

нигезсез һәм ялган дәгъваларын төзеделәр. Әмма бүген кәрәмәт хәбәре тарату бик бәһале төшәчәк. Чөнки бүгенге халыклар арасында әүвәлге гасырларның аерым галимнәре дәрәҗәсендә олуг галимнәр булмаса да (бу сүз гомуми фикерләр ышануына күрә сөйләнә), бүгенге гади халык әүвәлге гасырлардагы халык мәртәбәсеннән бик югары һәм бик аңлы. Тарихчыларның имамы булган Мәсгуди Могавиянең чәршәмбе көн җомга намазы укуын һәм ничә меңнән гыйбарәт сәләфләрнең, шуңа һич каршы төшмичә, оеп җомга [намазы] укуларын риваять итә. Бүген Русия мөселманнарының иң надан авылына, хәтта Истанбулдан солтан килеп, җомга намазын чәршәмбе көн укырга кушкан тәкъдирдә «Җомга намазының вакыты чәршәмбе көн түгел, бәлки җомга көн» дип әйтә алырлар һәм солтан сүзенә һич буйсынмаслар. Моннан башка, һәртөрле вакыйга һәм мажараларга бүген милли матбугат контроль булып торганлыктан, юк хәбәрләр таратып та, зиһеннәргә урынлаштырып калдыруга мөмкинлек юк. Мәсәлән, бүген бер Габделкәрим мулла чыгарып та, ишаннар өстенлекләре хакында китап язса һәм җөмләдән: «1. Безнең шәехебез Шәриф авылыннан Әхмәт хәзрәтне быелгы хаҗилар Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында күреп, күрешеп кайттылар. Әмма үзе шул Корбан гаетен үз мәхәлләсе булган Шәриф авылында укыды. 2. Шәехебез белән юл йөргәндә, бик ачыктык та, шәехебез дога кылган иде, алдыбызда икмәк, кыздырган ит, бер савыт саф су пәйда булды. 3. Бервакыт Дим елгасы аркылы чыгарга туры килде, ләкин күпер дә юк, көймә дә. Шуннан соң шәехебез намазлыгын җәйде дә, икебез шуның өстенә утырдык та, [елга] аркылы чыгып киттек. 4. Бервакыт кырда барганда, мөридләр бик сусадылар. Шулвакыт шәехебез җиргә аягы белән типте дә, шуннан атылып чишмә чыкты һәм бер тарафка агып та китте. 5. Шәриф авылының башкортлары һәм кымызга кил-

гән мөгаллимнәр кәрәмәт хәбәрләренә ышанмыйлар иде. Шәехебез беркөн урманга барганда бер бүре өстенә атланып, бүренең колакларыннан тотып, көн уртасында авылга кайтып керде һәм: «Кәрәмәткә ышанмый торган башкортлар, мөгаллимнәр! Менә инде күрегез!», – дип, урам уртасында туктап торды, шуннан соң Шәриф авылы башкортлары һәм кымыз эчеп ятучы мөгаллимнәр, хәтта урыс маржалары да кәрәмәт хәбәрләренә ышана торган булдылар. 6. Шәехебезне зиярәт кылыр өчен дип, Бубида [данлыклы Иж-Буби авылы мәдрәсәсендә] укыган бер мулла Вятка губернасыннан килгән иде. Шәехебезне күреп, сөйләшеп утырганнан соң, ни өчендер шәехебезне үзе фараз иткән рәвештә тапмаган һәм күңеленнән: «Сәфәрем әрәм булды», – дип хисаплаган. Ахшамнан соң тәһарәткә дип чыкса, бик куркыныч рәвештә бер бүре бу муллага каршы килгән. Мулла куркып, шәехебез янына йөгереп кергәннән соң, шәехебез чыккан да, бүрегә гыйбрәт белән: «Мин сезгә, кунакларны куркытмагыз, дип әйттем бит, шул сүземне ник оныттыгыз?...» – дип кычкырган. Бүре дә шул сәгать белән коерыгын бутап, шәехебезгә ялына башлаган һәм шуннан соң урманга киткән. Шулвакыт шәехебез Буби шәкертенә карап: «Сез менә тышкы ягыгызны гына төзәтәсез, шуның өчен бүредән куркасыз. Әмма без эчке ягыбызны (күңелебезне) төзәтәбез, шуның өчен бүре безнең үзебездән курка», – дип, Буби шәкертенең йөзен кызарткан» эчтәлегендә маҗаралар язса, һәр кешедән элек, Шәриф авылындагы куян куып йөрүче башкортлар протест ясарлар. Матбугатта Габделкәрим мулланы кырмыска оясына утыртылган адәм дәрәҗәсенә китерерләр.

Кәрәмәт хәбәрләре таралуга әүвәлге заманнар ирек бирүче иде. Әмма хәзерге заман мөмкинлек бирүче түгел. Бүген кәрәмәт хәбәрләре булмавының сәбәбе – бу.

Инглизнең иң зур сугыш көймәләреннән булган «Виктория»нең Тараблис Шам янында батуы бик күп адәмнәрнең хәтерләреннән чыкмагандыр. Маневрны карар өчен яр буена җыелган җәмәгать арасыннан яшь бер гарәп түрәсе иптәшләренә мәзәк хәл итеп, бөтен җәмәгать янында: «Иптәшләр, шушы инглиз сугыш көймәләреннән берсен батырсам, минем буш кеше түгел икәнлегемне танырсызмы? – дигәч, иптәшләре: «Хәзер кулыңны үбәбез, үзебез мөрид булабыз!», – дигәннәр. Бу сүзне әйтеп бетерер-бетермәгәндә, «Виктория» дә бата башлап, берничә секунд эчендә диңгез төбенә киткән. Моны гарәп матбугаты «Гаҗәеп туры килү» исеме белән газеталарда яздылар һәм берсеннән-берсе күчереп, бөтен дөньяга тараттылар. Мондый нәрсәләрне бүгенге халык «туры килү» дип атый. Әмма борынгылар шундый нәрсәләрнең бик күбесен кәрамәт дип санаганнар. Ерткыч хайваннарны буйсындыру белән кәрамәт арасында мөнәсәбәт булмаса кирәк. Бүгенге фән әһелләренең тикшерүләренә караганда, кайбер адәмнәрнең күзләренә табигать тарафыннан шундый куәтләр куелган буладыр ки, шул күзләргә каршы торырга хәтта арысланнарның да көчләре булмый. Бер немец кызының Африка урманнарыннан коры кулы белән арысланнар тотып кайтуы газеталарда язылган иде.

Рәсүлуллаһ хәзрәт хасталар хакында әүлияләр каберләренә йөреп түгел, бәлки дога кылу белән боера, үзе дә шул вакыттагы тәҗрибәләргә күрә гамәл кыла иде. Хәтта Рәсүлуллаһның «Һәр чиргә дәва бар» (Сахихе Мөслим. – Т. 2. – Б. 184) дигән сүзендә бүген дәвалары табылмый торган хасталыкларның да киләчәк заманнарның берсендә дәвалары табылачагына ишарә бар. (Әлбәттә, бу дәваларны табар өчен Коръән һәм хәдис белән гамәл кылырга әһәмият бирми торган мөселманнар тырышмаслар). Хәзрәте Рәсүлуллаһның

рөхсәте белән үзенең хатыны Өмме Сәләмәгә Әбү Тайййибә исемле бер сәхабә кан алдырган иде (Сахихе Мөслим. – Т. 2. – Б. 184.). Сәгъд бине Әбү Ваккас хасталангач, Рәсүлуллаһ хәзрәт Харис бине Килдә исемле бер гарәп табибын чакырып, дәвалаткан иде (Үсд әл-габә. – Т. 1. – Б. 345).

Бу мәсьәләнең итәге бик озын һәм бик киң булганлыктан, бу кадәр белән кәнәгатьләндек.

*Шура. – 1914. – № 12. – Б. 376–377.*

## [УТЫЗ ИМӘНИ ШИГЫРЕ ТУРЫНДА]

**Уральск:**

Мәрхүм атабыз хәзрәтнең Бохарада укыган язма «Шәрхе гакаид гадудийййә»сенең ахырында мондый сүзләр язылган:

«Габдерәхим мулла Утыз Имәни Казани әйтте:

«Зәгыр михнәт чикте җисемем, түкте күзем зәгыр аб,

Зәгыр гакыбы шәрехем булсын зәгыр тарихтан җавап»«.

Габдерәхим Утыз Имәни хәзрәт хакында «Әхмәт Мидхәт әфәнде» китабында: «Күп язучыларыбыздан» дип бер сүз күргән идем. Бу затның тәрҗемәи хәле мәгълүмме? Әсәрләре күбрәк нинди темаларда һәм басылганмы? Искә алынган шигырьнең соңгы юлы Утыз Имәнинең үз тормышыннан берәр вакыйгага ишарә түгелме? Чөнки «зәгыр» сүзе астына 1207 елы язылган? Шул мәсьәләләрдә «Шура»да мәгълүмат бирсәгез, шат булыр идек.

*Әбессогуд Әхмәди.*

**«Шура»:**

Соңгы юлындагы «зәгыйр» сүзе Әбҗәд хисабы белән ел. Шул [һиҗри] 1207 дә язган була. Башкаларын өзеп әйтергә көчебез юк. Икенче юлдагы «зәгыйр» «ташу» мәгънәсендә булырга мөмкин. Һәрхәлдә, мондый нәрсәләрне белүдән бертөрле файда һәм белмәүдән һичбер зарар булмас. Белү ләззәте белән гомер сарыф итү михнәте каршы китерелсә, соңгысына караганда әүвәлгесе бик вак нәрсә булып кына калыр. Мондый нәрсәләр риторика һәм сәнгатьле сөйләм галимнәре каршында да макталмый. Габдерәхим хәзрәтнең тәрҗемәи хәле «Мөстәфадел-әхбар» һәм «Асар»да искә алынган һәм бу китапларның икесе дә басылган. Әсәрләренең күбрәге ишаннарга каршы торудан гыйбарәт булып, кыска китапларыннан бик азы гына басылган.

*Шура. – 1914. – № 12. – Б. 378.*

## [АЙ КУЮ ТУРЫНДА]

**Казан:**

Хәзрәте Рәсүл заманасында мөселман мәчетләренең манаралары һәм манараларында ай булганмы? Булмаса, кайсы заманда ай кую чыккан? Ул ай нәрсәнең галәмәте?

*Суфия Таһирия.*

**«Шура»:**

Ай куюның мөселманлыкка һичбер бәйләнеше, ай галәмәтенең һичбер изгелеге юк. Мөселманнарда ай рәсеме галәмәт булып, бары Истанбул төрекләр кулына кергәннән соң башлана. Мәчет манараларына менүе аннан күп соң булып, кайбер мәмләкәтләргә генә хас. Хәзер дә ислам дөньясының күбесендә мәчет манараларына ай кую гадәте юк.

Ай галәмәте кую ничек чыгуы хакында күп тарихи тикшеренүләр булды. Бу мәсьәләнең иң зур галимнәреннән Истанбул гаскәри музее мөдире Әхмәд Мохтар паша хәзрәт айның элекке Истанбулда Византия дәүләтенең рәсми галәмәте булганын һәм христианнар тарафыннан изгеләштерелгәнен исбатлады. Манараларда хәзрәте Рәсүлдән күп [вакыттан] соң пәйда булды. Алар да Иран һәм Рум архитектура ысулының тәэсире белән.

*Шура. – 1914. – № 14. – Б. 441.*

## [АДӘМҺӘМ ХАВА ТУРЫНДА]

**Сәмәрканд:**

Түбәндә искә алыначак сорауларыбызга җавап биреп, безне шөбһәләнүдән чыгаруыгызны үтенәбез.

1. Адәм галәйһиссәлам җир шары туфрагыннан бар ителдеме яки башка бер шардамы? Әгәр дә җир шары туфрагыннан яратылган булса, кайсы урында иде?

2. Җир шарында бар ителгән булса, аның торган җәннәте шушы җир йөзендә булдымы яки башка идеме? Яисә савап йорты булган җәннәттә тордымы? Әгәр дә савап йорты булган җәннәттә торган булса, җир йөзенә нинди рәвештә иңде? Аллаһ Тәгалә тарафыннан тыелган агач нинди агач иде?

3. Хава, Адәм галәйһиссәламнең сул кабыргасыннан берәр кабырга киселеп алынып, бар ителдеме яки, авырлы кебек, берәр артык нәрсә булып, шуннан төштеме? Аллаһ тәгалә Адәмне туфрактан бар иткән кебек, Хаваны да туфрактан бар итмәвендә хикмәт нинди нәрсә булды?

5. Адәм галәйһиссәламнең буе ни кадәр биек иде? Сәрәндиб утравыннан чыкканда, диңгездән ничек үтте?

*С. Х. С.*

**«Шура»:**

Адәм белән Хава заманнарында дөньяда булмаганыбыз һәм аларның хәлләрен күреп тормаганыбыз сәбәпле, бу сорауларыгызның берсенә генә булса да җавап бирергә кодрәтебез җитми. Безне гозерле күрегез. Дөресе, мондый сорауларыгызның җавапларын Кәгъб әл-Әхбардан [Тәүраттан алынган сүзләрне сөйләп йөргән табигыйн исеме] башка кешеләр бирә алмаслар. Моның кебек булган бәхәсләрнең ни өчен кирәк булганлыгын аңламавыбыз сәбәпле, без үзебез, тузан кадәр булсын, әһәмият бирә алмыйбыз. Хәтта халыкның шушындый мәсьәләләр белән баш ватулары өчен гаҗәпләнәбез.

*Шура. – 1914. – № 21. – Б. 669.*

## [ДИНИ РУХ БИРҮ ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Һәрвакыт ишетәбез «Ысул җәдидә мәктәпләре шәкерт балаларга дини рух бирә алмый» дигән сүзләрне. Чынлыкта, бу сүз дөресме яки бер буш сүзме? Әгәр дә бу сүз дөрес булса, бу кимчелек кемдә? Мөгаллимнәрдәме яки мәктәптә укыла торган китаплардамы? Башлангыч мәктәпләр нинди нигез белән булырга тиеш? Башлангыч мәктәпләрдә укыла торган китаплар нинди рухта язылган булырга тиеш?

*Г. Кәрими.*

**«Шура»:**

«Ысул җәдидә мәктәпләре дини рух бирәләрме, юкмы» мәсьәләсендә бик күп яздылар һәм озын бәхәсләр алып бардылар, һаман да алып баралар. Ләкин дини рух үзе нинди нәрсәдән гыйбарәт? Мәктәпләрнең дини рух бирү-бирмәүләре хакында бәхәсләшүдән элек, дини рухның үзен билгеләргә ихтыяҗ бар иде. Халык арасында динне аңлау

бик төрле рәвештә. Бер адәм динне бик аз нәрсәдән һәм дә бик тар нәрсәләрдән гыйбарәт [дип] белгән хәлдә, икенче берәүләре бөтенләй киң рәвештә аңлыйлар. Ислам дөньясында бер-берсен көферлеккә чыгару, имансыз дип караулар да бу аңлашылмау һәм динне һәркемнең үзенчә аңлавы нәтиҗәсе булды. Газали, динне үз аңлавына күрә, Ибне Сина һәм Фарабиларны көферлеккә чыгарды. Мәрҗани, динне үз аңлавына күрә, Газалинең Ибне Сина белән Фарабины көферлеккә чыгаруын хата дип санады. Казый Гыяз, динне үз аңлавына күрә, Газалинең мөселман түгеллеге белән хөкем төзеде. Бу турыдагы бәхәс һәм маҗаралар озын. Ысул җәдидә мәктәпләренең шәкертләре һәм мөгаллимнәре хакында «динсезләр һәм атеистлар» дип сөйләнгән бер мәҗлестә бер адәм: «Мин элекке мәдрәсәләребезнең йөзьеллык тарихын һәм аларда булган гакыйдә һәм мәсләкләрне беләм, бу турыда һәрбер сүземне дәлилләр белән исбат итәргә кодрәтем бар, хәҗәт күренсә, бүгеннән исбат итәм. Ысул җәдидә тарихыннан да хәбәрем юк түгел. Миңа күрә, элекке мәдрәсә шәкертләре әхлаксыз, бозыклар, икейөзле һәм монафыйклар, мәсләксез һәм вөҗдансызлар, гади халык күрмәү шарты белән, һәрбер кабәхәтлекне эшләргә әзер иде. Диндә ныклык һәм дингә мәхәббәт, ысул җәдидә шәкертләре белән чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә түбән иде», – [дигән] мәгънәдә сүз сөйләде. Моның бу сүзе дә динне үз аңлавына күрә. Шуның өчен ысул җәдидә мәктәпләренең шәкертләргә дини рух бирү-бирмәүләреннән бәхәсләшүче адәмнәр иң элек үзләренең динне аңлауларын һәм дини рухның нинди нәрсәдән гыйбарәт икәнлеген берәр төрле билгеләүләре зарур. Шулай итми торып, бу бәхәстән бер мәгънә дә чыкмас, сүз үрчетүдән башка җимеше булмас.

*Шура. – 1914. – № 22. – Б. 700.*

## [КАБЕРЛӘРНЕ ИЗГЕЛӘШТЕРҮ ТУРЫНДА]

**Җәләлабад:**

Безнең торган урыныбыз – Җәләлабад шәһәре – «Хәзрәт Әюп зираты», «Сөләйман тәхете», «Хәзрәт Юныс» дигән мәшһүр зиярәт кыла торган урыннарның уртасында булганлыктан, шул җирләргә зиярәт кылыр һәм максатларын сорар өчен килгән мөселманнарның хәлләрен бик беләбез. Шушы урыннарга бик ерак мәмләкәтләрдән мөселманнар киләләр, һәр ел бер мең микъдарында корбан бугазлана. Килүчеләрнең сәфәр чыгымнары, сәдака һәм нәзерләре бер җиргә җыелса, бик күп меңнәргә җитүендә шөбһә юк. Мөселманнар шушы каберләр һәм мәетләр яннарында рөкүгъ, сәҗдә кылалар, туфракларын изеп, эчәләр, шәмнәр яндыралар, корбаннар бугазлыйлар. Шушы хәлләр үз башыбыздан да үтте. Сәмәрканд шәһәреннән зиратлар хакында соралган бер сорауга үткән елгы «Шура»ның 11 нче санында бер җавап язылган иде. Искә алынган җавап бу тарафтагы халыкларга бик олуг тәэсир бирде. Кайбер адәмнәр: «Безнең хакыйкать ияләре һәм кәрәмәт ияләре [булган] ишаннарыбыз, гыйлем һәм белем чишмәсе булган Хуҗа Баһаветдин солтанел-гарифиннәребез, мәүляна Борһанетдиннәребез, имам Әбүбәкер Кафәл Шаши, Исмәгыйль Бохари, Габдулла Сәмәрканди, Хәким Әбелкасыйм Сәмәрканди, Галлямәи Тафтазани, Хуҗа Әхрар, Мәүләви Җами, Әбү Гали Синаларыбыз бар иде. Алар Риза казый кадәр белмәделәрме? Белә торып, аларның яхшылыкка чакырмыйча калулары сурәт тотылмый? Риза казый һәм аның юнәлешендә булганнар безнең галимнәребезне һәм шәригать казыйларыбызны, шәех һәм суфиларыбызны, мәктәп-мәдрәсәләребезне, имам һәм дәрвишләребезне тәнкыйтьләүләренә канәгать итми, инде үзләренең әдәпсезлекләрендә ахыргы дәрәҗә алга китеп, күктә булган фәрештәләрне тәнкыйтьләргә керештеләр, җир астына төшеп, әүлияләребезне кимсетә башладылар. Куй, мәетләр тыныч ятсыннар!..», – диләр. Шуның өчен бу мәсьәлә тагын бер

мәртәбә «Шура»да бәхәс ителеп үтсен, хаклык белән ялган аерылсын иде. Әгәр дә хата сөйләгән булса, «Шура» үзенең сүзен кайтарып алсын иде. Без өч зират уртасында тереклек итүебез сәбәпле, шушы мәсьәләне бераз аңлыйсыбыз һәм шәригать хөкемен беләсебез килә. «Шура» сүзен укыганнан соң, үземнең әүвәлге хәлләремә пошаман булам, әмма аның каршылары сүзен ишетсәм, бераз икеләнүдә калам. Безнең кебек башка адәмнәр дә, бәлки, бардыр.

*Таҗетдин бине Мөхәммәдриза Бәделбаев.*

**«Шура»:**

«Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» исемле әсәрнең 172 нче битендә булган 37 нче маддәнең шәрехен ахырына кадәр укып чыксагыз, сорауларыгызның җаваплары, иншалла, табылыр. Каршы килүчеләр тарафыннан искә алынган исемнәр арасында бик хөрмәтле һәм ышанычлы затлар бар. Ләкин шулар заманнарында әрвахлардан ярдәм сорау, хәҗәт сорау өчен бик ерак җирләрдән кабер һәм зиратларга сәфәр чыгу, үлекләр янында корбан бугазлау кебек бидгатьләр таралган идеме? Таралса, шул могтәбәр затларның күрә һәм белә торып, яхшылыкка чакыруның биш-алты мәртәбәсеннән берсен генә булсын, эшләмәүләре дөрес булдымы? Дөрес булса, пәйгамбәрләрдән башка адәмнәрнең белә торып дәшмәүләре бер нәрсәнең шәригатькә туры килүе өчен дәлилме? Дәлил булса, Шәригать иясе [Аллаһ] һәм дин ирештерүче пәйгамбәр белән аңа өммәт булган гыйлем һәм белем чишмәсе, кәрәмәт һәм гадәттән тыш эшләр иясенең сүзләре һәм гамәлләре бер-берсенә каршы килгәндә, кайсыларының сүзләре һәм гамәлләре алда тотылырга тиешле? Менә каршы килүчеләрегез шушы темаларның һәрберсендә тукталып, җавап бирергә тиешлеләр. Тиешле җавапларны биреп үтсәләр, аларның сүзләре хак булыр. Риза казый юнәлешендә булучылар шәригать казыйларын, шәех-суфиларны, мәктәп-

мәдрәсәләрне тәнкыйтьләмичә, Ямь-ямьләрнең аучыларын, Австралиянең балыкчыларын тәнкыйтьләсеннәр идеме? Болар кайсы вакытта һәм кайсы урында фәрештәләрне тәнкыйтьләделәр? Әгәр дә каршы килүчеләр шуны исбат итә алмасалар, яла ягучылар булырлар, ягъни ахыр дәрәҗәдә әдәпсезлек итүнең сыйфаты үзләренә ябышып калыр, моны һичбер юл белән юып бетерә алмаслар. Үлекләрнең тыныч ятулары таләп ителгән булган өчен дә, алардан ярдәм сорау һәм яннарында корбан бугазлау, сәҗдә һәм рөкүгъ кылу ярамаганлыгы бәян ителә. Инде ничә еллардан бирле мөселманнар Хуҗа Баһаветдин, Габделкадыйр әл-Киляни, Бәдәви һәм Хуҗа Әхмәт Ясәви кебекләрне тыныч яткырмыйча газаплыйлар һәм һәрберсен Аллаһ Тәгалә янында оятлы итеп тоталар. «Шура» мөселманнарны мәетләрне тыныч һәм рәхәт тотуга өнди, үтенә, ялына, ялвара. Әгәр дә шушы эш Бохара һәм Төркестан галимнәре каршында әдәпсезлек, хәтта ахыр дәрәҗәдә әдәпсезлек саналса, моңа кайгырабыз. Тик мондый фикер, мондый гакыйдә Бохара һәм Төркестан галимнәренең һәрберсендә түгел, бәлки кайберләрендә генә булып, мәсьәләне аңлаучылар алар арасында да күп булса кирәк. Алты дөрес хәдис җыентыгында булган хәдисләрнең эчтәлеген сөйләү сәбәпле, әүлияләр кимсенмәсләр. Кимсенүчеләр булса, алар әүлия булмаслар. Кирәк Хуҗа Баһаветдин, кирәк башкалар булсын, Рәсүлуллаһ тарафыннан билгеләнеп, хәбәр бирелгән вакытта, мәгълүм бер адәмне әүлия дип хөкем чыгару – ахыр дәрәҗәдә хәтәр эш. Хуҗа Баһаветдин хакында «Мөселман булып вафат булды» дип катгый сурәттә хөкем чыгару мөмкин булмаса, әүлия дип хөкем чыгару ничек мөмкин була?.. Моны бер фикерләп карау тиешле иде.

*Шура. – 1915. – № 1. – Б. 26–27.*

## [ХӨТБӘНЕ ТӨРКИЧӘ (ТАТАРЧА) УКУ ТУРЫНДА]

**Оренбург:**

Бу сәфәребездә Ташкент шәһәрендә бер мәҗлестә булдык. Шул мәҗлестә бер галим: «Җомга хөтбәсе укылган вакытта, гарәпчәдән башка аз гына сүз сөйләнсә дә, җомга намазына кимчелек килә, шуның өчен без хөтбә арасында төркичә сүз кушмыйбыз (төркичә хөтбә сөйләмибез)», – диде. Шушы мәсьәләдә «Шура» идарәсе үз фикерен бәян итсен иде. Бу хатны Мәскәүгә барышыбызда Оренбург вокзалына салып китәбез.

*Гарифулла Сафиуллин белән Садыйк Яушев.*

**«Шура»:**

Бик күп адәмнәр бар, үзләрен Әбү Хәнифә мәзһәбендә саныйлар һәм шул мәзһәбкә бик бәйләнгән булуларын дәгъва кылалар. Әмма үзләренең мөгамәләләре шушы дәгъваларына бөтенләй каршы була. Әбү Хәнифә: «Фарсыча тәкбир [«Аллаһү әкбәр» сүзләре] белән намазга керешүнең, намаз эчендә Коръәнне фарсыча укуның намазга зарары юк», – дип сөйли. Әмма аның мәзһәбенә бәйләнгән булуны дәгъва кылучылар: «Хөтбәдә төркичә сүз сөйләү җомга намазына зарар китерә», – диләр. Бу кадәр мөнәсәбәтсез эш аз булса кирәк. Хәнәфиләрнең ышанычлы китапларының берсе булган «Әл-мәбсут» гарәпчәдән башка тел белән хөтбә укуның Әбү Хәнифә каршында дөреслеген ачык бәян итә (Т. 1. – Б. 37). Бу исә хөтбә итеп гарәпчә бернәрсә дә укылмаган тәкъдирдә. Әмма гарәп теле белән хөтбә исеме бирерлек дәрәҗәдә бер нәрсә укылып та, шуннан соң төркичә сүз сөйләнсә, монда нинди зарар булсын? Зарар барлыгын исбат итү «Зарар бар» дип дәгъва кылучы өстендә. Исбат итсен, күреп карыйк! Нинди бер шәригатькә туры килгән дәлил китерер икән?

*Шура. – 1915. – № 3. – Б. 92.*

## [ШАЙТАН, СӘДУМ, ХОЗЫР-ИЛЬЯС, ЯҖҮҖ-МӘЭҖҮҖ ТУРЫНДА]

**Малмыж:**

1. Яңа фәннәр, җеннәрнең адәмнәргә тәэсирләре юк, дип исбат итәләр. Шул ук вакытта, Коръән кәрим Әюп пәйгамбәр кыйссасында: «Мине шайтан авырлык һәм каты мәшәкать белән тотты» һәм дә риба хакындагы аятьтә: «Каберләреннән, шайтан буып ташлаган кеше кебек, бик яман сурәттә кубарлар», – дип, җен һәм шайтаннарның тәэсирләре булуны аңлата. Юкса аларның тәэсирләре юклыгы хакында тагын да куәтлерәк нәкъли [Коръән һәм хәдисләрдән булган] дәлилләр бармы?

2. Коръән кәримдә искә алына торган «әсхабел-әйкә» кыйссасындагы Сәдум шәһәренең урыны кайсы җирдә иде. Аның урыны бүген мәгълүмме?

3. Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләрне бүген исәннәр дип сөйләү бик таралган. Шушы сүз дөресме һәм аларның, мәңгелек агачын авыз итүләре сәбәпле, дөньяда мәңге торулары хакындагы хәбәрләрнең дөрес дәлилләре бармы?..

4. «Шура»ның өченче [санында] Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ хакында, аларны руслар дип тә, татарлар дип тә әйтүчеләр бар, диюе ышанырлык сүзме? Чөнки Коръән алар хакында, җирдә бозыклык эшләүчеләр, дип әйтә. Алай булганда, алар вәхши, хайван хөкемендә һәм адәм ите ашаучы мәхлуклар булырга тиешле иде. Шушы сорауларыбызның җаваплары «Шура»да язылсын иде.

*Хиббан Кәүсәров Ахуни.*

**«Шура»:**

1. Бер падишаһ мәшһүр галимнәрне үз янына җыйганнан соң: «Зур бер табакка су салып, үлчәү белән үлчәнсә, соңыннан шул суга үлгәч ун кадак тарта торган бер балык салынса, һич авыраймый, тере балыкның барлыгы белән юк-

лыгы арасында аерма күренми. Моның сәбәбе нинди нәрсә?» – дип сорагач, галимнәр, бер-берсеннән уздырып, хикмәтләр бәян иткәннәр. Фәлсәфәгә чумып, бик күп серләр ачканнар. Сүзгә бер дә катышмый утыручы бер адәм бик күп вакытлар үткәннән соң: «Чынлыкта, бу шулаймы икән?», – дип, тәҗрибә кылып күрергә карар биргән һәм шул мәҗлестә сынап карыйсы килгәнлекне бәян иткән. Үлчәп карасалар, бөтенләй алай түгел, бәлки ун кадак авырлыгындагы тере балык табактагы суга салгач та, ун кадак авырайган. Падишаһ үзе бу эшне галимнәрнең акылларын, зиһеннәрен сынар өчен, юри шулай иткән икән. Шуның кебек, «Яңа фәннәргә күрә, җеннәрнең адәмнәргә тәэсирләре барлыгына һаман дәлил табылмый» диячәк урында «Яңа фәннәр, җеннәрнең адәмнәргә тәэсирләре юк, дип исбат итәләр» рәвешендә бирелгән булмаса, ярар иде. Яңа фәннәр үзләре микроб галәмен исбат итеп торган хәлдә, «Җеннәрнең тәэсире юк» дип ничек дәгъва итсеннәр? Микробларның җен галәменнән икәнлеге хәзер гомуми фикерләр хөкеменә кереп бара. Бу – бер. Икенчедән, Коръән терминологиясендә «шайтан» сүзе рухани галәмгә генә хас түгел. Метафора һәм киная булмыйча, бәлки хакыйкый мәгънәсе белән «шайтан» сүзе рухани һәм матди нәрсәләрнең һәрберсенә әйтелә. Тел галимнәренең остазларыннан булган бер зат: «Шайтан – кешеләрдән, җеннәрдән, хайваннардан булган һәрбер каршы чыгучы тәкәббернең исеме», – дигән. Шулай булгач, искә алынган аятьләрдәге шайтанны рухани нәрсәгә хаслап та яки фәннәргә каршы килүе белән бәхәсләшергә урын булмаса кирәк.

2. Сәдум шәһәренең урыны «Лут күле»нең төньяк тарафында иде, диләр.

3. Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләрне күргәнебез һәм күргән кешеләрне дә күргәнебез юк. Шуның өчен алар хакында хәбәр сөйләргә кулыбыздан килми. «Сахих әл-Бохари»да булган бер хәдистән аларның вафат булганлыклары аңлашыла. Мактаулы эшләр һәм кәрәмәтләр хакындагы китапларга күрә, алар һаман тере булып дөньяда йөриләр. Хәдисне

алда тотучылар, табигый, аларның вафат булганлыкларын сөйлиләр. Хәдис китапларына караганда мактаулы эшләр китапларын алда тотучылар аларның тере икәнлегенә ышаналар.

4. Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ хакында булган «җирдә бозыклык эшләүчеләр» сүзенең кайсы җиреннән «Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ адәм ите ашыйлар» дигән мәгънә аңлашыла? Ул аять Коръән кәримдә бер төркемнең сүзләрен сөйли генә. Алар шул вакытта бозык булганнар. Ләкин «җирдә бозыклык эшләүчеләр»дән «мәңгелеккә шулай булырлар» дигән мәгънә чыкмый. Анда озакка сузылу, дәвамлылык һәм мәңгелеккә дәлил була торган нәрсә юк.

*Шура. – 1915. – № 8. – Б. 253.*

## [КОРЪӘН ҺӘМ ХӘДИСКӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Әгәр дә берәү: «Коръән һәм Рәсүлуллаһның хәдисе белән гамәл кылырга кирәк, шул ике нәрсәне үзебезгә мөмкин кадәр юл күрсәтүче итеп тотарга тырышу тиешле. Арабыздагы ислам кардәшлегенең бетүе безнең Коръән белән хәдисне үзебезгә юлбашчы итеп тотмавыбыздан килгән. Фәлән имам шулай әйткән, төгән мулла шулай әйткән, дип борынгы галимнәрнең кайберәүләренең сүзләрен хәтта аятькә каршы да дәлил итеп тотабыз. Бу эш ислам диненең кушкан юлы түгел. Ислам дине бөтен мөэмин-мөселманны дин карендәше булырга куша һәм дини ихтыяҗларны мөмкин кадәр Коръәннән алырга өнди. Коръән аятьләрен укып, мәгънәсе турында акыл ирешкән кадәр уйларга куша. Теге мәзһәб, бу мәзһәб дип аерылышып, бербереңне кяфер итәргә кушмый. Мин Коръән кәримнән азмы-күпме хөкем аятьләрен беләм икән, шул хөкемнәрне үтим. Үтәгәндә, фәлән имам әйткән өчен, шуңа ияреп үтим, дип ышанмыйм. Бәлки Коръәнгә ияреп үтим, дип ышанам. Әгәр

дә бер нәрсә турында шөбһәләнсәм, әүвәл белгәнем кадәр Коръәннән, хәдистән эзлим. Аятьтән тапсам – аятькә ияреп, хәдистән тапсам – хәдискә ияреп, гамәл кылам. Коръәннән, хәдистән таба алмасам, имам Әгъзам һәм башка галимнәрнәрнең яисә шушы замандагы мәшһүр галимнәрнең сүзләренә ияреп, шуның белән гамәл кылам», – дисә, шул кеше мөэмин буламы? Юкса «Белгәнем кадәр Коръәнхәдискә ияреп, гамәл кылам, башкага иярмим» дигәне өчен кяфер буламы?.. Монда галимнәр [дип] аталганнар «Һәрнәрсәдә имам Әгъзамга иярәм» димәгән өчен: «Бу – галимнәрне кимсетү һәм галимнәрне хурлау була, шул сәбәпле, бу сүзне сөйләгән кеше – үзе кяфер, хатыны талак була», – дип хөкем итәләр. Мөхтәрәм «Шура»да шушы турыда җавап язсагыз икән!..

*Муса Исмәкый.*

**«Шура»:**

Ул галимнәр каршында, имам Әгъзамга иярү мәҗбүри булып, аңа каршы сүз сөйләү һәм, ярамаса, хәтта «Имам Әгъзамга иярәм» димәү галимнәрне кимсетү һәм галимнәрне хурлау булып, шул сәбәпле, Аллаһ сакласын, кяфер булса, ул галимнәр үзләре бу мәсьәләдә имам Әгъзамга иярмиләр була һәм үз хөкемнәре белән хөкем ителүләре тиешле килә. Имам Әгъзам хәзрәттән «Миңа иярегез!» дигән сүзне ишеткәнебез юк, башка кешеләрнең дә, шаять, ишеткәннәре булмас. Әмма имам Әгъзам да һәм башка мөҗтәһидләрнең [үз тырышлыгы белән ислам чыганакларыннан хөкем чыгаручы галимнәрнең] дә «Әгәр хәдис дөрес булса, ул – минем мәзһәбем» һәм дә «Дәлилебезне белмәгән кеше безгә иярмәсен!» дигән сүзләре мәшһүр булып, ышанычлы адәмнәр риваять кылалар. Имам Әгъзамның мондый сылтаулар белән кыйбла әһелләрен кяфер итүдән бик саклануы мәгълүм. Әгәр дә галимнәрегез имам Әгъзамга иярсәләр, менә шушы эшләренә иярсеннәр. Дуслыкны кисү, аз гына сылтаулар белән мөсел-

маннарны кяфер итү – Әбү Хәнифә хәзрәттән түгел, бәлки хәварижләрдән [диннән аерылып чыгучылардан] мирас калган нәрсә. Мәзһәб тарихларын тикшерүчеләргә бу хәл бик мәгълүм. Хатынны талак итмәстән элек, галимнәр өстенә йөкләнә торган эш бик күп. Шул үз эшләрен тикшерсәләр, зарар булмас иде. Коръән һәм хәдисләрдән дәлил эзләүне бүгенгә кадәр мөселманнар арасында булмаган бер яңа сүз [итеп] чыгару кирәк түгел. Бәлки могтәбәр галимнәрдән кайберләре дәлилләгән юлны гына ихтыяр итү була. Хөкемнәр турында галимнәрнең дәлил китерүләре, бер-берсе белән каршылыкка керүләре һәм һәрберсенең дәлилләре хакында тәфсирләр һәм хәдисләргә язылган шәрехләр тулы мәгълүмат бирәләр. Әбү Бәкер ибне әл-Гарәбинең «Әхкям әл-Коръән» һәм дә Шәүкянинең «Нәйл әл-әүтар» исемле әсәрләре бу җөмләдән. Шундый әсәрләрне карап та, шул әсәрләрдә бәян ителгән рәвешле, кайбер галимнәрнең дәлилләре Коръән һәм хәдискә якраклырак, заманага яраклырак табылса һәм шуның өчен дә шул юл ихтыяр ителсә, монда ни зарар булсын? Сәләф галимнәренең берсе яки бер төркеме ихтыяр иткән сүзне чыгарма һәм яңа сүз дип дәгъва кылырга урын юк. Хакыйкать хәлдә, бу мәсьәлә белән иҗтиһад дәгъвасы – икесе бер нәрсә түгел. Иҗтиһад мәсьәләсе тагын да башка. Бу турыда мондый әдәби җыентыкларда шуннан артык сөйләргә мөмкин түгел, сөйләргә күп хәҗәт тә юк. Чөнки бу мәсьәлә күптән хәл ителгән һәм тәмамланган. Ибне әл-Һөмам «Фәтх әл-Кадир»нең күп урынында һәм башка олуг авторлар үзләренең әсәрләрендә һәркемне канәгать итәрлек рәвештә бу мәсьәлә хакында мәгълүмат бирәләр.

*Шура. – 1915. – № 14. – Б. 444.*

## [«ХУҖА»ЛАР ТУРЫНДА]

**Ташкент:**

Безнең Төркестанда булган шәһәрләрнең һәрберсендә Миян, Хуҗа исемле адәмнәр бик күп. Болар үзләрен Рәсүлуллаһ нәселеннән дип дәгъва кылалар, мөридләр җыялар. Халык үзләрен ифрат дәрәҗәдә олылый, сәдаканы бик мул бирәләр, бик сыйлыйлар. Татарлар арасында мондый Миян һәм Хуҗалар булмый, йөрми дә. Безнең төркестанлылар арасында болар ник бик күп була? Рәсүлуллаһ үз тормышын үз кәсебе белән тәэмин иткән һәм сәдака алмаган хәлдә, болар ничек халык өстенә бу кадәр салыналар һәм сәдака җыялар? Шушы хакта «Шура»да җавап язылсын иде.

*Мирйосыф Мирзаһидбаев.*

**«Шура»:**

Бу сорау «Балга ни өчен чебен җыела, куйлар ни өчен тозга киләләр» дип сорау бирүгә охшый. Моның җавабы үзегезнең соравыгыз эчендә мәгълүм. Әгәр дә сорауны «Болар шулхәтле хөрмәтләргә илтифат итмиләр, дөнья малына һич кызыгулары юк, кеше кулыннан хәтта шырпы да алмыйлар, важиб сәдакаларга күз дә салмыйлар, шуның сәбәбе нинди нәрсә» дип сораган булсагыз, «Боларга важиб сәдака алырга ярамый, аларга бирелгән важиб сәдакалар сәдакадан хисапланмый, Рәсүлуллаһ хәзрәт юлында булганлыктан, үз маңгай тирләре белән дөнья көтәләр, бәндәләр кулындагы керле һәм шөбһәле маллар белән пычранмыйлар, бәлки үзләре хәләл кәсеп итәләр һәм шуның белән торалар; боларның дәгъваларын ганимәт [дип] белегез!» дип җавап язган булыр идек.

*Шура. – 1915. – № 15. – Б. 474–475.*

## [«ГАЙНЕЛ-ГЫЙЛЕМ» КИТАБЫ ТУРЫНДА]

**Чапурин:**

«Шура» җыентыгы Шүрәле, дию, албасты, абзар иясе, йорт анасы кебек нәрсәләрне инкяр итү стилендә бер җавап язды (10 нчы сан, 117 нче бит). «Гайнел-гыйлем» китабы укыган вакытыбызда «Аның Коръән укуын фәрештәләр һәм йорт ияләре тыңлыйлар...» хәдисендә остазыбыз «йорт ияләре»ннән максат «өй анасы» икәнлеген аңлаткан иде. «Гайнел-гыйлем» хәдисләре, әлбәттә, ышанычлы булсалар кирәк, шуңа күрә «йорт анасы» кебек нәрсәләрне инкяр итү урынлы булырмы? Бу хакта аңлатма бирелүне үтенәбез.

*Исхак Таҗетдин.*

**«Шура»:**

Ибне Кәсир һәм башкалар сүзенә күрә, «йорт ияләре»ннән максат – өйдә тереклек итүче еланнар һәм, кайсыбер шәрехләр сүзенә күрә, мөселман җеннәр. Аны «өй анасы» дип тәфсир кылу дөрес тәфсир булмаса кирәк. Моннан соң, искә алынган хәдис мәшһүр «Сөнән» яки «Мөснәд» авторлары тарафыннан риваять ителә торган ышанычлы хәдис түгел. Аның хакында «мөнкәр» [инкяр ителгән] диючеләр дә бар. «Гайнел-гыйлем»дә булган хәдисләрне, гомумән, дөрес хәдисләр дип хөкем итү урынлы булмас. Анда «Әбү Хәнифә – өммәт яктырткычы» кебек ялганлыгы мәнди анасына да [һәркемгә дә] мәгълүм хәдисләр бар. Бәлки күп. «Гайнел-гыйлем» китабы «Ихья голүм әд-дин»нән кыскартылган әсәр булганлыктан, аның бар кебек хәдисләре «Сахих»ләрдән, «Сөнән» һәм «Мөснәд»ләрдән түгел, бәлки «Ихья...»дән генә алынган. Шул ук вакытта, «Ихья...» авторы имам Газали хакында «Хәдис фәнендә җәяүле адәмнәрдән иде» диләр. «Гайнел-гыйлем»дә асылсыз хәдисләрнең күп булуының сәбәбе – шул.

*Шура. – 1915. – № 15. – Б. 476.*

## [ШОМЛЫ КӨННӘР ТУРЫНДА]

**Чынгырлау:**

Халыклар һәр йолдызның 9 нчы көнен шомлы көн дип ышаналар һәм шуның өчен 9, 19, 29 нчы көннәрендә эшләр башланмый, сәфәргә чыгылмый, киңәш ителми. Әгәр дә ашыгыч эшләү мәҗбүри булса, бу эшләр 8 нче көндә эшләнә, аңа өлгереп булмаса инде, 10 нчы көнгә кала. Ислам динендә шушы ышануның асылы бармы?..

*Аманбай Баубиков.*

**«Шура»:**

Көннәр, айлар һәм йолдызлар, юлда кеше очрау кебек нәрсәләр белән шомлану ислам динендә юк. Бәлки андый нәрсәләрне бетерер өчен Рәсүлуллаһ күп тырышты. Бу турыда Бохари, Мөслим һәм дә башка имамнар хәдисләр риваять кылалар. Мондый ышанулар килданиләр һәм асуриләрдә бик могтәбәр иде. Шулардан башка кавемнәргә таралды, җәелде. Килданиләр Туран кавемнәре һәм бүгенге төркиләрнең бабалары булганлыктан, андый нәрсәләр – безгә дин тарафыннан түгел, бәлки элекке бабалар тарафыннан мирас калган нәрсәләр.

*Шура. – 1915. – № 16. – Б. 507.*

## [ХУҖА БАҺАВЕТДИН, ШӘЕХЛӘР ТУРЫНДА]

**Форт Александровский:**

1. Хуҗа Баһаветдин хәзрәт бер бүрек тегеп, һәрбер энә чәнчегән вакытта җитмеш мәртәбә: «Ләә иләһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүлүллаһ», – дип әйтә иде. Шул сәбәпле, бүрекне бик озак тегеп, җиде елда тәмамлады һәм шуның белән алты тәмугны сатып алды, диләр. Шушы сүз дөресме? Дөрес булса, инде бөтен халыкка бер генә тәмуг калган буламы? Хуҗа Баһаветдиннең алты тәмуг сатып алырга көче

җитсә, бу кадәр пәйгамбәрләр килеп үттеләр, вәхи белән хөрмәтле булдылар, болар ничек бер генә тәмуг та сатып ала алмадылар, болар Хуҗа Баһаветдин кадәр халыкларны кызганмыйлар идеме?

2. «Шәрхе әүрад» исемле әсәрдән «Иман китерү һәм тәүбә итү максаты белән шәехләрнең кулларын тотучы адәм – монафыйк [икейөзле], чөнки бу эш фарыз, сөннәт, мөстәхәб, нәфел эшләрдән һәм пәйгамбәрләрнең сөннәтләреннән түгел; тәүбә Аллаһка кайту мәгънәсендә булып, монда шәехләрнең кулларын тотуның катышы юк» эчтәлегендә бер гыйбарә күчерелгән. Шушы сүз дөресме?

3. «Вәҗизи» исемле китаптан: «Шәехләрнең рухлары килә, дигән кеше ислам диненнән чыгар», – дип бер гыйбарә күчерелә һәм шуны Фәйрүз Шаһи исемле адәм дә үзенең әсәрендә сөйли. Шул сүзләр дөресме?

4. Бу заманда пирлек [ишанлык] һәм пирнең кулын тотучы[лар] таралды. Бу эшнең асылы бармы, юкмы?..

Бу сорауларыма «Шура»да җавап язылсын иде.

*Мулла Солтанат бине Алҗан.*

**«Шура»:**

Дөньяда китап һәм сүз, мәсләк һәм мәзһәб бик күп. Боларның һәрберсен берәмләп тикшереп бетерү һәм һәрберсе хакында хөкем итү кешеләрнең көчләреннән киләчәк эшләр түгел. Аеруча халыкларның бер-берсенә ияреп сүз сөйләүләре һәм үз акылларын эшләтмәүләре эшләрнең чуалып китүенә сәбәп була. Ислам дөньясындагы имеш-мимеш, «әйтте-әйтелде»гә ияручеләр көннән-көн сазлыкка баталар һәм һәлакәткә якынлашалар. Шул эштән боларның котылуларына, кергән юлларыннан кире борылып чыгуларына өмет бик аз. Хаклыкка иярүне максат итүчеләр өчен бердәнбер дөрес юл – Рәсүлуллаһка иярү, бәндәләрнең карашларына, хосусый фикерләренә шәригать төсе бирмәү. Рәсүлуллаһ һәм дә сәхабәләрнең юлларын белергә теләүче кеше өчен мәшһүр

«Сахих»ләр, «Сөнән» һәм «Мөснәд»ләр җитә. Бу әсәрләрнең күбесе хәзер басылып таралды, гыйлем ияләренең кулларында файдаланыла һәм бик күп урыннарда дәрес итеп укыла. Шул әсәрләрдән файда алырга көчләре җитмәгән кешеләргә белүчеләрдән сорарга һәм шуларның сүзләре белән гамәл кылырга мөмкин. Күп булмасалар да, Коръән-хәдис гыйлемнәре һәм дә сәләф хәлләре белән таныш галимнәр дөньяның һәр почмагында бар, моннан соң да, шаять, булырлар. Ибне Маҗә тарафыннан: «Минем өммәтемнән бер төркем һаман хаклыкта дәвам итәрләр, каршы чыгучыларының зарарлары тәэсир итмәс» эчтәлегендә риваять ителгән хәдисеннән максат та – Коръән һәм хәдис әһелләре булу өметле.

Пирлек һәм пирнең кулын тоту дигән сүздән максат нинди нәрсә икәнлеген ачык аңламадык. Әгәр дә максат тәсаувыф [суфичылык] була торган булса, бу вакытта «Соралган кеше сораучыдан артыгын белмәс» дияргә мәҗбүрбез. Тәсаувыф хакмы, ялганмы соравына җавап бирер өчен шуның нинди кагыйдә һәм кануннардан гыйбарәт икәнлеген белергә кирәк. Ул эш безгә насыйп булмады. Аңа нисбәтле булган адәмнәр хәлләреннән дә берәр нәрсә аңлау мөмкин түгел. Чөнки тәсаувыфка нисбәтле халык арасында бик яхшы кешеләр булган кебек, бик усаллар булганлыгы да мәгълүм. Тәсаувыф хакында язылган китаплардан без күргәннәре фәнни рәвештә язылмаганлыктан, аның хакыйкатен белергә ярдәм бирә алмыйлар, алардан карап бер нәрсә аңлау читен. Замандашларыбыздан философ исеме белән мәшһүр бер галим уналты ел гомер сарыф итеп, тәсаувыф хакында бер китап язганлыгын игълан иткән иде, ләкин басылу-басылмавын белә алмадык. Европа һәм ислам галимнәре белән телләренә таныш булган бу затның әсәре, әлбәттә, яхшы булыр. Хәзер бөтен сүзебез «Коръән һәм хәдискә яраклы булган нәрсәләрнең һәрберсе хак һәм аларга каршы булганнар ялган» диюдән гыйбарәт. Аңа тәсаувыф та, пирләр кулы, башкалар да керерләр. Шуннан артык сүзебез юк.

Җиде ел вакытында бүрек тегеп, алты тәмугны сатып алу кыйссасы гади халыкны аулар өчен ясалган асылсыз кыйссалардан булып, аның кебек нәрсәләр җавап бирелү һәм кире кагылудан түбән. Мондый хикәяләрне кемнәр чыгарганлыгы һәм нинди максатлар белән халык арасына таратылуы хакында «Кәрәмәт вә истимдад» исемле әсәрдә беркадәр язылды. Шаять, искә алынган китап нәшер ителсә кирәк. [Кызганычка каршы, Р. Фәхретдиннең бу китабы нәшер ителмәде].

*Шура. – 1915. – № 19. – Б. 604–605.*

## [ӘҮЛИЯЛӘР КАБЕРЛӘРЕ ТУРЫНДА]

**Ташкент:**

«Төркестан Чине»ндә Турфан шәһәренә якын бер җирдә Әсхабел-кәһеф исеме белән телгә алына торган әүлияләр каберләре бар. Зиярәт кылыр өчен бу җиргә бик күп халык килә һәм «Хаҗ кылырга көче җитмәгән кеше Әсхабел-кәһефне зиярәт кылса, хаҗ савабын табар» дип, монда баруны һәм зиярәт кылуны мөселманнар бик зур гыйбадәтләрдән саныйлар. Әсхабел-кәһеф хакында бик гаҗәеп кыйссалар һәм маҗаралар сөйләнә, гадәттән тыш эшләре һәм кәрәмәтләре риваять кылына. Болар нинди әүлияләр, кемнәр икәнлекләре мәгълүмме? Шунда баручыларның хаҗ савабын табулары хакында берәр шәригать дәлиле бармы?

*Мирйосыф Мирзаһидбаев.*

**«Шура»:**

Соңгы заманда һәр мәмләкәттә булган мөселманнар каберләр белән бәхетсезлеккә төштеләр. Моннан исә Урал һәм Идел буйларындагы мөселманнар гына беркадәр саф калган булулары ихтимал. Гәрчә боларда «Хуҗалар таулары» исемле зиярәт урыннары булса да, бу урыннарга гыйлем

ияләре йөрмиләр һәм зиярәтләр дин исеменнән кылынмый. «Хуҗалар таулары»на баручылар хаҗ кылган савапны табарлар, кебек сүзләр сөйләнгәне ишетелми. Моның сәбәбе – безнең үз тикшерүебезгә күрә, бу тарафтагы элекке мөдәррисләр һәм галимнәрнең Дагстанга барып, Кадакый янында тәрбияләнүләре иде. Кадакый исә каберләрдән ярдәм сораучыларны сөйми торган шәех Мокбили Йәмәни шәкертләреннән. Кадакый шәкертләре бу мәмләкәттә бик күп асылсыз гакыйдәләрне бетерергә хезмәт иткәнлекләре мәгълүм. Турфан безгә ерак. Әсхабел-кәһеф исемле әүлияләр хакында элекке галимнәр әсәрләрендә бернәрсә дә укыганыбыз юк. Халыкны кабергә җыяр өчен, кабер иясенең хәлен белергә кирәк түгел. Кабер белән кәсеп итүчеләр берәр яраклы урында бер кабер табалар да (булмаса, үзләре ясыйлар), биналар салалар. Кыйммәтле паласлар җәеп, гуд агачлары һәм төрле хуш исле үләннәр яндыралар да, шул кабер иясенең әүлиялеген игълан итәләр. Шунда килү сәбәпле бер сукырның күзе ачыла, бер хатын аяклы була, бала тапмый торган бер хатын бала таба, берсе бәладән котыла, берсе шатлыкка очрый. Кабере табылганнан яки ясалганнан соң, боларны эшләү җиңел. Зиярәт ысулын төзүчеләр үзләре зур чалмалар киеп, кабердә дәрвиш һәм шәех булып утыралар, нәзер һәм сәдакалар су урынына ага. Болар өчен Әсхабел-кәһеф кабере ясау авыр түгел. Әгәр дә теләсәләр, Адәм пәйгамбәр һәм Нух пәйгамбәрләрнең каберләрен дә ясарлар, килүчеләргә хаҗ савабыннан артык саваплар да вәгъдә итәрләр иде. Безнең мөфти хәзрәтебез дә үз гомерендә «Сынташ зыяраты» исемле бер әүлия кабере ясап киткән иде. Ләкин эш башында үзе тормау сәбәпле, таралу таба алмады. Әгәр дә Хуҗа Әхмәт Ясәви яки Хуҗа Баһаветдин каберләрендә торучы дәрвишләрдән берәр кеше килсә, «Сынташ зыяраты»н да яхшы гына тәртипкә салыр һәм бер-ике буынга җитәрлек дәүләт хасил итәр иде. Ул тирәдә әүлияләр каберләре күп түгел, әмма халык бик күп. Бары алдарга оста адәм генә кирәк.

Хакыйкый гыйлем таралмый торып, ислам дөньясыннан кабер бәласе күтәрелмәскә охшый. Дөрес, ислам шәригатендә мәетләрне зиярәт кылу кагыйдәсе бар. Ләкин ул кагыйдә белән бу әүлияләр каберләрен зиярәт кылу арасында мөнәсәбәт юк. Алар бер-берсенә башка. Бу мәсьәләләрне без башка урында җентекләп язганлыктан, бу җирдә шушы кадәрле белән канәгатьләндек.

*Шура. – 1915. – № 19. – Б. 605.*

## [ТӘҮРАТ, ХАТАЛЫ ЭШЛӘР ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Кайбер гакыйдә китапларында Тәүрат шәрифнең иңүе күктән иңгән башка китапларның иңүләре кебек булмый, бәлки язылган тактада булганын риваять итәләр. Шул ук вакытта, Коръән кәримдә ул хакта бер ишарә дә күренми. Чыннан да, дөрес булган тәкъдирдә, аның тактасы җир галәменнән булган бер тактамы? Яки башка берәр галәмнәнме? Аның язучысы кемнәр? Фәрештәләрме?.. Без бит, фән карашы ноктасыннан, фәрештәләрне бер рухани куәт дип кенә йөртәбез. Аларның шуның кебек матди эшләр белән шөгыльләнүе буламы? Дөрес, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә – һәрнәрсәгә көче җитүче, Ихтыярлы. Ләкин Аллаһ эшендә аның кебек эшләрнең очраганы бармы? Булса, ник башка изге китаплар да шулай иңмәгән?.. Шушы мәсьәлә халык өчен дә игътикади [ышануга нигезләнгән] мәсьәлә булганлыктан, «Шура» аркылы хакыйкатьне белдерүегезне үтенәбез.

*Мөгаллим Нигъмәтулла Күзәмбаев.*

**«Шура»:**

Муса пәйгамбәр хакында Коръән кәрим «Мусага Тәүрат такталарында һәрнәрсәне яздык, вәгазьне, һәрнәрсә бәян иттек, аны куәт белән ал һәм кавемеңә дә Тәүрат белән гамәл

кылырга боер, Тәүратның күркәмрәк хөкемнәрен алсыннар», «Һәм ачуыннан кулындагы Тәүрат такталарын ташлады һәм кардәше Һарунның сакалыннан тотып үзенә тартты», «Мусаның ачуы басылгач, әүвәлдә атып ташлаган Тәүрат такталарын кулына алды. Ул Тәүратта Аллаһтан курыккан кешеләр өчен туры юлга керү тәртипләре һәм Аллаһның рәхмәте язылган иде» рәвешендә хәбәрләр сөйли һәм Муса пәйгамбәр шул такталарда булган фәрманнарны кавеменә ирештерү белән йөкләнгәнлеген бәян итә. Моның мәгънәсе «такталарда язылган нәрсә – Тәүрат иде» яки «Тәүрат – такталар иде» дигән сүз була. Инде «Тәүрат такталарда язылган булу хакында Коръәндә ишарә юк» дип әйтү ничек дөрес була? Коръәндә ишарә генә түгел, бәлки ачык гыйбарә бар. Бу мәсьәләнең игътикади булган ягы шушы гына. Әмма аны кем язган? Ул такталар үзе нинди нәрсә иде? Фәрештәләр нинди куәттән гыйбарәт? Рухани куәттән гыйбарәт булсалар, матди эшләр белән шөгыльләнүләре мөмкин буламы? Бер китап бер рәвеш белән иңгәннән соң, башкалары ни өчен шул рәвештә иңмәгән? Бу мәсьәләләрнең һичберсе игътикади түгел һәм дә боларны белү белән йөкләү юк. Безнең үз мәсләгебезгә күрә, мондый нәрсәләр – бүгенге адәм балаларының зиһеннәре ирешә алмый [торган эшләр] һәм, [фән] ияләренең тануларына күрә, бүгенге фән киртәсенең тышындагы эшләр. Үзләре тапкан электрның нинди нәрсә икәнлеген белүдән гаҗиз булган күп фәннәр белүче галимнәр, үзләренең кабыргаларында йөргән җаннарын һәм аның идарә итү рәвешләрен белә алмый хәйран калганнан соң, фараз һәм теорияләр бәян итәргә мәҗбүр булган бүгенге галимнәрнең Коръән сөйли торган фәрештәнең нинди куәтләрдән һәм эшләре дә нинди нәрсәләрдән гыйбарәт икәнлеген белү хакында дәгъвалары булмаса кирәк.

Шушындый очы юк бәхәсләрне, мәҗбүрилеге юк, йөкләнүе юк, белергә мөмкинлек юк булган мәсьәләләрне тикшерү турында халкыбызның ач күзле булуларының

сәбәбен белә алмыйбыз. Монда язылган сүзләрне дә өсте-өстенә килгән сорауларга мәҗбүр булып язабыз.

Мөселман дөньясы ике төрле бик зур хатага төшеп, авызы пешкән иде. Шуның өчен моннан соң инде бик сакланыр, алдын-артын фикерләп йөрер, дип уйлыйлар иде. Ләкин бу өметләрнең бушка чыкканлыгы һәм әүвәлге хаталарга өченче мәртәбә төшәргә әзерләнгәнлеге күренә.

Безнең бүген бик күп адәмнәр Газали, Ибне Хәзем, Ибне Рөшед, Ибне Тәймия, Әбү әл-Галя әл-Мәгарри, Әбү Бәкер әр-Рази сүзләренә әһәмият бирмәгән, хәтта бу адәмнәрнең кемнәр икәнлекләрен дә яхшылап белмәгән хәлдә, Толстой, Гёте, Байрон, Данте һәм Шиллер кебек исемнәр яннарында тезләнәләр. Аларны хатасыз дип саныйлар, бераз гына каләм тотканнары да шул исемнәрдән берәрсен кыстырып китәргә тырышалар. Ислам дөньясында бервакыт яһүд муллаларының исемнәре шушы дәрәҗәдә йөрде, боларның сүзләре хәтта тәфсирләргә кадәр керде һәм шушы юл белән яһүд хорафаты ислам милке булып калды. Ислам дөньясының беренче хатасы шушы иде.

Грек фәлсәфәсе тәрҗемә ителгәннән соң, мөселманнар каршында иң олуг адәм Аристотель булган иде. Кәлям әһелләре Аристотель мәзһәбенә яраклаштырып гакыйдә китапларын төзеделәр, тәфсир язучылар Коръән аятьләрен Аристотель мәсләгенә яраклаштырдылар. Боларның бу хәрәкәтләреннән, Коръән Аристотель мәсләген раслар өчен иңгән һәм Рәсүлуллаһ та Аристотель сүзләренә чакырыр өчен килгән, дип белергә мөмкин. Ислам дөньясының беренче хатасы бу булды. Мәзһәб әһелләренең Коръән һәм хәдисне үз имамнарына яраклаштырулары да һәм үз сүзләренә каршы булган аять, хәдисне ялгыш аңлатулары да – шушы эшкә якын бер хәл.

Безенең заманыбызда мөселман дөньясы өченче һәм дә бик зур бер хатага төшәргә әзерләнә. Бу исә – Коръән һәм хәдис хәбәрләрен бүгенге Европа галимнәренең сүзләре белән яраклаштырырга әзерләнү.

Коръәндә фәрештәләрдән хәбәр бирелә. Алар хакында «коллар һәм хөрмәтлеләр», «Аллаһка һич каршы килмиләр», «канатлылар» кебек нәрсәләр сөйләнә, әмма аларның сыйфатлары һәм хезмәтләрен билгеләү хакында дәшми торыла. Безнең өчен Коръән хәбәр биргән кадәрлесен белү ни өчен җитми дә, алар рухани куәттән гыйбарәтме яки җисемлеме, матди эшләрне эшли алалармы, юкмы, кебек булган нәрсәләрне тикшерергә нинди мәҗбүрлек була? Әгәр дә белү зарур булса, Коръән кәрим ул хакта хәбәр бирми калдырмас иде.

Адәм баласының белгән һәм белә торган нәрсәсе тамчы булса, белмәгәне – диңгез. «Сезгә белемнән өлеш бик аз бирелде» [Коръән, 17:85].

Ислам дөньясын өченче мәртәбә хата эшкә төшерергә әзерләнгән һәм билләрен буып, җиңнәрен сызганган кешеләргә әйтәчәк бер сүзебез бар:

Бертөрле гыйлем дөрес булудан аның белән шөгыльләнүче белгеч галимнең һәр сүзе дөрес һәм хакыйкать булу мәҗбүри булмый. Бу сүз бүген Европада булган рух галимнәре хакында гына түгел, бәлки тарих, тел галимнәрендә, хәтта фикыһ [ислам хокукы] галимендә дә шулай. Фикыһ галименең ялгышуы, акыл һәм шәригатькә сыймый торган сүз сөйләве мөмкин, әмма, аңа карап, фикыһ гыйлеме ялгыш булу һәм, киресенчә, ягъни фикыһ гыйлеме дөрес һәм хак бер гыйлем булудан һәрбер фикыһ галиме сүзе дөрес булу мәҗбүри түгел. Европада бер галим бер сүзне фәнгә нигезләп сөйләсә, акылга сыя торган дәлилләре [белән] берлектә булса, әлбәттә, аңа игътибар итәргә һәм дәлилләрен инкяр итәргә мөмкинлек булмаган хәлдә, нәтиҗәне инкяр итәргә ярамый. Бу эш кирелек һәм фанатизм була. Әмма бертөрле фәннәр галиме фараз юлы белән сөйләгән булса, моңа ышанмау, әһәмият бирмәү турында һәркем ихтыярлы. Бәлки «Ул бик галим һәм төрле фәннәр белүче адәм, әлбәттә, белми сөйләми торгандыр» дип әйтү һәм шуңа ышану – хурланган тәкълид [галимнәрнең сүзләренә сукырларча иярү] һәм торгынлыкның үзе.

Европада олуг галимнәрнең берсе пәйгамбәр тормыш юлы китапларында булган кайбер сүзләргә нигезләнеп, Рәсүлуллаһ хакында: «Ул бума зәхмәтле кеше булган», – дип яңа бер сүз сөйләгән һәм, гүя, шушы сүзе белән аның пәйгамбәрлеген инкяр итәргә юл әзерләмәкче булган иде. «Төрле фәннәр белүче кеше сөйли», – дип, бу сүзне фәнгә тоташтыру ярамаганлыгы мәгълүм. Докторлар үзләре кешеләр хәбәренә нигезләнеп кенә хасталыкны таный, билгели алмыйлар, дәва бирмиләр, хәтта ун профессор бергә җыелып та, кайбер чирләрне аера белмиләр һәм кайбер вакыт бердәмлек белән биргән карарларының ялгышлыгы килеп чыга. Инде бер-ике сүзгә карап та, мең ел электәге бер кешенең хасталыгы һәм хасталыгы нинди нәрсәдән гыйбарәт икәнлеген билгеләү ничек мөмкин була? Бу нинди фән булсын? Шушындый бер эш башка бер кеше хакында һәм башка бер адәм тарафыннан сөйләнгән булса, бу олуг адәм шушы кеше турында «дурак» дигән булыр иде.

*Шура. – 1916. – № 1. – Б. 29–30.*

## [ҖӘННӘТЛЕ ДИП ШӘҺАДӘТ БИРҮ]

**Вязовой:**

Хуҗа Баһаветдин хәзрәт үзенең мөридләреннән җитмеш кеше хакында оҗмах белән шәһадәт бирде, диләр. Без бер мәҗлестә шушы хакта бераз шөбһә белдергән идек һәм: «Рәсүлуллаһтан башка кешеләрнең җәннәт белән сөенеч бирергә хаклары бар микән?» – дигән идек. Мәҗлестә булган мөридләр һәм кайбер муллалар: «Син – кяфер, динсез», – дип үземне шелтәләделәр. Чыннан да, Хуҗаның шулай шәһадәт бирүе дөресме? Дөрес булса, анда шундый хак бармы? Булса, шөбһәләнүем сәбәпле инде кяфер һәм имансыз булдыммы? Бу хакта «Шура»да җавап язылсын иде.

*Хисаметдин Садретдин.*

**«Шура»:**

Сезнең урында Шәгъби булган булса, «Син – кяфер, син – динсез» дигәннәреннән соң, «Ялгыш әйттем, Хуҗа Баһаветдин җиде йөз кешене оҗмахлы итте, оҗмахның ишеген ачып, һәрберсен күздән кертеп җибәрде» дип ант иткән булыр иде.

Бу турыда сезгә бирә торган җавабыбыз – бу: Шәригать төзүче [Аллаһ] тарафыннан хәбәр булмаган вакытта, пәйгамбәрләрдән башкаларны билгеләү белән «Фәлән кеше (яки бу кеше) җәннәттә яки тәмугта» дип шәһадәт бирергә ислам шәригатенең мөмкинлеге юк. Чөнки бу Аллаһ Тәгаләдән башкага һәм дә Аллаһ Тәгалә вәхи [пәйгамбәрләргә хәбәр итү] белән белдермәгәндә, мәгълүм була торган эш түгел. Кешеләрнең күңелләрендә булган нәрсәләрне белергә юл юк. Рәсүлуллаһ тарафыннан җәннәт белән сөенеч бирелгән сәхабәләр барлыгын ышанычлы хәдис галимнәренең кайберләре риваять итәләр, «Көтебе ситтә»нең дә кайберләрендә бар. Ләкин бу риваятьләр уй мәртәбәсеннән үтмиләр. Шуның өчен сөендерелгән ун кеше һәм сөенеч бирелгән башка сәхабәләрнең (хатыннар да шул җөмләдә) җәннәттә булуларын, шул хәдисләргә күрә, уйларга һәм өметләнергә мөмкин. Әмма шәһадәт бирү һәм ышану дәрәҗәсенә җитмәскә тиешле. Сәламәтлек шунда. Бу турыда кәлям әһелләренең «Җәннәтле дип шәһадәт бирәбез...» дигән сүзләре – арттыру. Гомумән, мөэминнәр хакында, кирәк хосусый дәлил булсын, кирәк булмасын, җәннәттә булуларын уйлау һәм өмет итүне сәләф галимнәре дөрес күрәләр. Әмма вәхи белән хөрмәтләнмәгән кешеләрнең берәүгә җәннәт белән шәһадәт бирүләре – үлчәүсез сөйләү һәм шәригать белән тыела торган хәрам эш. Хуҗа Баһаветдин андый бер эшне эшләмәгән булса кирәк. Шәехләр һәм ишаннар хакында булган хәбәрләр бик арттырулы һәм күбесе ялган була.

*Шура. – 1916. – № 7. – Б. 180–181.*

## [МӘЕТЛӘРГӘ КОРЪӘН УКЫТУ ТУРЫНДА]

**Петропавел:**

1. Кайбер урыннарда әрвахларны шатландыру нияте белән мәет янында яки мәет чыккан йортта «голяма» исемендәге төркемне җыеп, тулысынча Коръән укыту гадәте бар. Шушы эш шәригать каршында мәҗбүри, һич булмаса, сөннәт гамәлләрдәнме?

2. Каберләргә баргач, Коръән укып, шуның савабын багышлау тиешлеме яки гөнаһларны кичерү белән дога кылу яхшыракмы?

3. Рәсүлуллаһ өчен Коръән укып, шуның савабын багышлау артыкмы яки салават укумы? Шушы өч сорауның җавабы «Шура»да язылсын иде.

**«Шура»:**

Мондый мәсьәләләргә җавап бирерлек галимнәр һәр җирдә булган кебек, Петропавел шәһәрендә дә бар. Шулардан сораган булсагыз, яхшырак җаваплар ишетергә яраклы булыр идегез. Безнең җавабыбыз һичбер кеше каршында яраклы булмас. Үз насыйбыбыз да бары сүз ишетү, гаепле саналу гына булыр. Шулай булгач, бу сорау һәм җавап – буш һәм файдасыз нәрсәләр, бәлки бөтенләй зарарлы эш булып калыр. Инде ничек булса да булыр, безнең бу сораугa каршы бирә торган җавабыбыз менә бу:

Бәндәләрнең гамәлләре гыйбадәт [булып] саналу һәм дә савапка лаеклы булу өчен мондый нәрсәләр шарт: 1. Шул гамәл хакында шәригать ирештерүче [пәйгамбәр] тарафыннан хосусый яки гомуми рәвештә әмер булу. 2. Шул гамәл вакытында ихлас булу. 3. Шул эш Рәсүлуллаһ һәм сәләфләрнең гамәлләренә туры килү һәм охшау.

Бу өч шарттан берсе генә табылмаса да, ул нәрсә гыйбадәт исемен алмас һәм савапка лаек булмас.

Ихласлык исә Аллаһ ризалыгын һәм савабын, әмеренә буйсынуны ният итүдән гыйбарәт булып, берәр төрле дөньяви мәнфәгать катышса, ихласлык ялган була һәм гыйбадәтлектән чыга. Тик фарыз гамәлләрдә «Барыбер минем ихласлыгым юк, шуның өчен мин аны үтәмим» дияргә мөмкин түгел. Кушылган нәрсәгә буйсыну – бәндәнең бурычы.

Мәетләр өсләрендә тулысынча Коръән укылып, сәдакалар өләшү гадәте Рәсүлуллаһ заманында юк иде, сәхабәләр һәм сәләфләр арасында булганлыгы да мәгълүм түгел. Рәсүлуллаһ мәетләрне зиярәт кыла, аяк өстендә булган хәлдә, сәлам бирә һәм гөнаһларын кичерү белән дога кыла иде. Рәсүлуллаһның шуннан башка рәвеш белән зиярәт кылуы хакында бернәрсә дә күргәнебез юк. Рәсүлуллаһның шул эше өммәткә мирас булып калды, сәләфләр дә шулай гамәл кылдылар. Мәетләр өсләрендә Коръән укылу, тәһлил [«Лә иләһә илләллааһ» сүзләре] һәм тәкбирләр [«Аллаһү әкбәр» сүзләре] әйтелү, өчесе, җидесе, кырыгы һәм елы исеме белән кунак мәҗлесләре ясалу, кабер сәдакасы (гүр сәдакасы) исеме белән хайваннар бирелү, каберләрдә [зиратларда] сәдакалар өләшү кебек эшләрнең кемнәр тарафларыннан һәм нинди ниятләр белән уйлап чыгарылганлыкларын белмәсәк тә, гасры сәгадәттә [сәхабәләр заманында] булмаганлыкларын безнең белән бергә һәрбер гыйлем иясе белә.

«Садака бирү, Коръән укып, савабын багышлауда ни зарар бар?» – дип, гыйбадәт эшләрен игътибарсыз һәм уйлаусыз сурәттә йөртү ярамый. Коръән уку һәм сәдака бирүнең үзләрендә бер зарар да юк, ихласлык белән булса, бәлки файда бар. Зарар исә, гомуми булган гыйбадәтләрне хосусый төсләргә кертүдә (Рәсүлуллаһ һәм сәхабәләрнең гамәлләренә яраклы итмәүдә).

Иртәнге чәй белән төшке сәгать 11 уртасында мәчеткә җыелып, нәфел яки каза намазы уку гадәтен чыгаручылар булса, «Намаз уку, мәчеткә баруда ни зарар бар?» дип, гыйлем әһелләре тавыш чыгармый тик торырлар идеме? Әбү Талиб әл-Мәкки, Газали кебек суфилар «Рәгаиб» һәм «Бәраәт» исем-

ле намазлар уйлап чыгарганнан соң, хәдис галимнәре «Намаз укуда ни зарар бар?» дип тормадылар, бәлки бөтен көчләре белән шушы гадәтне инкяр иттеләр һәм бетерергә тырыштылар, хәтта «Бу гадәтне тарату – ислам диненә җинаять кылу» икәнлеген дәгъва кылучылар да булды. Рәсүлуллаһның намаз укыган урынында халыкның намаз укуларын белгәннән соң, хәзрәте Гомәр «Намаз укуда ни зарар бар?» дип тормады, бәлки шул эштән өммәтне тыйды һәм: «Үткән өммәтләр шушындый нәрсәләр сәбәпле һәлак булдылар, фарыз намазның вакыты җитсә, Рәсүлуллаһ укыган урын булуын игътибарга алмыйча, укыгыз, әмма, Рәсүлуллаһ укыган урын булу җәһәтеннән, нәфел намазлары укып, бәрәкәт алган булып, чуалып йөрмәгез!» – дип шелтәләде.

Хакыйкать хәлдә, үткәндәге диннәрнең бозылулары, үзгәрүләре «Гыйбадәт кылуда ни зарар бар?» рәвешендәге кагыйдәгә таянып, пәйгамбәрләр тарафыннан өйрәтелмәгән гамәлләр, гыйбадәтләр уйлап чыгару яки өйрәтелгән кадәрдән арттыру һәм киметү сәбәпле булган иде.

Рәсүлуллаһтан ачык булмаган гакыйдәләр, гамәл һәм гыйбадәтләрнең һәрберсе (азы, күбе) – бидгать һәм һәр бидгать – адашу. Кайбер китапларда «яхшы бидгать» дигән сүзләр булганга карап, «Бидгатьнең яхшысы да бар икән» дип шөбһәләнергә урын юк. Ул сүзне башлап сөйләүче никадәр зур галим һәм ислам динендә хөрмәте югары булса да, сүзе ялган һәм мәгънәсез.

Рәсүлуллаһ «Һәр бидгать – адашу» дип торса, аңа каршы «Юк, алай түгел, бәлки кайбер бидгатьләрнең яхшы булулары да мөмкин» дияргә мөҗтәһиднең [үз тырышлыгы белән ислам чыганакларыннан хөкем чыгаручы галимнең] дә хакы юк, мөкаллиднең [дин галимнәренең сүзләренә сукырларча иярүченең] дә. Әгәр дә берәү һаман киреләнсә һәм һәрбер бидгатьнең адашу булуына ышанмаса, бу мәсьәләдә аның дошманы «Һәр бидгать – адашу» диюче Рәсүлуллаһ булачак.

Һәркем үзе белгән кадәр Коръән укып, Рәсүлуллаһка яки мәетләргә багышлый икән (ихлас булу шарты белән) – зарар

юк. Мөселманнар арасында «Фатиха» һәм «Ихлас» сүрәләрен белмәгән кеше булмас. Ысул җәдидә мәктәпләрендә укучылардан күпләр бу сүрәләрнең мәгънәләрен дә беләләр. Акча алу һәм сыйлану яки нинди дә булса дөньяви бер бүләкләр күрү ниятләре катышудан иминлек булмаган рәвешләр белән җыелышып, Коръән укуга караганда да бер кешенең ихласлык белән Фатиха» һәм «Куль һүвәллаһ» сүрәләрен укып багышлавы бик күп мәртәбә зарарсызрак булса кирәк. Аллаһ дөресен белүчерәк.

*Шура. – 1916. – № 9. – Б. 228–230.*

## [ЛОТЕРЕЯ, ФИДИЯ, ДИН ИРЕШМӘГӘН КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА]

**Бакчакүл:**

Түбәндәге сорауларыбызга «Шура»да җавап язылсын иде:

1. Лотерея шәригать каршында дөресме яки түгелме?
2. Калган намаз өчен «дәвер» [акча бәрабәренә мәрхүмнең гөнаһларын кемнеңдер үз өстенә алуы] юлы белән булса да, фидия [мәрхүмнең үтәлмәгән фарыз гыйбадәтләре өчен бирелгән сәдака] бирергә тиешлеме?
3. Рәсүлуллаһның дине ирешмәгән кешеләр, динле булмаулары сәбәпле, Аллаһ каршында сораулы булырлармы?
4. Зөлкарнәен тарафыннан салынган Сәд дөньяның кайсы җирендә, сәяхәтчеләр тапмадылармы?

*Имам Габидулла бине Габдрахман Ишбәков,*
*«Каен» өязе.*

**«Шура»:**

1. «Маидә» сүрәсендә булган 92 нче аять хөкеме белән мөселманнар отыш мөгамәләсеннән тыелалар. Лотерея да отыш булса, ул да шунда керә.

2. Бу турыда Коръән һәм хәдистә бернәрсә дә юк. Ислам шәригатен кимсетүгә сәбәп булганлыктан, «дәвер» дөрес бер гамәл булмаса кирәк. Сәләф заманында андый нәрсәләр булмаганлыгы мәгълүм.

3. Рәсүлуллаһ хәбәре җитешмәгән кешеләрнең мәсьәләләре бездә барлыкка килгәне юк. Ул хакта сезнең беләң бездән сораучы булмас. Белми торсак та, бер зарар да күрмәбез.

4. Сәд хәбәрен белмибез.

*Шура. – 1916. – № 10. – Б. 254.*

## [КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Оҗмахка кергән кешеләрнең тәмугта газапланучы якыннары, хәтта аталары, аналары, хатыннары, ирләре, уллары, кызлары булырга мөмкин. Адәм балалары шушы хәлгә ничек чыдыйлар? Шундый якыннар өчен кайгырмау кешелеклелек түгел. Кайгырсалар, оҗмахта кайгы һәм хәсрәт юк, дигән сүзнең дөрес булмавы тиешле.

*Хөсәен Тимербулатов.*

**«Шура»:**

Дөньяда булган адәм балаларының йөздән берсе рәхәттә булса, туксан тугызы газап эчендә яши. Халык хәлен тикшереп караучыларга бу хәл мәгълүм. Шушы рәхәтлектә торучылар газап астында изелүче үз туганнары өчен кайгырмасалар, хәтта бер-берсенең бәхетенә түзә алмасалар, бөтен эшләре бер-берсенең итен ашау, канын эчү булса, бер-берсе өстеннән донослар ясап йөрсәләр, ул халыкта нинди шәфкать һәм мәрхәмәт булсын?! Ашарга икмәге булмаса – адәм баласы байларга дошман була, аз гына бөтенәйсә [баеса] – ярлыларга дошманлаша. Мондый табигатьтә булган мәхлукларга

ни ата һәм ни бала, ни хатын һәм ни ир! Үз максатлары булса, бөтен дөньяны җир йотсын!.. Үз нәфесеннән башкалар өчен кайгырмау кадәр кешелеклелек булмас. Адәм баласы кадәр усал, адәм баласы кадәр әхлаксыз һәм үз җенесенә мәрхәмәтсез хайван яратылганлыгы мәгълүм түгел. Аталары, балалары җәһәннәмдә газапланган вакытта, боларның оҗмахта кәеф-сафа корып йөрүләре гаҗәп түгел, бәлки берберсе өстеннән донос ясап, оҗмахтан сөрдерергә һәм тәмугка салдырырга тырышып йөрмәүләре гаҗәп. Моны инде белмибез. Бәлки, максатлары булса, йөрерләр дә. Адәм баласыннан һәр кабәхәт эшне, һәр бозыклыкны көтәргә юл бар. Инде ул – бик сыналган бер хайван!..

*Шура. – 1916. – № 10. – Б. 254.*

## [ФИРГАВЕН ИМАНЫ ТУРЫНДА]

**Намәгълүм:**

Фиргавеннең иман китергәнлеге Коръәндә искә алына («Юныс» сүрәсе, 100 нче аять). Аның иманы кабул ителгәнме, юкмы? Хөрмәтле галимнәр шушы мәсьәләне тикшерсеннәр иде.

*Әбү Шәхмә Бокаев.*

**«Шура»:**

Дөрес, мәсьәлә бик мөһим. Ни кадәр эшләребез шуңа тукталып тора! Сузылып һәм иснәп ятучы, сакал һәм мыеклары белән уйнап утырудан башка эш тапмаучы хөрмәтле галимнәр шушы мәсьәләне чынлап тикшерсәләр, турыдантуры үз өсләренә төшкән вазыйфаларын үтәгән булырлар иде.

*Шура. – 1916. – № 11. – Б. 277.*

## [НУХ ПӘЙГАМБӘР ТУРЫНДА]

**Хәсәнколый (Каспий аръягы өлкәсенән):**

Түбәндәге сорауларыбызга «Шура»да җавап язылуны үтенәбез: Нух пәйгамбәр заманында Туфан бөтен дөньяны каплап алды һәм хәзерге халыклар Нух пәйгамбәрнең Хам, Сам, Яфәс исемле улларыннан гына таралды, шуның өчен Нух галәйһиссәлам икенче ата булды, диләр. Болар арасында хатыннар булмаганнан соң, бу халыклар ничек болай үрчеделәр? Җир йөзендәге хайваннар ни рәвешле барлыкка килделәр? Бу мәсьәлә хакында бүгенгә кадәр җавап бирелгән булса, аңа йөкләмәгез. Чөнки бу вакытларга кадәр бу җирләргә «Шура» кермәде. Без бу журналны күрергә бу көннәрдә генә муафыйк булдык.

*Хаҗи Мөхәммәдниязи.*

**«Шура»:**

Үткән елларда бу бәхәс кабат сөйләнгән иде. Хәзерге җавабыбыз моннан гыйбарәт булачак:

Туфанның бөтен җир йөзен каплап алуы һәм бүгенге бөтен кешеләрнең Нух пәйгамбәрнең өч баласыннан гына таралу гакыйдәсе Коръән кәримнән алынган гакыйдә түгел. Коръән кәримдә Туфан килеп чыгуы, Нух пәйгамбәр көймә ясап, мөселманнар белән шунда кереп, Туфаннан сәламәт калуы һәм үзе белән берлектә хайваннарны да алып керүе хәбәр бирелгән булса, шул Туфан бөтен дөньяны каплап алдымы яки кайбер урыннарда гына булдымы, бүгенге кешеләр Нух пәйгамбәр балаларыннан гына таралдымы, кебек бәхәсләр хакында дәшмәү белән үтә. Гомуми тарих һәм аннан башка әсәрләрдә таралган хәбәрләрнең чыганагы Тәүрат булганлыктан, без мөселманнар өчен бу хакта Коръән кәримдә искә алынган кадәрдән артыкка ышану кирәк эшләрдән түгел. Бүгенге кешеләр Нух пәйгамбәр балаларын-

нан гына таралды, дигән кешеләрнең максатлары – Нух пәйгамбәрнең Хам, Сам һәм Яфәс исемле уллары белән шуларның хатыннары да сәламәт калдылар, диләр. Хайваннарны исә көймәдән чыккан хайваннардан үрчегән булуларын дәгъва кылалар. Безгә Коръән кәрим хәбәр биргән кадәрлесенә генә ышанып, шуннан башкасына керешмәү яхшы. Сәламәтлек шунда.

*Шура. – 1916. – № 14. – Б. 348.*

## [ФИРГАВЕН ИМАНЫН ТИКШЕРҮ ТУРЫНДА]

**Екатеринбург:**

Быел «Шура»ның 16 нчы санында Фиргавеннең иманы мәсьәләсе хакында бер сүз булганда, «Шура» үз тарафыннан мәсьәләнең бик мөһим икәнлеген бәян иткән иде. Без моңа төшенә алмадык. Кешенең иманын тикшерү ни өчен кирәк була да, Фиргавен иманына нинди эшебез тукталып тора, Фиргавен оҗмахка керсә, кемгә тыгызлык килә? Үзебез керә алсак, безгә шул җитә.

*Имам Мөхәммәдгалим Габделгалим улы,*
*Тәскә авылы.*

**«Шура»:**

Безнең максатыбыз, Фиргавеннең иманын тикшерү безнең вазыйфабыз түгел, аның әһәмияте юк, безнең һич эшебез аңа тукталып тормый, дип әйтү иде.

*Шура. – 1916. – № 14. – Б. 349.*

## [«ФАТИХА» СҮРӘСЕ ТУРЫНДА]

**Бөгелмә:**

Быелгы «Шура»ның 3 нче санында (65 нче бит): «Намазда укыла торган Коръән аятьләре һәм догаларның мәгънәләрен белү шарт, «Фатиха» сүрәсенең мәгънәсен белмәгән кешенең намазы намаз булыр, дип белмим», – диелгән. Без бу сүзне бүгенгә кадәр һичбер китапта күргәнебез һәм һичбер хәзрәттән ишеткәнебез юк. Моны, дөрес бер дәгъва булыр, дип тә белмибез. Юкса шул урында берәр төрле басма хатасы бармы? Әгәр дә дөрес булса, шул сүзегез хакында дәлил күрсәтсәгез иде. Бу турыда сүз күп.

*Тимерпулат Хушкилдиев.*

**«Шура»:**

Искә алынган гыйбарә дөрес, хата юк. Без «Ниса» сүрәсендәге 46 нчы аятьтә намаздан тыелу нинди нәрсә сөйләгәнне белү белән чикләнгәнлектән, намазда укыла торган «Фатиха» сүрәсенең һәм догаларның мәгънәләрен белү тиешле, дип аңлыйбыз. Ләкин безнең аңлавыбызның бер генә кеше өчен дә зарары һәм файдасы юк. Бу турыда сүз күбәюнең сәбәбен белмибез. Сез үз гомерегездә никадәр китап карадыгыз да һәм никадәр остаз күрдегез? Шушы сүзнең сез күрмәгән берәр китапта булуы мөмкин түгел, дисезме яки сез күрмәгән берәр остаз тарафыннан сөйләнгән булуын дөрес күрмисезме?

*Шура. – 1917. – № 10. – Б. 234.*

## [«ӘТ-ТАРИКАТ ӘЛ-МӨХӘММӘДИЯ» КИТАБЫ ТУРЫНДА]

**Уфа:**

«Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» исемле әсәрдә «бүленү» хәдисенең асылы булмауны Ибне Хәземгә тоташтырган идегез. Шул ук вакытта, «Әт-тарикат әл-Мөхәммәдия» исемле китапта искә алынган хәдис Бохари белән Мөслимгә тоташтырыла (7 нче биттә). Бохари белән Мөслим хәдисләрен Ибне Хәземнең инкяр итүенә ышанып, зәгыйфьләтергә тырышуыгызны яхшы эш дип белмибез.

*Мосафир бине Мокыйм.*

**«Шура»:**

Бохари белән Мөслим «Сахих»ләрендә андый бер хәдис булмаска тиеш. «Әт-тарикат әл-Мөхәммәдия» авторы хәдис галиме түгел. Үзе яхшы, күңеле сәламәт кеше булса да, хәдис күчерү турында бик йомшак. Хәтта китабында булган хәдисләрне үзе тоташтыра торган асыллардан арадашчысыз алган булуына күңел ышанмый. Безнең җавабыбыз – шушы. Бу заманда инде хак сүзне сөйләсәң, «Элекке авторларны сүгә, үзе әллә кем булмакчы була; аны борынгы мөдәррисләр белмәгәннәрме» дип орышалар, гайбәт журналына язып, сүгәләр. Хак сүзне сөйләми үтсәң, вөҗдан газаплый. Ике мылтык арасында калган кеше кебек ни эшләргә дә белмибез.

*Шура. – 1917. – № 22. – Б. 512.*

# ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ *(А.М. Гайнетдинов)* ........ 3
ТӘФСИРЛӘР ТУРЫНДА ........ 8
ДИНИ МӘЗҺӘБЛӘР ТУРЫНДА ........ 9
ГАЛӘМНӘР ТУРЫНДА ........ 11
ГАУҖ БИНЕ ГАНАК ТУРЫНДА ........ 11
ПӘЙГАМБӘР КАБЕРЕН ЗИЯРӘТ КЫЛУ ТУРЫНДА ........ 12
ЛОТЕРЕЯ ТУРЫНДА ........ 13
ӘЮП ҺӘМ ШОГАЕП ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТУРЫНДА ........ 14
КОРЪӘН ТУРЫНДА ........ 15
ӘКЪСА МӘЧЕТЕ ТУРЫНДА ........ 16
ТЮЛЕНЬ МАЕ ТУРЫНДА ........ 17
СӘДАКА ҖЫЮЧЫЛАР ТУРЫНДА ........ 18
АДӘМНЕҢ СӨЙЛӘШКӘН ТЕЛЕ ТУРЫНДА ........ 19
КИЕМНӘР, ФОТОГРАФИЯ, ФОНОГРАФ ТУРЫНДА ........ 19
АЙ ЯРЫЛУ ТУРЫНДА ........ 20
ИБНЕ ТӘЙМИЯ ТУРЫНДА ........ 21
ГРАММОФОН, ТЕШ ЯМАТУ,
ТЕШ КУЙДЫРУ ТУРЫНДА ........ 21
НӘҮРҮЗ ТУРЫНДА ........ 22
ХАВАНЫҢ КАБЕРЕ ТУРЫНДА ........ 23
ХАҖ ТУРЫНДА ........ 24
ДИНИ МӘЗҺӘБЛӘРГӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА ........ 24
ТУЙ ТУРЫНДА ........ 25
ЧАЛМА, СӘДАКА ТУРЫНДА ........ 26
ТӘМӘКЕ, ЧӘЙ ТУРЫНДА ........ 27
УТ ПУМАЛАСЫ ТУРЫНДА ........ 28
ИСЕМНӘР ТУРЫНДА ........ 28

«ДӘВЕР» ТУРЫНДА .......... 30
ХӘДИСКӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА .......... 32
«ВАҺҺАБИ» СҮЗЕ ТУРЫНДА .......... 33
РАШТУА ТУРЫНДА .......... 35
ДӨЛДӨЛ ТУРЫНДА .......... 37
ШӘДАД ҖӘННӘТЕ ТУРЫНДА .......... 38
БОЛГАРГА КИЛГӘН СӘХАБӘЛӘР, БЕР ХӘДИС ТУРЫНДА .......... 38
БИДГАТЬЛӘР ТУРЫНДА .......... 40
ЗИРАТЛАР ТУРЫНДА .......... 41
МӨХӘММӘДИЯ» КИТАБЫ, КАБЕРДӘН ТЕРЕЛЕП ЧЫГУ, БЕР ХӘДИС ТУРЫНДА .......... 43
«КАРА ТАШ» ТУРЫНДА .......... 44
ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ТУРЫНДА .......... 46
ИЗГЕ КАБЕРЛӘР ТУРЫНДА .......... 47
КОРЪӘН СҮЗЛӘРЕ ТУРЫНДА .......... 48
НАМАЗ ТУРЫНДА .......... 50
ҖЕНАЗА ТУРЫНДА .......... 51
ТАЛАК ТУРЫНДА .......... 53
МӘҮЛИД ТУРЫНДА .......... 53
ХӨТБӘ СӨЙЛӘҮ РӘВЕШЕ ТУРЫНДА .......... 57
ТАҢ, АЛТЫН ЧЫГАРУ ТУРЫНДА .......... 59
ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ ҖӘМӘГАТЬ БЕЛӘН НАМАЗ УКУЛАРЫ ТУРЫНДА .......... 60
ӘҮЛИЯЛӘР ТУРЫНДА .......... 62
УТЫЗ ИМӘНИ ШИГЫРЕ ТУРЫНДА .......... 68
АЙ КУЮ ТУРЫНДА .......... 69
АДӘМ ҺӘМ ХАВА ТУРЫНДА .......... 70
ДИНИ РУХ БИРҮ ТУРЫНДА .......... 71

КАБЕРЛӘРНЕ ИЗГЕЛӘШТЕРҮ ТУРЫНДА .................................... 73
ХӨТБӘНЕ ТӨРКИЧӘ (ТАТАРЧА) УКУ ТУРЫНДА ......................... 76
ШАЙТАН, СӘДУМ, ХОЗЫР-ИЛЬЯС,
ЯҖҮҖ-МӘЭҖҮҖ ТУРЫНДА ........................................................ 77
КОРЪӘН ҺӘМ ХӘДИСКӘ ИЯРҮ ТУРЫНДА .................................. 79
«ХУҖА»ЛАР ТУРЫНДА ................................................................ 82
«ГАЙНЕЛ-ГЫЙЛЕМ» КИТАБЫ ТУРЫНДА ................................... 83
ШОМЛЫ КӨННӘР ТУРЫНДА ......................................................... 84
ХУҖА БАҺАВЕТДИН, ШӘЕХЛӘР ТУРЫНДА .............................. 84
ӘҮЛИЯЛӘР КАБЕРЛӘРЕ ТУРЫНДА ............................................. 87
ТӘҮРАТ, ХАТАЛЫ ЭШЛӘР ТУРЫНДА .......................................... 89
ҖӘННӘТЛЕ ДИП ШӘҺАДӘТ БИРҮ .............................................. 93
МӘЕТЛӘРГӘ КОРЪӘН УКЫТУ ТУРЫНДА .................................. 95
ЛОТЕРЕЯ, ФИДИЯ, ДИН ИРЕШМӘГӘН
КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА ................................................................. 98
КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ТУРЫНДА ....................................................... 99
ФИРГАВЕН ИМАНЫ ТУРЫНДА ................................................ 100
НУХ ПӘЙГАМБӘР ТУРЫНДА ................................................... 101
ФИРГАВЕН ИМАНЫН ТИКШЕРҮ ТУРЫНДА .......................... 102
«ФАТИХА» СҮРӘСЕ ТУРЫНДА ................................................. 103
«ӘТ-ТАРИКАТ ӘЛ-МӨХӘММӘДИЯ»
КИТАБЫ ТУРЫНДА .................................................................. 104

**Риза казый фәтваләре**
**(Фетвы Ризы казыя)**

*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *Л.М. Зигангареева*
Подписано в печать 29.10.2019 г. Формат 60×84 1/16
Усл. печ. листов 6,75 Тираж 1000 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46,
231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф